ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№12 (395)
ДЕКАБРЬ 2024

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

АЛЬБИНА КАМЕНЕЦКАЯНЫҢ МАТУРЛЫК ДӨНЬЯСЫ

4 612750 670011

№12 (395)
ДЕКАБРЬ 2024

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Шарова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Айдар Шәйхин, Әхмәт Шакиров, Михаил Рябинин
Фотографлар: Александр Ефремов, Аида Илһамова,
Айдар Мөшәрәпов, Никита Тохтасинов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Альбина Каменецкая. Раил Шакиров фотосы

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: А-2847
Басарга кул куелды: 12.12.2024
Чыгу көне: 18.12.2024

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

104 НЧЕ ДЕКАБРЬ

«Татарстан» бу әкияти Яңа ел аен 104 нче мәртәбә яши. Ай башында – 1 декабрьдә – журналга 104 яшь тулды. Ай ахырында – 31 декабрьдә – ул, безнең белән бергә, яңа 2025 елга аяк басачак. Инде 105 нче яшен каршыларга.

Яше шактый олпат булуга карамастан, безнең «Татарстан» бик яхшы сакланган: җете, матур, кызыклы. Абруен күрсәтеп тора торган саллылыгы да бар, яме-күрке дә.

– Синең озын гомерле булуыңның сере нәрсәдә соң? – дип кызыксынды «Татарстан»нан туган көненә килгән кунаклар.

Без җавап бирдек:

– Беренчедән, бары АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР/ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР/МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘРНЕ генә яктыртуда.

– Икенчедән, бер урында утырып кына түгел, хәтта таптанып та тормыйча, КҮП СӘЯХӘТ ИТҮДӘ. Хәрәкәттә – бәрәкәт, исегездәме?

– Өченчедән, үз һөнәреңә, сайлаган кыйблаңа, кәефеңә ХЫЯНӘТ ИТМӘҮДӘ!

Туган көнебез белән безне! Якынлашып килгән Яңа ел белән! Һәрчак укырга яхшы китаплар, эчтәлекле басмалар булсын! Бигрәк тә – кышкы озын кичләрдә.

Сезнең 104 яшьлек редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның ярты еллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» 104 ЯШЬ
ЖУРНАЛЫНА

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре
бары ТИК ТАТАРСТАНДА

ГАЛӘМ КУНАГЫННАН – ЙОЛДЫЗЛЫ ЯРА*

Татарстанда Буадан көнбатыштырак, Чувашия белән чиктә, «Карлин кратеры» бар – ул Россия территориясендә моңа кадәр табылган уникe иң эре метеорит кратерларының берсе. Галәм кунагы монда якынча биш миллион ел элек төшә дә җир өслегендә алагаем зур эз, җәрәхәт хасил итә. Аның туфракны ярып тирәнгә китүенең диаметры 10 километрга җитә. КФУ Геология музеенда метеорит төшкән дип исәпләнгән урыннан алып кайткан токым да бар. Дөресрәге, ул – төрле токымнарның чәрдәкләреннән гыйбарәт, әмма югары басым астында цементлашып укмашкан катнашма.

Кратерны бүген инде космостан да карап шәйләп булмый. Миллион еллар дәвамында явым-төшемнәр, ком белән балчыкның күчеше нәтиҗәсендә кратер инде бөтенләй «яшеренгән». Хәзерге кеше эшчәнлеге һәм яшәеш эзләре дә аермачык – «йолдызлы яра» урынында Протопопово, Ямбулат, Мөкерле авыллары урнашкан. Алар барысы да үзәнлектә утыра, Протопопово авылыннан соң, төньяк-көнбатышка таба гына, калкулыклар барлыкка килә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

* Җир өслегенә каты бәрелүдән барлыкка килгән кратерларны галимнәр астроблема дип атый, грек теленнән тәрҗемә итсәк, ул «йолдызлы яра» дигәнне аңлата.

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Иннополиска ышан, үзең дә тырыш
Югары Ослан районын нинди киләчәк көтә

10. Аграр тармактагы технологияләр
Аның савым һәм уңыш күләменә йогынтысы

20. «Кара урман» көче
Татар җыры академик Кев Салиховка ничек булышкан

28. Университет тәмамлаучылар
Тарихчы-археологлар ничек тренер-берейторга әверелә

игелекле эшләр

38. Совет иле канатлары: үткәннәргә өмет белән
Авиация музеенда нинди очкычларны күрергә була

50. Өч гасырга сәяхәт
Төньяк Чулман төбәгендә нинди тарихи экспонатлар шаккатыра

54. Волонтёр көндәлеге
Журналист Дмитрий Сивков фронт хастаханәсендә ничек хезмәт итте

60. Гамьле әңгәмә
Бездә кунакта – Римма Ибраһимова

64. Халыкара китап ярминкәсе
Милли әдәбиятлар кайда очрашты

мәңгелек кыйммәтләр

70. Матурлык дөньясы
Шаһинә таҗына ничек ия булырга

74. Онытылмас исемнәр
Мөхәммәтхан Фазлуллин: тел язмышы сагында

80. Татарстан авыллары
Яңа Бүләк – Илһамлы авыл

88. Җылылык һәм яктылык шагыйрьләре
Энергетиклар илһамны каян ала

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: komanda-k.ru

Акыллы гамәлләр

20.11

Михаил Мишустин, Россия Федерациясе Премьер-министры, – Мәскәүдә, Халыкара транспорт форумында:

– Тулысынча яңартылган Superjet, Ту-214, Ил-96, Ил-114 һәм җирле линияләр өчен «Байкал»ны да кертеп, барлык типтагы самолётларны мөмкин кадәр тизрәк массакүләм җитештерүгә тапшырырга кирәк. Вертолётлар буенча да шундый ук планнар. Моның өчен кирәкле акчалар билгеләнгән.

Игелекле эшләр

22.11

Валерий Фальков, РФ фән һәм югары белем министры, – Казан (Идел буе) федераль университетының 220 еллыгына багышланган тантаналы җыелышта:

– Үзенең бай мирасына таянып, университет бүген лидер вузлар арасында ныклы урын алып тора һәм илнең технологик бәйсезлеген тәэмин итүгә зур өлеш кертә. Яңа белем бирү программаларын, тикшеренү эшчәнлеген үстерүгә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Президентыбыз Владимир Путин тарафыннан хупланган проектлары ярдәм итә. Алар арасында «Приоритет-2030», «Алдынгы инженерлык мәктәпләре» һәм башкалар бар. 220 еллык чикне үтеп, университет ышанычлы адымнар белән киләчәккә атлый.

Мәңгелек кыйммәтләр

14.11

Лян Жэньчжэ, Цзилинь провинциясе вице-губернаторы, – «Казан Экспо»да узган «РОСТКИ» Россия-Кытай хезмәттәшлегенең II форумында:

– Без Татарстан икътисадының уңай һәм тотрыклы үсешен күрәбез. Сезнең республикада сәнәгать, IT-тармак, авыл хуҗалыгы яхшы үскән. Хезмәттәшлек өчен потенциал бик зур. Безнең бурыч – әлеге мөмкинлектән максималь дәрәҗәдә файдалану.

Фото: tatar-inform.ru, news.mingpao.com

игелекле эшләр

акыллы гамәләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан **ничек** Идел буеның азык-төлек хабына әйләнә

Кем миграцияне шәһәрдән авылга борырга хыяллана

Татар җыры академик Кев Салиховка **кайсы** чакларда булышкан

Тарихчы-археологлар **ничек** тренер-берейторга әверелә

ЮГАРЫ ОСЛАН: ЯРЛАРЫҢА КАГА БИЕК ДУЛКЫН

Татьяна Вафина

Югары Ослан төбәге борынгыдан билгеле. Быел аңа 430 яшь тула! Татарстанның иң матур районнарының берсе саналган Югары Ослан Идел елгасының текә ярында урнашкан. Алай гына да түгел, аның 90 градуслы текә борылышында. Нәкъ менә бу урында көнбатыштан көнчыгышка таба ага торган мул сулы елга көньякка таба кискен борылыш ясый. Кыскасы, кая карама, барысы да текә монда!

АЛАР ЧИГЕНМӘС ҺӘМ СЫНАТМАС

Күптән түгел генә бу район белән Евгений Варакин җитәкчелек итә башлады. Ул – ике ел дәвамында Россиянең яңа төбәкләре – Лисичанск һәм Рубежный шәһәрләрен торгызу эшләре белән җитәкчелек иткән кеше. Кыскасы, Югары Осланга башлыкларның да бик шәбе туры килде. Хәрби хәрәкәтләр зонасында аның позывное да «Татарин» булган. Аңа биредә дә катлаулы бурычларны хәл итәргә туры киләчәк, әмма Владимир Путин үзенең Федераль юлламасында махсус хәрби операциядә катнашучылар турында әйткәнчә: «Алар чигенмәс һәм сынатмас. Алар алдынгы урынга чыгарга тиешле төбәк, предприятиеләрне, иң эре иҗтимагый проектларны җитәкләргә тиеш».

КҮЧЕНҮ ИКӘН, БАРЫ ТИК БЕЗНЕҢ РАЙОНГА!

– Димәк, авыл халкының шәһәргә күченүенә бәйле бурычларны да җиңеп чыгарга өметләнәсез? Әллә бу мәсьәләдә Югары Ослангa куркыныч янамыймы? Ул бит шәһәргә иң якыны... Җитмәсә, Иннополис та янәшәдә генә.

– Әйе, район өчен төп проблемаларның берсе – хезмәт миграциясе. Шуңа күрә үзем алдына, командам алдына куйган төп бурычларның берсе – миграцияне әкренәйтү. Мин киресенчә миграцияне үзебезгә таба борырга телим. Беренчедән, без шәһәргә якынмы, әллә шәһәр безгәме – кем ничек әйтә бит. Икенчедән, 2030 елгы Стратегиядә билгеләнгән Казан агломерациясен беркем дә гамәлдән чыгармады әле.

Казанга якын булуның районыбызны туризм ягыннан гына түгел, сәнәгать кластеры буларак үстерүне дә таләп итүен яхшы аңлыйбыз. Әгәр күрше Кайбычка күз салсак, анда авыл хуҗалыгы өстенлек итә. Районыбыз халкы биредә эшләсен өчен, миграция белән бәйле вазгыятьне яхшыртырга өметләнәм. Моның өчен кешеләрне

Фото: Аида Илһамова

максималь дәрәҗәдә эш урыннары белән тәэмин итәргә кирәклеген аңлыйм. Әйе, район территориясендә Иннополис та бар, әмма минем үземнең фикеремчә, бу шәһәр – үзенчәлекле эш урыны. Ягъни һәр кешенең дә IT-белеме юк, әйеме? Анда барыбер басым күбрәк югары технологияләргә ясала. Хезмәт күрсәтүче персонал да күптән тупланган, мин белеп сөйлим.

Шуңа күрә Иннополиска өметләнәбез, әмма үзебез дә тик ятмыйбыз. Районда хәзер берничә көчле проект эшли башлады. Мәсәлән, өч индустриаль парк төзелә. Бездә бер проект бар, мин аны фантастик дим – бер төзүче районга зур күләмдә акча кертергә ниятли. Мин әлегә сумманы атамыйм, шуны гына әйтәм: Казанда нинди генә проектларда катнашмадым, әмма минем өчен дә бу акчалар бик зур! Бездә мең ярым урынга исәпләнгән курорт-савыктыру комплексы төзү планлаштырыла. Күз алдына китерәсезме, мең ярым урын! Һәм аларда, фаразланганча, 1200 эш урыны ачылачак. Әле бу төзелешне санамаганда. Гомумән, кабатлап әйтәм, җирле халыкны эш урыннары белән тәэмин итү – эшчәнлегемнең төп юнәлешләренең берсе.

ГАИЛӘМ ТАРИХЫНА ХЫЯНӘТ ИТӘ АЛМЫЙМ

– Фронт зонасында эшләү тормышка карашны нык үзгәртә. Анда алынган тәҗрибәне Югары Ослан районында кулланып булырмы?

– Сез беләсезме, күп кеше миннән анда барырга ничек риза булдың дип сорый. Ә мин ризалашмый булдыра алмыйм, чөнки бу гаиләм тарихына хыянәт булыр иде, мин шуны тойдым. Бабам өч сугыш кичкән, өч сугышта Ватанны саклаган. Ул Фин сугышында очкан, Бөек Ватан сугышында очкан, хәтта япон сугышында да катнашырга өлгергән. Һәм мин аның сөйләгәннәре йогынтысында үстем, офицер хатыны буларак һәрвакыт янәшәсендә булган әбием тәрбиясен алдым. Һәм әгәр мин, куркып калып, бармыйм, монда гаиләм, балаларым, тормышым җайланган дисәм, бу алар истәлегенә хыянәт булыр иде. Шуңа күрә мин озак уйлап тормыйча киттем. Бу чыннан да шулай.

Тормышымның теге өлеше турында сораганда, шундук балачак хатирәләре – офицер хатыны буларак, бабай белән аның сугышчан юлын, тылдагы тормышын уртаклашып яшәгән әбиемнең сөйләгәннәре күз алдына килә. Һәм турыдан-туры хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан бабам хатирәләре. Әйе, 80 ел элек тә, хәзер дә сугыш сугыш инде – югалтулар, кайгы, күз яшьләре – барысы да шул ук, берни дә үзгәрми, миңа ышана аласыз. Моның кайчан булуы мөһим түгел: 14 гасырдамы, 15 гасырдамы, әллә бүгенме. Шулай булгач, нинди дер яңалык әйтә алмыйм. Сугыш вакытында кешенең тормышы җимерелә. Мин анда бер көн эчендә барысын да җуйган кешеләр белән аралаштым. Туганнарын югалткан кешеләрне күрдем. Гаиләләре ике якка бүленгән кешеләр белән дә сөйләшергә туры килде. Бу, минемчә, иң куркыныч, иң аяныч хәл. Бер хатын-кыз – Лисичанскидагы бүлекчә җитәкчесе – миңа елый-елый теге якка киткән, нацистлар идеологиясенә бирешкән бертуган апасы белән нәрсәләр язышуын күрсәтте. «Без кайтачакбыз, сине, Ватанга хыянәтче буларак, беренче баганага ук асып куячакбыз», – дип язган аңа апасы. Ике бертуган арасындагы язышу бу! Гаиләләрне аеру, милләтне җимерү – сугыш шулай бара. Ул күтәрә алмаслык зур кайгы-хәсрәт алып килә.

Мин үземнең нык үзгәргәнемне тоям. Якыннарымны күбрәк ярата, тормышымны күбрәк кадерли башладым.

Өйгә ракета һөҗүменнән соң, мизгел эчендә аңлап алып, җимерекләр астыннан бер секунд элек исән булган кешеләрнең гәүдәләрен тартып чыгарасың. Һәм исән туганнарның ничек кайгыруын күрәсең – бу эзсез үтә алмый. Казанда берәр юл һәлакәте булса да, бөтен шәһәр борчыла. Ә монда һәр көн, һәр сәгать, һәр минут шартлый, ярыла, үтерә... Янәшәдә, синең күз алдыңда диярлек. Әйе, даими рәвештә мондый вазгыятьтә булганда, үзеңдә ниндидер деформация барганын аңлыйсың. Яшь табибларның, авырттырудан куркып, авыруны кызганулары кебек. Ә аннары табибның

йөрәге авыру күргән саен алай кысылмый башлый. Чөнки кызганырга түгел, дәваларга кирәк. Һөҗүм нәтиҗәсендә дистәләгән кеше һәлак булуын күргәндә дә шундыйрак үзгәреш тоя башлыйсың. Син аларны җимерек өемнәре астыннан чыгарасың да чыгарасың, һәм бервакыт үзеңнең беренче мәлләрдәге кебек борчылмаганыңны аңлый башлыйсың. Инде әчтән янып бетүеңне, хәсрәткә дә иялэшә башлавыңны сизәсең. Шуңа күрә тормышым һичшиксез үзгәрде.

КИТАП ПЕНСИЯГӘ ЧЫККАЧ ЯЗЫЛЫР

– Киләсе ел махсус хәрби операция елы дип игълан ителде. Сез Лисичанскида алган тәэсирләрегез, кичерешләрегез турында китап язарга теләмисезме? Мондый китапны укучылар күп булыр, дип уйлыйм.

– Бу хакта инде бик күп язылды. Китап түгел, әлбәттә. Китаплар әле өлгермәгән... Хәер, мин китап дип шапырынмам да. Беренчедән, дөресен генә әйткәндә, мин эш аты. Үзеңне китап язуга багышлар өчен, барысын да кичектерергә һәм шуның белән генә шөгыльләнергә кирәк. Язар нәрсәләр күптер, әмма мин әлегә әзер түгел. Бәлки, буш вакыт күп булганда, пенсиядә язылыр...

ХОХЛУШКА – ГАИЛӘ ӘГЪЗАСЫ

– Евгений Анатольевич, безнең журнал укучыларын Изиның* хәлләре дә кызыксындыра. Ул нихәл, яңа, тыныч тормышка иялэшәме?

– Хәлләре бик яхшы. Аны барысы да ярата. Яратып, Хохлушка дип йөртәләр. Барысы да аны сыйларга тырыша. Хәер, мин: «Дуслар, без аны бик яхшы ашатабыз. Аның барысы да әйбәт, барлык витаминнарны, тиешле прививкаларны ала!» Әмма, беләсезме, бу да безнекеләргә хас сыйфат. Мин кешеләргә үпкәләмим, аларның да үпкәләмәвен үтенәм: «Дуслар, әгәр сез китергәннең барысын да ашатсак, ул озак яшәмәячәк. Ә без аның озак һәм бәхетле яшәвен телибез», – дим.

Изи – бик шук, ә кайчак бик җитди маэмай. Тиз үсә. Менә хәзер кышка әзерләнә – бу бит аның өчен бездәге беренче кыш. Ә монда климат салкынрак. Ләкин, күрәмсең, кыш аңа ошый. Ул карда рәхәтләнеп уйный...

Изи үсә. Кечкенә көчектән җитди этка әверелә – территорияне, безне саклый, ул үз вазифаларына ия тулы хокуклы гаилә әгъзасы булуын аңлый.

– Ә сез аны каян таптыгыз? Аны шундый ерак арадан алып кайтырга ничек батырчылык иттегез?

– Бу гомумән бик кызыклы тарих. Юлда барганда, кечкенә генә эт баласын күреп алдык. Бик кечкенә, мөгаен, ике ай чамасыдыр. Үзе бик матур! Машинаны чүп ташларга дип туктаткан идек. «Кире кайтканда, шул ук урында утырсаң, без сине алып китәрбез!» – дидек тегеңә.

Ни гаҗәп, кире кайтканда маэмай шул ук урында безне көтеп утырмасынмы!

Ишекне ачуыбыз булды, сикереп менде дә! Һәм шуннан бирле бездән аерылмады, безнең белән бергә яшәде.

Мин хайванны вакытлыча гына тотып, аннан соң чыгарып ташлаган кешеләрне аңламыйм. Үзеңә аласың икән, ул гаилә әгъзасына әверелә. Яши торган йортыбыз өстеннән ракетаны бәреп төшергәндә дә, тирә-юньдә ядрә кыйпылчыклары очканда да ул янәшәбездә булды. Безнең белән яшеренде, көнкүреш авырлыкларын бергә күтәрде. Ул безне саклады. Салкын булганда, безнең белән өйдә йоклый иде. Ничек инде аны үзең белән алмыйсың? Гаилә әгъзасын ничек калдырып китәсең? Күз алдына да китереп булмый. Шуңа күрә Изи безнең белән бергә кайтты.

ПОЛКЫБЫЗ КЫЗЫ

– Маэмай ничек сездә калды, анда сез генә түгел бит?

– Бик җиңел. Кем өлкәнрәк. Административ ресурс ярдәм итте. Мин: «Үземә алам!» – дидем дә бетте-китте. Миңа булды. Әмма ул минеке генә дигән сүз түгел. Ул бөтенесен сагына, көтә, шатланып каршы ала. Егетләрнең барысы да һичшиксез аның янына килеп йөри. Ул полк кызы кебек. Хезмәттәшләрем Сергей да, Айрат та, безгә килеп, аның белән уйныйлар, аралашалар, бу яктан ул иркәләнеп бетте инде. Үзләре белән дә алып китә алалар. Изиның өч өе бар – кайсына барса да, аны шатланып каршы алалар. Дөресен генә әйткәндә, кайчакта аны фәрештәбез дип тә уйлый идек, чөнки ул безгә авыр шартларда яшәргә ярдәм итте, туган ягыбызны сагыну да аның белән җиңелрәк кичерелде. Ул сөй-

* Изи – Донбасстан Казанга Евгений Варакин алып кайткан эт баласы.



кемле бала, назлы уенчык кебек, аның ихласлыгы безгә көч бирә иде.

Кешеләрнең суга йөгерүләрен, үзләренә ризык табарга, дистә еллар дәвамында туплаган, ә аннан мизгел эчендә югалткан, җимерелгән малларын бөртекләп торгызырга тырышуларын күреп борчыласың... Җитмәсә, акчасы да, уты да, суы да, газы да юк... Һәм бу бетмәс-төкәнмәс караңгылыкны күреп, кайчак гаҗизләнеп каласың, төшенкелек биләп алгандай тоела. Ә монда, янында, шатлыгыңнан койрыгын болгап, сине ялап яратуын белдерергә омтылган җан иясе йөгереп йөри – һәм син үзеңнең кемгәдер кирәклегеңне аңлыйсың. Эт синең кайтуыңа, исән булуыңа шатлана – бернинди артык әйбергә өмет итми генә. Һәм каяндыр көч-ышаныч пәйда була. Канатлар үскәндәй тоела. Һәм шуны аңлыйсың: син барысын да булдырырга тиеш, син булдыра аласың.

Изины монда алып кайту тулы бер маҗарага тиң. Юл озын, аны йөртеп керергә дип туктыйбыз. Озак барганга, юллар сикәлтәле булганга, аны укшыта. Күпне кичерде ул. Анда, кызганычка каршы, бик күп эт-мәче машина астына эләгә. Бездә бу бик сирәк күренеш. Ә анда шартлау гөрелтеләре аркасында, алар чукраклана. Юлга чыккач, машина тавышын, сигнал бирүне ишетмиләр. Контузияләнгән һәм чукрак эт-мәчеләр бик күп. Сугышта кешеләр генә интекми.

ПЛАННАР ЗУРДАН

– Югары Осланга әйләнеп кайтыйк. Районда сезне ничек кабул иттеләр? Якын киләчәккә планнарыгыз? Сез нәрсәне үзгәртергә/төзергә/төзекләндерергә телисез?

– Мине ничек кабул иткәннәрен әлегә белмим. Бу сорауга җавапны монда

эш күрсәткәч аңларбыз. Планнар зурдан. Без кай юнәлештә хәрәкәт итәргә кирәклеген ачыкладык. Үзгәрешләрсез генә булмас. Алдагы башлыкның үз планнары, таләпләре булган, район үсешен дә үзенчә күргән. Минем исә үз планнарым бар, алар зурдан. Югары Осланга ял көннәрендә генә түгел, бөтенләйгә яшәргә күченеп килүләрен телим. Аларның тормышларын уңайлы итәргә кирәк, дип уйлыйм. Инфраструктураны да үстерергә, җайлы итәргә тырышачакбыз. Бәлки, кемнәрдер үзләренең тыныч тормыш агышын бозуда гаепләр, әмма, минемчә, алар районның үсүеннән, киңәюеннән канәгать калыр. Кешеләрне бирегә тартуда һаваның сафлыгы, елганың якынлыгы, экологиянең чисталыгы ярдәм итәр. Монда яшисе, балаларны тәрбиялисе-укытасы килер, җирле халык та Казанга китмәс, ә үзләренең туган ягына өстенлек бирер, дип хыялланам. Бездәге хезмәт хаклары да шәһәрдәге кебек булыр.

Тагын нинди эшләр көтә? Без елга ярында яшәсәк тә, суга бәйле проблемалар бар – парадокс бит! Ягъни бездә мораль яктан искергән ике су алу урыны бар, әмма район үсә. Иске су манаралары кайчандыр үз эшләрен яхшы башкарган, ләкин халык саны арта бара. Ял көннәрендә районга 110 мең кеше килә! Бу мин уйлап тапкан сан түгел – рәсми статистика. Дачниклар, туристлар, биредә туган нигезләре булган кешеләр... Шашлык кыздырып ял итәргә килүчеләр дә, ниндидер үз хуҗалыкларын алып баручылар да бар. Кемнәндер монда җиләк-җимеш, яшелчә бакчасы, алар су сибәргә, чүп утарга дип килә. Ял көннәрендә – 110 мең кеше, күз алдына китерәсезме?!

Шуңа күрә бездә суга кытлык. Ике су манарасы гына җитми. Төп бурыч әнә шул. Без, әлбәттә, тик тормыйбыз. Бик күп су бирә алырлык яхшы урын табылды – ул Югары Осланга, Түбән Осланга, Студенец, Печище җирлекләренә җитәрлек. Моның өчен безгә «Чиста су» федераль проектына керергә һәм су манарасы төзергә кирәк.

Бу, әлбәттә, заманча чистарту корылмалары төзүне дә таләп итәчәк. Чистарту корылмалары хәзер дә бар, әмма алар үз мөмкинлекләре чигендә эшли. Әгәр дә без куәтле су манарасы төзибез икән, су куллану артачак, димәк, аларны дөрес, экологик яктан тел-теш тидермәслек итеп эшләтү өчен, кулланылган суны да чистартырга кирәк булачак.

ИҢ МӨҺИМЕ – АРТТЫРЫП ҖИБӘРМӘСКӘ!

– Югары Ослан – бик матур урын. Туристларның яраткан ял итү урынына әйләндерергә мөмкиндер...

– Туризм белән бүгенге көндә үк мактана алабыз. Үсеш буенча планнар да күп. Ләкин, минемчә, монда иң мөһиме арттырып җибәрмәскә! Барысы да чама белән эшләнергә тиеш. Ялга килүче-китүче туристлардан соң үлән дә үсми торган, «яндырылган» җир генә калуын теләмибез. Җирле халыкка да яхшы яшәргә кирәк. Авыл хуҗалыгы да үсәргә тиеш – бу илнең милли иминлеге. Туризм өчен акватория күбрәк туры килә, әмма районның ерак авылларында да туристлар өчен кызыклы объектлар бар, тик алар елга буендагы кебек масштаблы түгел. Бүгенге көндә инде 11 глэмпинг төзелгән. Һәм аларны башка төбәкләрдән килүче туристларга күрсәтергә оят түгел. Кызыл Байракта, мәсәлән, элеккеге «Связист» лагере базасында. Сез анда күпме кеше килүен күз алдына да китерә алмыйсыз!

Бездә йокы сатыла торган глэмпинг та бар. Әйе-әйе! Кешеләр безгә тынлыкта йокларга килә. Бу «йокы урыны» проектын бер инвестор кыз уйлап тапты һәм төзетте. Менә хәзер ул тагын алты йорт төзергә тели. Урман ешлыгында. Мондый төр ялга да ихтыяҗ бар икән. Бертуктаусыз цейтнотта, секунд саен башларына мәгълүмат ташкыны ишелү шартларында эшләүче Казан халкы 2-3 көнгә нарат урманында йокларга килә. Илаһи тынлык анда! Бәясе кыйммәт түгел, ялга ихтыяҗ зур.

Мин бик гаҗәпләнгән идем: «йокы урыны» безнең өчен бик туры килми торган үзенчәлекле нәрсә кебек тоелды. Ләкин мин ялгышканмын. Бик кирәк булып чыкты.

КҮЗНЕ ИРКӘЛИ ТОРГАН НӘРСӘЛӘР

– Районда сез яраткан урын бармы? Онытылып ял иткән, көч туплаган, көнделсезлекләрне онытыра, хыялландыра торган урыныгыз...

– Миңа Түбән Ослан бик ошый. Түбән Осланга борылып төшә башлагач, искиткеч манзара ачыла: диңгездәй су дәрьясы, бөтен Казан уч төбендәге кебек. Лаеш районы да, Зеленый Бор да күренә... Бу урынны бик яратам. Мин Мәйданны, Коргуза якларын яратмыйм дип әйтә алмыйм... Алай түгел. Ләкин нәкъ менә Түбән Осланга төшә торган урын күзне иркәли, кәефне күтәрә.

– Әгәр сезгә Югары Осланда беркайчан да булмаган дусларыгыз килсә, аларны беренче чиратта кая алып барыр, нәрсә күрсәтер идегез?

– Монда матур урыннар бик күп. Мин аларга бөтен җирне күрсәтер идем. Мәсәлән, Вахит авылын – матур, тәртипле җирлек. Бүгенге көндә М-12 юлы ачылды, хәзер ул тагын да ныгып, баеп китәр, дип уйлыйм. Бу юл күп кенә инвесторларны Югары Ослан районына таба борды. Ягъни М-12 авыл халкы өчен бай инвестицияләр китерергә сәләтле акыллы гамәл булды. Хәзер күпләр М-12 юлы тирәсендә эшләтеп җибәрергә теләгән кызыклы проектлар тәкъдим итә. Вахит мисалында без аның гади авылдан бик кызыклы урынга әйләнүен күрәбез. Безгә бер проект белән мөрәҗәгать иттеләр – балалар өчен авыл хуҗалыгы буенча тематик юнәлешле лагерь төзергә телиләр. Бик өметле, кирәкле проект дип саныйм!

Хәзер авторлар грант алыр өчен РФ Мәгариф министрлыгына гариза бирәләр. Мин мондый проектка ике куллап риза. Безгә бөтен республикадан балалар киләчәк – бу нәкъ менә киләчәктә авыл хуҗалыгында эшләргә теләүче укучылар. Бу белем бирү лагеренда уен аша балада авыл хуҗалыгы эшчәнлегенә дөрес мөнәсәбәт, туган якка мәхәббәт тәрбияләнәчәк. Кыска гына итеп әйткәндә, кеше бала чагыннан ук үзенең кем булырга, нәрсә белән шөгыльләнергә теләвен аңлый башлаячак. Югыйсә хәзер укучыдан кем булырга теләвен сорыйсың икән, ул аптырап кала. Күпчелеге эти белән әни мәҗбүр иткән һөнәрне үзләштерә. Һәрвакыт эшле булсын дип, ата-ана, мәсәлән, баласының стоматолог булуын тели. Ә балага үсемлекнең ничек үсүен күзәтү ошый... Менә мондый лагерьларда исә балада кечкенәдән һөнәргә кызыксыну пәйда булачак. Бу ата-ананың фикер сөрешенә дә йогынты ясаячак. Һөнәр сайлау вакыты җиткәндә, бала үзенең чыннан да нәрсә теләгәнен аңлап эш итәчәк.

МАРАТ ҖӘББАРОВ: «АВЫЛГА ЯРДӘМ – БЕЗНЕҢ ТӨП БУРЫЧ»

Әхмәт Шакиров

Татарстан ашлыгының сыйфаты нинди? Тармакны цифрлаштыру ничек ярдәм итә? Безгә атланмай кытлыгы янамыймы? Чит илгә нинди продуктлар сатабыз? «Татарстан»ның әлеге һәм башка сорауларына Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров җавап бирә.

АЗЫК-ТӨЛЕК СЫЙФАТЫ ТУРЫНДА

– Марат Азатович, авыл халкының хезмәтенә бәя биргәндә без гадәттә сан күрсәткечләре белән эш итәбез. Әйдәгез сөйләшүне икенче яктан – сыйфаттан башлыйк әле.

– Әйдәгез, карап карыйк. Ноябрь уртасына мәҗбүри дәүләт мониторингы кысаларында белгечләр 2,1 млн тоннадан артык бодайны тикшерде (алынган бодайның 98,9%ы). Нәтиҗәләр мондый: тикшерелгән ашлыкның биштән бер өлеше, ягъни 418 мең тоннадан артыгы – составында 23 проценттан һәм аннан да күбрәк җилемсә (клейковина) булган 3 классллы бодай. 818 мең тонна (40 процентка якын) – 4 классллы бодай, аның составында җилемсә 18 проценттан да ким түгел. Кырдан җыеп алынган ашлыкның төп өлеше, рәсми беркетмәләрдән күренгәнчә, – азык-төлек бодае. Иң мөһим күрсәткеч – он чыгышы сыйфаты буенча 3 һәм 4 классллы яңа бодай экспорт күрсәткечләренә туры килә. Бу Федераль агросәнәгать комплексы продукциясенең куркынычсызлыгын һәм сыйфатын бәяләү үзәгенең Татарстан филиалы белгечләре чыгарган нәтиҗәләр. Ышандырып шуны әйтә алам: аграрийларыбыз үстергән иген, яшелчә, сөт ризыклары – барысы да яхшы сыйфатлы. Аерым алганда, сөтнең сыйфатын Роспотребнадзор даими контролендә тота, күп еллар дәвамында анда антибиотиклар, пестицидлар, сәламәтлеккә зыян китерерлек башка матдәләр табылганы юк.

– Быелгы һава шартлары авыл хезмәтчәннәрен шатландырып тормады. Уңышта бу ни рәвешле чагылыш тапты?

– Рекордлы уңыш җыя алмадык. Әмма быел игенчеләрне озакка сузылган язгы салкыннар, җитди корылык сынавын исәпкә алсак, нәтиҗәләр начар түгел. 3,8 млн тон-

Фотолар: tatarstan.ru, tatar-inform.ru, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы матбугат хезмәте

на ашлык алынды (эшкәрткәннән соң), гектарыннан уртача уңыш 29 центнер тәшкил итә. Шуның 2 млн 300 мең тоннасы – бодай, 976 мең тоннасы – арпа, 141 мең тоннасы – арыш, 134 мең тоннасы – бөртекле-кузаклы ашлык. Шикәр чөгендере – 2,6 млн тоннадан артык, бәрәңге һәм башка яшелчә продуктлары 1,2 млн тонна җыелды. Терлекләрне уңышлы кышлату өчен җитәрлек азык әзерләнде. Табигать сынауларына авыл хезмәтчәннәре профессиональлек, оешканлык, заманча технологияләр белән каршы торды. Татарстанлылар бүген төп азык-төлек продуктлары белән тулысынча тәэмин ителгән, алай гына да түгел, республикада җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясенең шактый өлеше илнең башка төбәкләренә җибәрелә, экспортка чыгарыла. Болар барысы да – агросәнәгать хезмәткәрләре ирешкән казаныш.

ЭКСПОРТ ҺӘМ ЯҢА САТУ БАЗАРЛАРЫ ТУРЫНДА

– Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, АСК хезмәткәрләре алдында чыгыш ясаганда, республика бөтен Идел буе өчен халыкара сатып алулар башкарыла торган азык-төлек хабы әверелергә тиеш, дигән иде. Бурыч үтәлерлекме?

– Ул инде үтәлү стадиясендә. Ноябрь башына Татарстан агросәнәгать комплексы продукциясен экспортлау күләме 361,7 млн АКШ долларын тәшкил итте. Сатып алулар географиясе 52 илне үз эченә ала. Татарстан Республикасының 258 компаниясе чит илләргә май ризыкларын, бөртекле-кузаклылар, җитен орлыгы, спирт, азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгате продукциясен, шулай ук ит, сөт һәм бөртеклеләрне чыгара. Бөртекле культуралар гына да 47,1 мең тоннадан артык озатылды инде. Экспортерларга ярдәм йөзеннән Каспий төбәге, Персия култыгы, Һинд океаны һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия илләренә алып бара торган транспорт коридорлары төзелә. «Август» компаниясе Свияжск мультимодаль логистика үзәгендә заманча элеваторны эшләтеп җибәрде. Шундый ук проект Бөгелмә районында да гамәлгә ашырыла. 30 октябрьдә «Алабуга» МИЗның Тукай районындагы яңа терминалыннан Кытайга беренче контейнерлы поезд китте. Татарстан Рәисе билгеләп үткәнчә, әлеге киң колачлы проектлар логистиканы камилләштерергә мөмкинлек бирәчәк, Татарстан икътисадының үсеш ноктасына әвереләчәк.

– Әмма бөтен Идел буеның азык-төлек хабына әверелү өчен, мөгаен, безгә башка төбәкләргә караганда күбрәк җитештерергә кирәктер?

– Әлбәттә, ләкин бу яктан да республиканың тоткан урыны нык. Тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе күләме буенча Татарстан Идел буе федераль округында беренче урында һәм Россия Федерациясенең барлык субъектлары арасында беренче бишлеккә керә. Илебездәге авыл хуҗалыгы җирләренең ике процентын биләгән республика, хуҗалык итүнең барлык категорияләрен кертеп исәпләгәндә, авыл хуҗалыгы продукциясенең 3,5 процентын җитештерә. Татарстан сөт саву һәм мөгезле эре терлекнең сугым ите (тереләй авырлыкта) җитештерү буенча – беренче урында, бәрәңге игү буенча икенче урында тора. Шулай ук терлек ите һәм кош ите, йомырка җитештерү һәм шикәр чөгендере үстерү буенча тотрыклы рәвештә беренче унлыкка керә. Игенчеләр үз позицияләрен бирергә җыенмый, киресенчә, алга таба да үсү, җитештерүне һәм эшкәртүне арттыру бурычы тора. Соңгы биш елда республиканың агросәнәгать комплексына салынган шәхси инвестицияләр 146,2 млрд сум тәшкил итте, шул исәптән авыл хуҗалыгына – 122 млрд сум.

БӨРТЕКЛЕЛӘРНЕ ИҢ КҮП БУА, ТӘТЕШ ҺӘМ АРЧА РАЙОННАРЫ СУКТЫРДЫ. «ЧЫНЛЫ», «КАМА БЕКОНЫ», «ВАХИТ» АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕ, ШУЛАЙ УК «АГРОКӨЧ», «ЧИСТАЙ», «АВГУСТ-АГРО», «АК БАРС ХОЛДИНГ» ҺӘМ «КЫЗЫЛ ОКТЯБРЬ» АЛДЫНГЫ АГРОХОЛДИНГЛАРЫ КҮРКӘМ НӘТИҖӘЛӘРГӘ ИРЕШТЕ.



– «Ростки» Россия-Кытай форумы безнең агросәнәгать комплексының экспорт потенциалы үсешенә этәргеч булырмы?

– Быел форумның беренче көнендә үк Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән Синьцзян җитештерү-төзелеш корпусының авыл хуҗалыгы һәм авыл эшләре идарәсе арасында килешү имзаланды. Без, алдынгы технологияләргә таянып, томат һәм югары сыйфатлы соя үстерү өлкәсендә хезмәттәшлек итүгә, суны бәрәкәтле куллана торган сугаруның демонстрацион проектларын алга этәрүгә, шулай ук тышкы сәүдә операцияләрендә агросәнәгать комплексы продукциясе ассортиментын киңәйтүгә кагылышлы ниятләрне җиткердек. Менә шундый нәтиҗәләр.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘГЕ РЕКОРДЛАР ҺӘМ ҮСЕШ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ТУРЫНДА

– Узган ел Татарстанда беренче тапкыр рекордлы 2 млн 187 мең тонна сөт савып алынды. Быелга фаразлар нинди?

– Быелгы планнарда – 2 млн 263 мең тонна, һәм күрсәткечләргә караганда моңа ирешеп булыр кебек. Мәсәлән, сигез айда барлык категория хуҗалыкларда 1,5 млн тоннадан артык сөт савып алынган. Бу узган елның шушы чорына караганда 59,6 мең тоннага күбрәк. 14 ноябрь мәгълүматларына караганда, Татарстанда тәүлеклек сөт җитештерү узган елгыдан 142,8 тоннага артыграк. Кукмаралылар республика районнары арасында беренче булып тәүлеклек савымны 500 тоннага җиткерде. Әтнә, Балтач һәм Саба районнары көн саен 300 тоннадан артык сөт савып ала. Алдынгылар арасында Минзәлә районы да бар – алар эре мөгезле терлекнең баш саны һәм ит җитештерү буенча иң зур үсешкә иреште.

– Ә Россиянең кайбер төбәкләрендә күзәтелгән атланмайга кытлык безгә янамыймы?

– Күргәнебезчә, бездә атланмай белән өзеклекләр булмады. Һәм була да алмый. Татарстанда аны куллануга караганда җитештерү күбрәк. Сигез айда 14,3 мең тоннадан артык май эшләнде, ә республика эчендә куллану 10 мең тоннадан азракны тәшкил итте. Татарстанда сыер мае җитештерү кимеми, киресенчә, арта бара. Бездә сатылмаганы читкә чыгарыла, белгәнегезчә, республикада чимал кытлыгы да күзәтелми. Әйе, атланмайга бәяләр артты, әмма монда продукциянең үзкыйммәтенең күтәрелүе чагылыш таба. Ә үзкыйммәт чималга, логистикага, энергиягә бәяләр күтәрелү аркасында арта.

– Республика ел саен сөт җитештерүне нәрсә хисабына арттыра?

– Алдынгы технологияләр, тармакны актив цифрлаштыру, савым сыерларының сыйфатын яхшырту, дәүләт ярдәме, ниһаять, инвестиция проектларын эзлекле рәвештә гамәлгә ашыру – болар, мөгаен, даими үсешнең төп чыганаклары дыр. Терлекчелектә, аерым алганда, һәр җирдә көтү белән идарә итү һәм ашату системалары кертелә, терлекнең цифрлы паспорты ясала, регламентларны мониторинглау һәм тикшереп тору гамәлгә ашырыла. Ә тармакка ярдәм итүнең нәтиҗәле ысулларына таянып, быел 7 120 башка исәпләнгән 9 сөтчелек комплексы эшләтеп җибәрелде. Тагын 26,5 мең сыерга исәпләнгән 35 инвестиция проекты гамәлгә ашыру стадиясендә, алар 2025–2026 елларда төгәлләнәчәк. Болар барысы да өстәмә 100 мең тонна сөт алырга мөмкинлек бирер, дип уйлыйбыз.

АГРАР ТАРМАКНЫ ЦИФРЛАШТЫРУ

– Тармакны алга җибәрү чыганакларының берсе буларак цифрлаштыруны атадыгыз. Бу киләчәккә каралган бурычмы?

– Бу бүгенге көн бурычы, аннан да бигрәк, аны гамәлгә ашыру белән без берничә ел уңышлы шөгыльләнәбез. Нәтиҗәләр дә күзгә күренерлек. РФ Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төзелгән агросәнәгать комплексы өлкәсен цифрлы трансформацияләү рейтингында Татарстан лидер санала, Ямал-Ненец АО, Пенза, Ленинград һәм Кострома өлкәләре бездән соң бара. Бүген цифрлы технологияләр Татарстан авыл хуҗалыгының төрле тармакларында кулланыла. Үсемлекчелектә, мәсәлән, геомәгълүмат һәм метеомониторинг системалары, спутникны мониторинг. Әйткәнемчә, терлекчелектә – көтү белән идарә итү һәм ашату системалары, терлекнең цифрлы паспорты. Бүген эшкәртү юнәлешендә ясалма интеллект кулланган линияләр һәм системалар актив эшли. Авыл хуҗалыгын цифрлаштыру уңышны арттырырга, чыгымнарны киметергә һәм глобаль чакырулар фонында илебезнең агросәнәгать комплексы позицияләрен ныгытырга ярдәм итә торган чынбарлык. Бүген Татарстанның агросәнәгать комплексы – үсеш потенциалы яхшы булган югары технологияле тармак. Һәм иң мөһим бурычларның берсе – тупланган тәҗрибәне башка төбәкләр белән уртаклашу, алдынгы технологияләрне тарату. Бу уңайдан Казан аграр университетының «Агробиотехнопаркы» үз сүзен әйтер, дип уйлыйм. Ул август аенда РФ авыл хуҗалыгы министры Оксана Лут катнашында ачылды. «Бу уникаль проект укыту-тәҗрибә хуҗалыгы форматын торгызуга юнәлдерелгән, – дип билгеләп үтте Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов. – Ул селекция һәм орлыкчылыкта алдынгы тәҗрибә алмашуны күздә тоткан федераль мәйданчык булачак».

АВЫЛГА ДӘҮЛӘТ ЯРДӘМЕ ТУРЫНДА

– Аграрийларга дәүләт ярдәме сакланамы?

– Бюджетның чикләнгән булуына да карамастан, республика бюджетыннан да, федераль бюджеттан да ярдәм чараларын саклап кала алдык. Бу максатларга барлыгы 13,7 миллиард сум бүлеп бирелде, шул исәптән 2,8 миллиард – РФ бюджетыннан һәм 10,9 миллиард – ТР бюджетыннан. Республикада хуҗалык итүнең кече формаларына аерым игътибар бирелә, алар республика тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысын диярлек җитештерә. Авыл хезмәтчәннәрен котлаганда Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, фермерлар, җирдә эшләүдән тыш, авыл тормышын, мәдәниятен һәм туган телен саклау буенча миссияне дә, кече ватаннарында социаль бурычларны да намус белән үтиләр. 2024 елда хуҗалык итүнең кече формаларына ярдәм 1,3 млрд сумга якын тәшкил итте. Бу акчалар уңайлы эш шартлары өчен инфраструктураны үстерүгә, кече һәм урта эшкуарлык өлкәсендә эшләүчеләр санын арттыруга тотыла.



– Авыл хезмәтчәннәренең тормыш сыйфатын яхшырту өчен нинди проектлар гамәлгә ашырыла?

– 2020 елдан республикада «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы гамәлгә ашырыла. Максаты – авыл халкының торак шартларын яхшырту, авылны социаль-мәдәни көнкүреш объектлары белән тәэмин итү, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасын камилләштерү. Алдагы елларда бу максатларга 11 млрд сум акча салынды, быел – 5 млрд сумнан артык. Республикада беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү камилләштерелә, мәдәни үзәкләр һәм спорт мәйданчыклары төзелә, су белән тәэмин итү, яктырту һәм башкалар яхшыра.

Авылга булышу – беренче чираттагы бурычыбыз. АСК хезмәткәрләре ярдәмендә Татарстанның авыл хуҗалыгы үзенең тотрыклы үсешен саклый, республика иминлегенең һәм алга китүенең нигезе булып тора. Илнең фидакарь хезмәте батырлыкка тиң булган авыл хезмәтчәннәреннән дә ышанычлырак таянычы юктыр. Агымдагы елда килеп туган катлаулы шартларга карамастан, Татарстан аграрийлары, тармакның өзлексез эшләвен тәэмин итеп, аның тотрыклы үсешен саклап калып һәм барлык төп юнәлешләр буенча җитештерү күләмнәрен сизелерлек арттыруга ирешеп, югары профессионализм үрнәге күрсәттеләр. Т

AGRATOR DISK

AGRATOR DISK 9000
AGRATOR DISK 12000

ДИСКЛЫ ЧӘЧҮ КОМПЛЕКСЛАРЫ

РЕКЛАМА

AGROMASTER

www.pk-agromaster.ru

Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы, Тукай ур., 33 а, e-mail: agromaster@mail.ru
тел: 8 (85556) 2-39-08, 2-43-59, сот.: 8-939-396-83-44

ЭДВАРД АБДУЛЛАҖАНОВ, КДЭУ ректоры: «ГОРУРЛАНЫРЛЫК КАЗАНЫШЛАРЫБЫЗ БАР!»

Владимир Путинның Рәхмәт хаты, «Приоритет-2030» программасының иң яхшы тәҗрибәләре конкурсында җиңү, Татарстанда беренче университет ана һәм бала бүлмәсе, шулай ук республика һәм ил күләмендә уникаль проектларны уңышлы гамәлгә ашыру – Казан дәүләт энергетика университетының 2024 елдагы казанышларының кайберләре генә болар.

КДЭУ яңа уку елын көчле позициядән башлаган: быелга бүленгән 2 меңнән артык бюджет урыны өстәмә имтиханнар үткәрмичә дә тулган. Бу Казан энергоуниверситеты дипломының абруе һәм хезмәт базарында аны тәмамлаучыларга ихтыяҗның зурлыгы турында сөйли. КДЭУның беренче курс студентлары арасында быел беренче тапкыр Россиядәге барлык 89 төбәкнең (шул исәптән дүрт яңасының да) вәкиле бар.

Казан энергетика университетында инфраструктура һәм матди-техник база даими камилләштерелә: тулай торакларда һәм уку корпусларында капиталь ремонт үткәрелгән, бөтен җирдә җиһазлар тулысынча яңартылган, аудиторияләрдә цифрлы мультимедиа җиһазлары куелган.

КДЭУ җитәкчелеге яшьләр сәясәтенә зур игътибар бирә – студентларның күп инициативалары уңышлы гамәлгә ашырыла һәм яңа, югарырак статуска ия була. 2009 елда югары уку йорты эчендә оештырылган «Яз гүзәле» мәдәни-мәгариф проекты быел федераль дәрәҗәгә чыккан. Россиянең төрле төбәгеннән 100дән артык гариза кабул ителгән, ә «Алтын калфак» бүләгенә Самара дәүләт социаль-педагогика университеты студенткасы лаек дип табылган.

КДЭУда Гаилә елында уздырыла башлаган «Гаилә энергиясе» интеллектуаль фестивале шул ук елны республика статусын алган һәм Татарстанның дүрт районында яшәүчеләрне җәлеп иткән.

БРИКС саммитының эш программасы кысаларында Россия Федерациясе энергетика министры Сергей Цивилёв Казан дәүләт энергетика университетында булган һәм биредә Татарстанда беренче университет ана һәм бала бүлмәсен ачуда катнашкан. Фәнни эзләнү һәм тикшеренүләрен дәвам итә алсыннар өчен, анда яшь ата-аналарга квалификацияле ярдәм күрсәтелә икән. Сергей Цивилёв шулай ук Казан дәүләт энергетика университетында электр энергетикасы тармагындагы «Таврида Электрик» компаниясе белән берлектә «Энерджинет» үзәгенең Energynet.Lab уникаль лабораториясен дә ачкан.

2024 елның апрелендә РФ Президенты Владимир Путинның «Бүләкләү турында» карары белән КДЭУ коллективына «фән-педагогика эшчәнлегендәге казанышлары һәм квалификацияле белгечләр әзерләүләре өчен» рәхмәт белдерелгән.

– Әйе, горурланыр уңышларыбыз бар. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм республика хөкүмәте, алдынгы энергетика компанияләре ярдәме белән, бөтен коллективның тырышлыгы нәтиҗәсендә бүген безнең университет Россиядәге техник югары уку йортлары арасында әйдәп баручылардан берсенә әйләнде, – ди КДЭУ ректоры Эдвард Абдуллаҗанов.

Быел Казан энергоуниверситеты «Үзебездә эшләнгән югары технологияле продукцияне сынау һәм вак сериялап җитештерү үзәге» проекты белән «Приоритет-2030» программасының иң яхшы тәҗрибәләре проекты марафонында җиңгән. Ул фәнни эшкәртмәне инде тулысынча әзер үрнәк дәрәҗәсенә җиткерү мөмкинлеген бирә, аны шунда ук җитештерү партнёрларына тәкъдим итеп була.

Моннан тыш, КДЭУда «Приоритет-2030» программасының башка стратегик проектлары да гамәлгә ашырыла. «Татнефтехиминвест-холдинг» АҖ Директорлар советының 24 ноябрьдә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов катнашында үткән утырышында КДЭУ галимнәре эшләгән илдә беренче мобиль водород салу станциясе тәкъдим ителгән.

Энергетиклар көне һәм Яңа ел бәйрәме алдыннан КДЭУ җитәкчелеге һәм коллективы һәрбарчагызга яктылык, җылылык һәм бетмәс-төкәнмәс энергия тели! Барлык хыялларыгыз да тормышка ашсын! Сәламәтлек, уңышлар һәм кояшлы күтәренке кәеф юлдаш булсын сезгә!

Фотолар КДЭУ матбугат хезмәтеннән алынды. РЕКЛАМА

220 ел

КАЗАН ТАРИХИ

СССРда 1954 елгы почта маркасы. В. И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университетының 150 еллыгы. Университет бинасы

2004 елгы почта маркасы. В. И. Ульянов-Ленин исем. Казан дәүләт университетының 200 еллыгы. Университет бинасы

Россия Банкының 2005 елгы алтын тәңкәсе, 50 сумлык («Казанның 1000 еллыгы» сериясеннән)

Александр I, император. 1804 елның 5 (17) ноябрендә Казан Император университеты ачылышын раслау турындагы Грамотага һәм уку йорты Уставына кул куя.

Николай Лобачевский
Беренче Евклидча булмаган геометрияне ача (XIX гасырның 20–30 нчы еллары). Лобачевский геометриясе асылда меңъ еллар дәвамында өстенлек иткән фәнни карашларны җимерә, геометрия, математика һәм гомумән фән үсешендә яңа эпоханы башлап җибәрә.

Николай Зинин
1842 елда беренче мәртәбә анилин синтезлана, әлеге ачыш нәтиҗәсендә анилин-буяу сәнәгатенә һәм дарулар җитештерүгә нигез салына.

Карл Клаус
1844 елда Казан университетында яңа химик элемент ачыла, аны Россия хөрмәтенә «рутений» дип атыйлар. Рутений – патша Россиясендә ачылган бердәнбер химик элемент һәм Россия/СССРда ачылган бердәнбер табигый химик элемент.

Александр Бутлеров
Органик матдәләрнең химик төзелеше теориясен ача. Бу ачыш органик матдәләр химиясе өчен органик булмаган матдәләр химиясендә Д.И. Менделеевның периодик таблицасына тиң әһәмияткә ия.

Фото: commons.m.wikimedia.org, ru.wikipedia.org

УНИВЕРСИТЕТЫ: ШӘХЕСЛӘР

Александр Арбузов
Фәндә яңа – фосфорорганик кушылмалар химиясе юнәлешенә нигез сала.

БҮЛӘКЛӘР

«Татарстан Республикасы каршындагы казанышлар өчен» ордены – 2019 елда тапшырылган

Ленин ордены – 1979 елның 23 октябрендә тапшырылган

Хезмәт Кызыл Байрагы ордены – 1955 елның 11 июлендә тапшырылган

Евгений Завойский
1944 елда Казан университеты лабораториясендә электрон парамагнит резонансы күренешен ача. Әлеге ачыш тулы бер фән – магнит радиоспектроскопиясенә башлангыч бирә.

Иван Бодуэн де Куртенэ
XIX гасырның 70–80 нче елларында Казан лингвистика мәктәбенә нигез сала. Казан мәктәбенең күп кенә идеяләре, структур лингвистика, морфонология, лингвистик типология, психолингвистика үсешенә этәргеч биреп, үз заманын узып китә.

Иван Симонов
1819–1821 елларда җир шары тирәли беренче экспедициядә катнаша. Нәтиҗәдә Антарктида ачыла, материк фәнни яктан өйрәнелә башлый.

Александр Самойлов
Электрокардиографиягә нигез салучыларның берсе. Электрофизиологиягә караган хезмәтләре дөнья күләмендә таныла. Электрофизика мәктәбен оештыручы, Россиядә беренче мәртәбә электрокардиограмма төшерүче галим.

Семён Альтшулер
Казанда радиоспектроскопия һәм квант электроникасы фәнни мәктәбен оештыра. Акустик парамагнит резонансы идеясен әйтә һәм үстерә.

Университетта төрле елларда Владимир Ульянов-Ленин, язучылар Сергей Аксаков, Лев Толстой, Павел Мельников-Печерский, Велимир Хлебников, композитор Милий Балакирев, рәссам Валерий Якоби һ.б. укыган.

ИМПЕРАТОР, ДӘҮЛӘТ, ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ

Фотолар проект авторлары архивыннан

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР

Казан университетына – 220 ел!

Ул эшләгән дәвердә бередә миллионлаган студент белем алган. Кемнәрдер үз өлкәләрендә танылган белгеч булып җитешкән, исемнәре бөтен дөньяга танылганнары да бар араларында. Һәр факультет, һәр белгечлек юнәлеше үзенең шундый йолдызлары белән мактана, горурлана ала. Күпчелеге юбиляр университетны тәмамлаучылардан торган «Татарстан» редакциясе дә «КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР» проектын башлап җибәрә.

Ел буена без сезне, кадерле укучыларыбыз, иң кызыклы шәхесләр белән таныштырып барырга тырышырбыз. Алар укыган елларда университет нинди булган, бередә тупланган белем тормышларында, эшләрендә үз урыннарын табарга ничек ярдәм иткән – барысын да беләчәкбез. Аларга (безгә дә) дөрес юл күрсәткән мөгаллимнәребезне дә җылы сүз белән искә алырбыз. Бераз сагышланырбыз да. Казан университеты – бик күп татарстанлы өчен альма-матер бит. Татарстанлылар өчен генәме соң?! Россиянең һәр гаиләсендә һичшиксез Казан университетын тәмамлаган кеше табылачак!

Бу турыда «Татарстан» журналының 11 нче санында да (2024 ел) укый аласыз.

ПРОЕКТ АВТОРЛАРЫ

Казан университетын тәмамлаучылар:

Татьяна Челышева

Әскәр Сабиров



Руфия Рәхмәтуллина

Фәридә Хәбибуллина

Луиза Шарова

Евгения Зыкова



Рәшит Хәйретдинов

Анастасия Шахерзад

Виктория Майорова

шулай ук:

Ирина Морозова

Игорь Глушков



Дмитрий Сивков

Виктория Зубова

КДУның теоретик физика факультеты студентлары. Югары рәттә сулдан беренче – Кев Салихов.

Фотолар Кев Салихов архивыннан

Кев Салихов үзенең аспирантлары белән.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
КЕВ САЛИХОВ

Евгения Чеснокова

3 ноябрьдә, үзенә 88 яшь тулган көнне, РФА академигы, физика-математика фәннәре докторы Кев Салихов Американың Денвер шәһәрендә ел саен халыкара физика симпозиумын оештыручы профессор Гарет Итоннан хат ала. «Мин сезнең җырлавыгызны хәтерлим әле, – дип яза профессор. – Кайчандыр без үзебезнең фәнни җыелышта сезнең туган көнне бәйрәм иткән һәм торт белән сыйланган идек».

«Кайчандыр» дигәне 1996 ел була, ул вакытта парамагнетикларда спин системалары динамикасын өйрәнү өлкәсендә эшләүче галим Кев Салиховка Денвер симпозиумында ЭПР (электрон парамагнит резонансы) халыкара җәмгыятенең алтын медален тапшыралар. Ул – әлеге медальне алган бердәнбер Россия галиме.

Тантанадан соң банкетта Кев Салихов, барлык кунакларны гаҗәпләндереп, татарча үзенең яраткан «Кара урман» җырын җырлый да инде.

– Кайвакыт көтелмәгән хәлләр була, нәрсәдер әйтергә кирәк, ә мин моңа бөтенләй әзер түгел, – дип аңлата ул. – Менә шундый вакытларда мин җырлыйм. Һәм бермәлне, җырлаган чагымда, үземне бик бирелеп тыңлауларына игътибар иттем. Шуннан бирле мин бу алымнан файдаланам. Шулай ниндидер чарада танылган җырчыбыз Илһам Шакировны очраттым. Ул «Кара урман»ны искиткеч шәп җырлый иде бит. Аңардан кайчакта бу җырны җырларга рөхсәт итүен үтендем. Ул рөхсәт итте. Шул рәвешле татар халык җыры минем ышанычлы ярдәмчемә әйләнде.

КИЧЕКТЕРЕЛГӘН ОЧРАШУ

Күз алдыгызга китерегез, сезгә республика Президенты шалтырата, иртәгә кунакка киләм, ди. Ә сез: «Иртәгә эшем бар шул», – дип җавап бирәсез...

Кев Салихов белән шулай була. Ул Россия Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Завойский исемендәге Казан физика-техника институты директоры булганда, аңа Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев шалтырата һәм аларның институтына киләсе килүен әйтә. Мәсәлән, чәршәмбе иртән...

– Һәм мин аңа әйтәм: бездә һәр чәршәмбе 9:30 сәгатьтә институт семинары башлана. Әгәр сез башка көнне килә алмыйсыз икән, безгә бу атнада семинарны үткәрмәскә туры киләчәк. Әмма кунакка килү вакытын үзгәртә алсагыз, бик рәхмәтле булыр идек, – дип искә ала Кев Миңнулла улы. – Ул озак уйлап тормады, икенче көнне билгеләде. Шәхес шул ул Минтимер Шәрипович, ә!

Без үз нәүбәтебездә шуны әйтә алабыз: галимнәребез дә нинди бит! Алар өчен фәннән дә мөһимрәк беркем дә, бернәрсә дә юк!

Хәтта республика башлыгының да эш графигын үзгәртергә мәҗбүр иткән семинарның ни өчен шулкадәр мөһим булуы хакында исә без бераз соңрак сөйләрбез.

УКЫРГА, УКЫРГА ҺӘМ УКЫРГА

1954 елда Кев Салихов, КДУ физика-математика факультетының математика бүлегенә укырга керергә дип, Казанга килә. Укыганда математика аның иң яраткан дәресе була. Тик юлында аның белән бер мәктәпне тәмамлаган бер кыз очрый. «Син нәрсә, малайлар барысы да физикка укый!» – ди ул.

– Шулай итеп мин физик булдым, – дип елмая академик Салихов. – Уку чорында иң яраткан шөгылем – китапханәнең уку залына бару. Лекцияләр бетүгә, мин шунда йөгерәм һәм ябылганчы утырам. Дусларым минем кайда икәнемне һәрвакыт белә иде.

Моннан тыш, укуның беренче көннәреннән үк мине курсның комсоргы итеп сайладылар. Мин бу эшкә зур энтузиазм белән алындым. Аннары университетның комсомол комитетына сайладылар, уку секторы өчен җавап бирдем. Хәтерлим әле, икеле капчыклары, шул исәптән спорт аркасында укуларын калдыручылар белән көрәшергә туры килде. Бервакыт ректор Михаил Нужин катнашында ниндидер утырыш булды, һәм мин анда безнең курста икелегә укучы бер волейболчыны тәнкыйтьләдем. Һәм кинәт Нужин аны яклап чыкты... Ректорның үзенең дә волейбол уйнарга яратуын мин соңыннан гына белдем. Бу минем өчен үзенә күрә бер сабак булды.

Безнең комсомол комитеты секретаре Лев Бажанов иде. Аннары аны Мәскәүгә комсомол линиясе буенча эшкә чакырдылар, һәм ул мине дә үзе белән алып китәргә теләде. Тик мин инде бу вакытта диплом яза идем, һәм гомумән фән белән шөгыльләнү миңа бик ошый иде. Шул рәвешле мин, һич икеләнми, фән юлын сайладым.

БЕЛЕМЕ БУЛГАН МЕҢНЕ ЕГАР...

Гомумән, ул кечкенәдән үк укуга омтыла. Сугыш вакытында аларның Башкортстандагы кечкенә генә татар авылына Ленинградтан эвакуацияләнүчеләрне урнаштыралар. Бәләкәй Кев ул чакта – рус телен, ә эвакуацияләнгән

малай, аның яшьтәше, татарча белми. Һәм алар бер-берсен телгә өйрәтә.

– Авылда мәктәп юк иде, шуңа күрә мине күрше авылдагы рус мәктәбенә укырга керттеләр, – дип искә ала Кев Миңнулла улы. – Дүртенче сыйныфтан соң исә эти мине районның иң яхшы мәктәбенә илтеп куйды. Шуннан бирле фатирда яшәдем. Гаиләдә алты бала үстек, эти-әниебез барыбызга да яхшы белем бирергә тырышты.

Башта татар авылыннан килгән малайны мәктәпкә алырга теләмиләр. Ә аннары аның табелен гел бишле билгеләре генә бизи.

– Дәрес әзерләмәгән вакытымны хәтерләмим, – дип сөйли академик Салихов. – Соңрак, башка балаларга карап, болай да мөмкин булуын белдем. Тик мин моны аңламый идем. Минем район мәктәбенә эләгүем бик шәп булды, анда укытучылар бик яхшы иде. Ә тарих укытучысы Татьяна Константиновна Максимова мине укырга, уйларга һәм анализларга өйрәтте.

ФӘННИ БОРЫЛЫШЛАР

Ул дүртенче курста укыганда, илдә полимерлар физикасын үстерү турында карар кабул ителә. Физматта яңа белгечлек ачарга һәм шуңа иң яхшы студентларны сайлап алырга карар кылалар. Исемле стипендиат Салиховны КДУның радиоспектроскопия һәм квант электроникасы кафедрасы мөдире Семён Альтшулер чакыртып ала.

– Семён Александрович миңа Ленинградка, Фәннәр академиясенең Югары молекуляр кушылмалар институтына барып, моңарчы белмәгән полимерлар буенча әзерлек үтәргә тәкъдим итте, – дип искә ала Кев Салихов. – Шуның белән ул минем язмышымны үзгәртте, дип әйтергә мөмкин. Әгәр мин КДУда калсам, мөгаен, гади укытучы булыр идем. Ә Ленинградта мин бик яхшы лабораториягә эләктем, анда чын-чынлап фән белән «чирли» башладым һәм инде Казанга кире кайтырга теләмәдем. Соңрак, мин Новосибирск академшәһәрчегендә эшләгәндә һәм инде электрон парамагнит резонансы белән шөгыльләнгәндә, Семён Александрович, әгәр мин докторлык диссертациясен якларга телим икән, моны Казанда эшли алачагымны әйтте. Мин ул вакытта докторлык турында уйламый да идем. Ләкин аның тәкъдименнән соң яңа бурычларны актив хәл итә башладым, нәтиҗәдә диссертацияне КДУда якладым. Ә Альтшулер минем оппонентым булды. Шул рәвешле ул кабат минем фәнни тормышыма үзгәреш кертте.

ЧЫГЫШ ЯСЫЙ ДА ЙОКЫГА КИТӘ

Бервакыт Кев Салихов үзе өчен бик мөһим чарада йокыга китә. Чөнки аның үзе өчен шундый мөһим булачагына ышанмый...

Бу үзгәртеп кору чоры, бөтен җирдә кинәт җитәкчене сайлап кую актив үткәрелә башлаган чак була. Новосибирск академшәһәрчеге хезмәткәре Кев Салиховка КФТИ директоры сайлауларында катнашырга тәкъдим итәләр.

– Мине Новосибирскидан Уфага, Мәскәү янындагы Пущинога, Сәмәркандка, хәтта Америкага да чакырып карадылар, – дип сөйли Кев Миңнулла улы. – Әмма миңа Новосибирскида да бик яхшы иде. Мин ул чагында инде Ленин премиясен алган, шулай булгач, Россия фәнендә соңгы кеше түгел. Өстәвенә, мин беркайчан да беркем белән дә җитәкчелек итмәдем, хәтта лаборатория мөдире дә булганым юк иде. Ләкин монда башка бит – туган Казаным чакыра...

Әйтергә кирәк, мин Казан институты турында уйлаганда беркадәр уңайсызлык тойдым. Ул вакытта без Новосибирскида импульслы ЭПР өлкәсендә дөнья фәне күзлегеннән караганда Казаннан күпкә алга киткән идек. Ә бит Завойский парамагнит резонансы күренешен нәкъ менә Казанда ачкан... Әмма аның варислары, Казан физика профессорлары, үз эшләрендә химияне, биологияне санга сукмауның корбаны булган, моны игътибарга лаек түгел, дип санаган. Ә бит нәкъ менә ЭПР химия һәм биологиядә искиткеч кулланылыш таба.

Һәм мин кайтырга уйладым. Ә сайлау алдыннан инде институтныкылардан кемнедер сайларга уйлаганнарын ишеттем. Шуңа күрә коллектив алдында үз программам белән чыгыш ясаганда, мине барыбер сайламаячакларына ышанып, тыныч күңел белән аларга институт турында һәм ЭПР өлкәсендә Казан тикшеренүләре белән бәйле вазгыять турында уйлаганнарымның барысын да әйттем. Бик арыган идем, шуңа күрә башкалар чыгыш ясаганда йокыга киткәнмен. Тавыш бирү башлангач исә, бөтенләй чәй эчәргә чыгып киттем. Һәм кинәт шунда килеп, минем сайлануымны хәбәр иттеләр...

ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕ ҺӘМ ДУСЛАРЫ ТУРЫНДА

1985 елның көзендә Американың «Челленджер» шаттлында космоска очкан сигез астронавт арасында немец физигы Райнхард Фуррер да була. Аның белән бергә космоска галимнең Казандагы хезмәттәше Кев Салихов бүләк иткән матрешка да оча.

Чит ил коллегалары белән аралашу һәм дуслашу – Кев Миңнулла улы тормышының аерылгысыз өлеше.

– Мин Берлинның Ирекле университеты хезмәткәрләре белән тыгыз хезмәттәшлек иттем һәм дус идем. Алар мине фотосинтезның беренчел процессын ЭПР методлары белән тикшерүнең кызыклы өлкәсенә кертте, һәм аларның бездә булмаган һәм минем теоретик фаразларымны сынарга мөмкинлек биргән бик яхшы приборлар базасы бар иде.

Космик тикшеренүләргә күчкәнче, Фуррер шулай ук электрон парамагнит резонансы белән шөгыльләнде. Берлинга сәфәрләремнең берсендә аның университеттагы кабинетында эшләдем. Ул миңа: «Сиңа монда уңайлы булыр, дип өметләнәм», – дип язып калдырган иде.

Ә бервакыт аңардан тагын бер җылы хат алдым. Америкадагы хезмәттәшләре белән Аляска

өстеннән, Россия чикләре тирәсендә хосусый самолетта очканда, ул мине исенә төшергән һәм хат язарга булган икән...

Ул космоста берничә эксперимент әзерләгән, шуларның берсе авырлык югалту шартларында шәмнең ничек януын тикшерүдән гыйбарәт булган. Кызганыч ки, ул сынауларның нәтиҗәләрен белә алмадым. Очрашып фикер алышу өчен әле вакытыбыз күп, дип уйлый идем. Әмма ул авиаһәлакәттә һәлак булды...

КАҺВӘ КЛУБЫННАН – ИНСТИТУТ СЕМИНАРЫНА

Новосибирскидагы академшәһәрчектә эшләгән елларында Салихов бервакыт институттагы хезмәттәшләре белән каһвә клубы оештыра.

– Бу галимнәрнең формаль булмаган аралашуы иде, – дип искә ала ул. – Безгә үз эшебезнең нәтиҗәләре турында фикер алышу мөһим булды. Мин үзем, мәсәлән, теоретик, һәм миңа экспериментаторлар белән аралашу мөһим иде. Миндә ниндидер идея, эксперимент турында фикер туа гына әле, ә экспериментаторларның берсе, сынау үткәреп, инде нәтиҗәләрне хәбәр итә. Һәм проблема ачыграк аңлашыла башлый.

Директор булгач, ул бу идеяне институт семинарында тормышка ашыра. Нәкъ менә шуның өчен Татарстан Президенты белән очрашу вакытын үзгәртергә туры килә дә.

– Семинар – бик мөһим, – дип аңлата Кев Салихов. – КФТИда мондый нәрсә булмавы белән риза түгел идем. Атна саен семинар үткәрүне гамәлгә керттем, бу эш мәҗбүригә әйләнде. Бу һаман да шулай, хәзер исә институт Гыйльми советының фәнни сессиясенә әверелде. Һәр чәршәмбе унынчы яртыда Гыйльми совет әгъзалары һәм теләге булган һәркем конференц-залга җыела. Үз хезмәтләре турында сөйлиләр, фәнни проблемалар хакында фикер алышалар, чәй, каһвә эчәләр. Синең нинди тема белән шөгыльләнүең мөһим түгел, чөнки биредә барыбер үзең өчен файдалы мәгълүмат ишетә аласың. Бу тормыш та, уку да. Нәкъ менә шундый очрашуларда яңа белем аласың да инде.

«БЕР ГОРУРЛЫК ХИСЕ ЯНА МИНДӘ...»

2005 елда Завойский исемендәге КФТИ оештырылуына 60 ел тулуны бәйрәм итә. Шактый кеше чыгыш ясый, бик күп яхшы сүзләр әйтелә. Икенче көнне иртән институт директоры Кев Салихов янына урам себерүче һәм слесарь булып эшләүче бер хезмәткәр килеп: «Мин институтыбыз белән бик горурланам!», – ди.

– Мин бу вакыйганы әле дә бик дулкынланып искә алам, – ди безнең героебыз. – Без һәркем үзен физтехчы итеп тойган коллектив булдыра алдык!

Мин ул чакта үз-үземә, ЭПР тикшеренүләрендә безнең институт дөнья лидерлары өчлегендә булсын иде, дигән бурыч куйдым. Ахыр чиктә, бишлектә булса да ярый. Минемчә, без моңа ирештек.



Физика буенча Нобель премиясе лауреаты Жорес Алфёров Завойский исемендәге КФТИга килгән вакыттагы очрашу.





КДУ лабораториясендә фотосинтезның радиоактив продуктлары белән эшләү, 1960 ел.

Академик Тарчевский шәкертләре белән.

Фотолар Игорь Тарчевский шәхси архивыннан

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
ИГОРЬ ТАРЧЕВСКИЙ

Евгения Чеснокова

Бервакыт, 1950 нче еллар уртасында, КДУның төп бинасында ишегенә «Чит кешеләргә керү тыела» дип язылган кабинет пәйда була. Әлеге яңа биофизика лабораториясендә университет биологлары, СССРда беренчеләрдән булып, радиоактив изотоплар һәм радиохроматография кулланып, тикшеренүләр үткәрә. Лабораториянең мөдире аспирант Игорь Тарчевский була.

Өлкән сыйныфларда укыган чакта әтисе аңа Климент Тимирязевның «Солнце, жизнь и хлорофилл» дигән китабын бүләк итә. Игорь үзе мәктәптә химия белән бик кызыксына һәм химфакка керергә җыена. Әмма әтисенең бүләге бөтен фикерне чуалта.

– Тимирязев зур галим генә түгел, бәлки фәнне менә дигән итеп популярлаштыручы да булган. Кузәнәкләрдә кояш нурлары тәэсирендә ниләр баруын тасвирлаган әлеге китап мине шулкадәр мавыктырды ки, биофакка керергә ниятләдем, – дип сөйли академик Тарчевский. – Казан университеты мине фәнгә «очыртып» җибәргән старт мәйданчыгына әйләнде.

ЯҢА МЕТОДЛАР ҺӘМ АРТИСТ БАТАЛОВ ТУРЫНДА

– Университетны тәмамлагач, мине аспирантурада калдырдылар, – дип искә ала Игорь Анатольевич. – Ул чакта фәнни журналларның берсендә америкалы Кальвинның хезмәте басылды, анда галим фотосинтез вакытында углекислый газдан барлыкка килгән органик кушылмаларны беренче тапкыр радиоактив углерод ярдәмендә тасвирлаган иде. Һәм мин үсемлекләр физиологиясе кафедрасы мөдире Алексей Алексеевка фотосинтез химизмы белән шөгыльләнергә тәкъдим иттем. Әмма бу эшләр бары тик тамгалы атомнар – радиоактив углерод кулланып кына үткәрелә ала иде. Моңа радиометрия аппаратурасы, саклагыч җиһазлар, махсус җиһазландырылган бина таләп ителә... Әлбәттә инде, Алексей Михайлович миңа моның мөмкин түгеллеген аңлатты – СССРда ул чакта мондый методлар файдаланылмый иде диярлек.

Әмма минем тәкъдимем турында КДУ ректоры Михаил Нужин ишеткән, һәм ул аңа бик ошаган. Нужин үзе – математик, моңарчы биофак аңа мүкләнеп беткән факультет кебегрәк тоелган. Серкәч, җимешлек... Һәм кинәт – радиоактив изотоплар! Бу физика бит! Нәтиҗәдә бик тиз арада лаборатория өчен бүлмә дә табылды, күп акча бүленде, радиометрлар, саклагыч җиһазлар сатып алынды.

Әгәр болар эшләнмәсә, мин соңрак КДУда биохимия кафедрасы оештырмас, СССР Фәннәр академиясе академигы булмас, РФАнең Казан фәнни үзәге Биология институты директоры итеп чакырылмас идем. Алексеев кафедрасы өчен стандарт проблемалар белән шөгыльләнүче гади хезмәткәр генә булып калыр идем.

...Шул елларда «Девять дней одного года» фильмы чыга, анда да галимнәр радиация белән эшли. Һәм нигәдер студент кызлар Тарчевскийны фильмның баш герое Баталовка охшата. Алар лабораториягә агыла, эшкә комачаулый башлый. Галим имеш-мимеш таратырга мәҗбүр була: янәсе, радиоактивлык аркасында лабораториягә керү куркыныч һәм аның да, нурланыш алган Баталов героеныкы кебек үк, баласы булмаячак.

Шуннан соң гына тынычлап эшли башлыйлар. Әмма соңрак кемдер әлеге имеш-мимешне Тарчевскийның булачак «тёща»сына җиткерә, һәм ул кызын галимгә кияүгә чыкмаска үгетли.

ХАЛЫК ДОШМАНЫ УЛЫ

БЕРВАКЫТ фән докторы Тарчевскийга СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Космик биология һәм медицина ябык институтында бик перспективалы эш тәкъдим итәләр. Ул баш тарта. Моның берничә сәбәбе була. Тикшеренүләр юнәлешенең нык үзгәрүе нәтиҗәсендә яңа эшкә җайлашырга кирәк булуы, хезмәтләренең ачык матбугатта басылмаячагы һәм... әтисенең язмышы.

...1931 елда Омскида Игорь Тарчевский туганда, әтисе төрмәдә утыра торган була. Ул мәктәпкә укырга кергәндә халык дошманы улы санала, чөнки әтисе икенче тапкыр төрмәгә утыртыла.

– Ике тапкырында да ул яла буенча кулга алына, – дип сөйли Игорь Анатольевич. –

Гражданнар сугышы елларында Омскины Колчак яулап алганда, әти техник училище курсанты була. Аларны тимер юлларны төзәтергә җибәрәләр. Ә аннары, күп еллардан соң, кемдер «кирәкле урынга» хәбәр итә: янәсе, әлеге курсантлар Кызыл армиягә каршы сугышкан... Хөкем бик катгый буласы булган, бәхеткә, бер мөгаллим аны яклап чыккан, хакыйкатьне аңлата алган. Әтине тиз арада азат иткәннәр. Ә 1938 елда кабат кулга алдылар. Ул машина-сынау станциясендә эшли иде. Омскига килешү буенча Америкадан чылбырлы тракторлар кайтарткаччыннар, өйрәтер өчен белгеч тә җибәрелгән. Әлеге белгеч бераздан кире кайтып киткән, ә берничә елдан соң аның белән аралашканнарны Америка шпионнары дип кулга алганнар. Әти аның белән турыдан-туры аралашмаган да, аралашканнар белән генә элемтәдә булган. Әмма ул елларда гаепләү өчен шул да җитә. Әти төрмәдә ике ел утырды, аннары ирекка чыгарылды: НКВД җитәкчесе Ежовны Бериягә алыштырган чакта тоткыннарның бер өлешен азат иттеләр.

Аннары әтигә Чебоксар авыл хуҗалыгы институтында кафедра мөдире вазыйфасын тәкъдим иттеләр, һәм без шул шәһәргә күчендек. Тик әтине күзәтү туктамады. Космик институттагы шартлар, эш режимы белән танышкач, шуны аңладым: мин дә биредә күзәтү астында булачакмын. Әтием язмышын исемә төшердем дә баш тарттым...

ЯЛГАН ФӘНГӘ КАРШЫ

БЕРВАКЫТ, әле студент чагында ук, Тарчевскийга университеттан куу белән яныйлар.

– Мин студентлар фәнни түгәрәге старостасы идем һәм галим Лысенконы тәнкыйтьләп рәсми басмада басылган беренче мәкаләне тикшерергә булдым, – дип искә ала Игорь Анатольевич. – Икенче көнне дарвинчылык кафедрасы мөдире миңа янады: янәсе, мондый тәнкыйть өчен, бигрәк тә репрессияләнгән кеше улы, ике көн эчендә университеттан куылырга мөмкин. Әмма деканыбыз Михаил Васильевич Марков миңа каты бәрелмәде, шелтәләп кенә алды. Гомумән, студент еллары хәтеремә мөгаллимнәребезнең югары дәрәҗәдәге профессионал һәм зыялы булулары белән уелып калды. Алар әхлаклы тәрбиячеләр иде, безне киләчәк тормышка яхшы әзерләде.

Соңрак Игорь Тарчевский студентлары өчен үзе дә шундый Остазга әйләнә. Ул аларны ярата, аларга ышана.

«Безнең төркемгә көтелмәгән бәхет елмайды, – дип яза үзенең хатирәләрендә Татарстан Фәннәр академиясе әгъзасы, биология фәннәре докторы Ирина Лещинская. – Игорь Анатольевичны куратор итеп билгеләделәр. Без аңа барыбыз да гашыйк булдык. Бервакыт Игорь Анатольевич миңа яшереп кенә Жорес Медведевның Лысенко һәм Ко кылган «эшләр» турындагы китабын бирде. Мин аны йотлыгып укып чыктым, аеруча кызык урыннарына кат-кат әйләнеп кайттым. Ул болганчык елларда мондый әдәбият тараткан өчен иректән мәхрүм ителергә дә мөмкин иде...»

ФОТОСИНТЕЗ СЕРЛӘРЕ

БЕРВАКЫТ, 1957 елның кышында, КДУ биофагыннан бер төркем яшь тикшеренүче Обсерваториядәге биостанциягә килә. «Бу сәфәр минем хәтеремә гомерлеккә уелып калды, – дип укыйбыз биология фәннәре докторы, КФУның атказанган профессоры Людмила Хохлова хатирәләрен. – Фәнни түгәрәк җитәкчебез Игорь Тарчевский белән без чыршы ылысындагы фотосинтезны өйрәндек. Ылысларны колбаларга салып, кар өстенә резин көпшәләр суздык һәм алар буйлап ылыска радиоактив углерод изотобы булган углекислый газ кертә башладык. Һәм менә сенсация: сигез градус суыкта ылыста фотосинтез башланды! «Чыршы ылысының кышкы фотосинтезы» дигән мәкалә 1959 елда Бөтенсоюз фәнни конференциясе материалларында басылып чыкты. Күп еллар үткәч, әлеге нәтиҗәләрне чит ил галимнәре дә раслады. Шул рәвешле без, беренче курс студентлары, кечкенә генә ачышта катнаша алдык».

– Стресс шартларында фотосинтез химизмы минем кандидатлык һәм докторлык хезмәтләремнең темасы иде, – дип сөйли Игорь Тарчевский. – Бу саф теоретик тикшеренүләр гамәли, агротехник нәтиҗәләргә дә китерде. Ул чакта үсемлек чәчүлекләренең потенциаль продуктлылыгын яфракларның суммар мәйданы («яфрак потенциалы») буенча билгеләү методы кабул ителгән иде. Ә без хезмәткәрләребез белән бергә шуны күрсәттек: корылык тәэсирендә бодай үсентеләренең яфраклары иң алдан һәлак була, ә башак һәм сабак һаман яшел булып кала һәм фотосинтездан туктамый. Бу безгә чәчүлекләрнең потенциаль продуктлылыгын яфрак мәйданы буенча түгел, бәлки «хлорофилл потенциалы» буенча билгеләүне кертү мөмкинлеген бирде.

КАРЬЕРАДА ТӘҮГЕ ҮСЕШ...

БЕРВАКЫТ Игорь Чебоксардан 30 чакрым ераклыктагы бер авылда колхозда көтүче ярдәмчесе булып урнаша. Сугыш вакыты... Җәйге эссе көн, ул урман буенда ята да йокыга китә. Ярый әле үзе кебек көтүче малайлар уята – сыерлары качып бетә язган икән...

– Әлеге очрак исемә төшкән саен миңа бик оят, – ди Игорь Анатольевич. – Бу бит минем беренче эшем иде. Сугыш бара, ачлык-ялангачлык, ә бит колхоз миңа эшем өчен ризык бирә. Әмма, күрәмсең, минем

эшемнән канәгать калганнардыр, чөнки икенче елны инде беренче курсны бетермичә генә берүземә бозаулар көтүен ышанып тапшырдылар. Көтүче ярдәмчесеннән көтүчегә күтәрелү – минем беренче «карьера үсешем» шул булды.

КАЗАНГА ТУГРЫЛЫК

БЕРВАКЫТ Игорь Тарчевскийга СССР ФАнең Тимирязев исемендәге үсемлекләр физиологиясе баш институтында фотосинтез химизмы лабораториясен оештырырга тәкъдим итәләр. Фатир, башкалада теркәлү белән кызыктыралар... Моны белеп алган КДУ ректоры Михаил Нужин, биофизика лабораториясе мөдирен җибәрмәс өчен, шунда ук чаралар күрә башлый. КПСС ҮКның фән бүлеге аша башкаладагы институт директорына төбәкләрдән яхшы әзерлекле кадрларны үзенә алу омтылышы өчен шелтә белдерелә. Галимне җибәрмәс өчен, ректор биофакта биохимия кафедрасы ачарга тәкъдим итә, Игорь Анатольевич озак еллар буе аны җитәкли.

– Ул чакта без әлеге кафедрада укуның яңа программасын эшләдек, абитуриентларга укырга кергәндә математикадан имтихан бирдертә башладык – элегрәк биолог булырга теләүчеләр мондый имтихан бирми иде, һәм безгә бик көчле укучылар килә башлады, – дип сөйли академик Тарчевский. – Хәтеремдә әле, ике ел рәттән безнең кафедраның өлкән курс студентлары өлгереш буенча университетта иң яхшы төркемнәрдән булды. Кызганыч, мин университеттан СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Биология институтына директор булып китүнең икенче елында ук кафедра ябылды. Бермәлне аны кабат ачтылар, әмма хәзер университетта мондый кафедра юк.

Ә мин гомерем буе бары тик ике урында – Казан университетында һәм РФАнең Казан фәнни үзәгендә генә эшләдем.

ШӘКЕРТЛӘРНЕҢ ШӘКЕРТЛӘРЕНЕҢ ШӘКЕРТЛӘРЕ

БЕРВАКЫТ, моннан берничә ел элек, Казанда үсемлекләр физиологиясе җәмгыятенең Бөтенроссия съезды уздырыла. Анда Казаннан әлеге тармакта тикшеренүләр алып баручы бик күп биология фәннәре докторлары һәм кандидатлары чыгыш ясый. Әйтүләре буенча, барысы да – үсемлекләрнең күзәнәкләр сигнализациясе буенча Казан фәнни мәктәбен оештыручы академик Тарчевскийның укучылары, укучыларының укучылары яки укучылары укучыларының укучылары. Ул иллегә якын фән докторы һәм кандидаты әзерли, ә бер шәкерте – Александр Гречкин РФА академигы итеп сайлана. Шул рәвешле остазның эше үзенең шәкертләрендә дәвам итә.

Хатыны – филология фәннәре докторы, КДУ профессоры Татьяна Николаева белән.

СИГНАЛ СИСТЕМАЛАРЫ

БЕРВАКЫТ СССР Фәннәр академиясе, үсемлек күзәнәкләренең сигнал системаларын өйрәнгән өчен, академик Тарчевскийга биохимия өлкәсендәге Бах премиясен бирә.

– Үсемлекләр һәм патоген микроорганизмнар арасында даими көрәш бара, – дип сөйли үзенең тикшеренүләре турында Игорь Анатольевич. – Үсемлек күзәнәкләре үзләрендәге антенналар ярдәмендә дошман якынлашуын тоя һәм бу хакта сигналларны «төш»кә, ягъни генетик аппаратка тапшыра. Нәтиҗәдә саклагыч геннар «кабына» һәм сигналлар махсус «цех»ка тапшырыла, анда саклагыч аксымнар синтезлана башлый, шул исәптән үзенчәлекле «ракеталар» да – аларны күзәнәк дошманга төбәп ата һәм җиңә. Антенналар дошманның типларын аера һәм сигналларның тиешлесен «кабыза» ала. Шул рәвешле күзәнәк нәкъ менә шул дошманга каршы көрәштә нәтиҗәле булган саклагыч җавап стратегиясен сайлап ала. Соңгы елларда күзәнәкләр сигнализациясендә катнашучыларны агробиотехнологияләрдә һаман ешрак файдаланалар – алар белән үсемлекләрне эшкәртү өчен дә, сигнал аксымнары геннары күчерелгән трансген үсемлекләрдә аларның күләмен арттыру өчен дә.

Үсемлекләрнең стресс халәтендә, төрле уңайсыз шартларда үзләрен тотышын өйрәнүгә, сигнал системалары ярдәмендә аларның стресс факторларына җавап бирүен тикшерүгә мин бөтен гомеремне багышладым.

КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫН ТӘМАМЛАУЧЫЛАР
АНАСТАСИЯ ВӘЛИЕВА

Николай Коновалов

Анастасияне Казан университетына... атлар алып килә. Аңа борынгы халыкларның кыяда ясалган рәсемнәрен һәм ат сурәтләрен, атларның цивилизациягә йогынтысын өйрәнү ошый торган була... Һәм ул тарихчы-археолог белгечлеге ала. Университет белеме аңа үзенчәлекле һөнәрендә гаять файдалы булып чыга: Настя – тренер-берейтор, ягъни атларны иярдә җайдак йөртергә өйрәтүче белгеч.



Фотолар Анастасия Вәлиева архивыннан

БИЗНЕС ТҮГЕЛ, Ә ЯШӘҮ РӘВЕШЕ

– БЕРВАКЫТ син атларга гашыйк буласың һәм аларның саны ничек унбергә җиткәнен сизми дә каласың! – ди Анастасия.

Моннан алты ел элек Настя атларын, шәһәр ипподромыннан алып китеп, Татарстан тугайларына урнаштыра. Шулай итеп аның шәхси көтүлек проекты – Viking&Co ранчосы барлыкка килә.

– Ранчо – чөнки хайваннар табигатьтә, болында яши, – дип аңлата ул. – Бу хосусый агротуристлык проекты, кечкенә генә, зур бизнес түгел, аны яшәү рәвеше, яшәү мәгънәсе, дисәк, дөресрәк булыр. Монда атлар, сыерлар, ангор бөдрә кәҗәләре, казлар, асылташ кебек төрле төстәге йомырка салучы төрле токымлы тавыклар, көтүче коллилар һәм җигүле якут лайкалары хуҗа, хәтта кулга ияләшкән кеш тә бар. Алар барысы да – минем гаилә әгъзалары.

ДЖЕЙМС ХЭРРИОТ МОТИВЛАРЫ БУЕНЧА

БЕРВАКЫТ Настя Джеймс Хэрриот китапларын уку белән мавыга һәм андагы мохиткә гашыйк була. Үзенең ранчосында ул Хэрриот атмосферасын, кеше һәм табигать үзара тыгыз бәйләнештә булган дөньяны булдырырга тырыша. Бу дөнья шулкадәр тыныч һәм якты ки, аннан һич тә китәсе килми.

– Проект, асылда, күчмә, чөнки аның әлегә үз җире юк, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге барлык җирләр хосусый затлардан арендага алына, – ди Настя һәм, кулларын җәеп, арендага алынган киңлекләрнең чикләрен күрсәтә. – Хәзер атлар Рыжов хуторы гаилә фермасы җирләрендә яши. Хайваннар күченүләрне тыныч кабул итә. Күнектеләр инде. Иң мөһиме, даими ветеринария контроле булсын һәм аларның гаилә составы үзгәрмәсен. Корылмалар мобиль. Һава торышы бозылганда, хайваннар табигый тыныч урыннарда – урман полосаларында, чокырларда ышыклана...

БӘХЕТ ҺӘМ ГАРМОНИЯ ТУРЫНДА

БЕРВАКЫТ «Татарстан» журналына да Настяның хайваннары белән аралашу бәхете тәтеде. Без үзебезне чыннан да бик бәхетле хис иттек.

– Проектның мәгънәсе дә шунда: кешеләр (өлкәннәр һәм балалар) иректә яшәүче бәхетле хайваннар белән аралашсын, аларны тоярга һәм аңларга өйрәнсен иде, – ди Настя.

Ул үзен каравылчы, сакчы дип атый… Нәрсә сакчысы? Бәхет? Монда булып киткән кешеләргә иңгән гармония?

– Атлар – бик сизгер хайваннар, чын Гармония осталары, алар кешеләрнең энергетикасын үтәли тоя һәм аңлый. Алар белән аралашу өчен, билгеле бер сыйфатларга ия булу зарур. Алар моңа өйрәтә. Атлар белән аралашу кешене бик нык үзгәртә, ихтыяр көче, рух тәрбияли, – дип җавап бирә Гармония сакчысы.

ТЫНЫЧЛЫК ҺӘМ ИРКЕНЛЕК

БЕРВАКЫТ монда булып киткәч, сез барлык аралашуның хайваннар инициативасы буенча гына баруын аңларсыз. Алар ранчода бик иркен яши. Биредә кешеләр – аларның кунаклары, күзәтүчеләре генә.

Кунаклардан тыныч һәм куелган кагыйдәләрне хөрмәт итүләрен үтенәләр. Бу – аулактагы тынычлык утравы. Монда кешеләр ташкыны юк, атларны вакытлыча файдалануга биреп тору юк. Дуслары һәм Настя үзе өйрәткән, атларын ышанып тапшыра алган кунаклар гына атка атланып йөри ала.

Сезне ранчода беренче булып бөдрә ангор кәҗәләре – гаҗәеп Гуся һәм Руфь каршы ала. Алар болытка охшаган, чөнки бу – кәҗәләрнең мамык токымы.

Бүген Лидер шәһәр ыгы-зыгысыннан еракта яши. Күпләр өчен атлар дөньясы белән таныштыручы булып тора.

Аннан соң Альп кәҗәләре Изма, Руна, Цикада, Лилу килә. Бур кәҗәсе Конфетка ничек оста итеп агач яфрагы ашый алуын күрсәтә. Көтүнең башлыгы – Росинка кушаматлы сыер. Ул да иректә яши, үзенең мөгезле гаиләсен сукбай этләр һөҗүменнән кыю яклый.

Сүз уңаеннан, барлык хайваннарга да чип куелган. Закон буенча алар маркировкаланырга тиеш, монда аларга бирка урынына чип имплантацияләнгән.

ЛИДЕРНЫҢ КӨНЛӘШТЕРГЕЧ ПЕНСИЯСЕ

БЕРВАКЫТ ранчога Орел юртагы Лидер кайта. Элек ул Минтимер Шәрип улы Шәймиевнеке була. Спорт карьерасын тәмамлагач, Лидер пенсиягә озатыла һәм аны Настя сатып ала. Хәзер Лидер шәһәр ыгы-зыгысыннан еракта яши, балаларны атлар дөньясы белән таныштыручы булып тора.

Гомумән, ранчодагы барлык атлар да аерым игътибарга лаек. Аларның һәркайсы – үз тарихы булган җан иясе. Нигездә, болар – Россия абориген һәм җигүле токымнар вәкилләре: рус авыр йөк атлары Викинг һәм Варвара, рус юртагы Позывной, Байкал аръягы алмачуары Кюнней һәм аның кызлары – бурлы Морошка һәм көмешсу-кола Галатея, башкорт коласы Мадера һәм туры Мулан.

Биредә Россиядә сирәк очрый торган токым вәкиле – ирланд авыр йөк аты Фердинанд та бар. Аның төп аермасы – көмеш ял, аякларындагы матур кыл һәм Эркюль Пуароныкы кебек чын мыек. Тагын әле ул бик күп трюклар белә. Атларның барысы да көтү булып, тулы бер гаилә булып яши, кунакларны аның законнары белән таныштыралар. Җирән төстәге юаш гигант Викинг – баш айгыр һәм колыннарның атасы. Иректә йөргән атларга, аларның чабуына карап тору берни белән дә чагыштырмаслык рәхәтлек бирә. Аларның бөтен куәтен, аяк астында җирнең калтыравын тоймау мөмкин түгел. Көтүнең аралашу өчен кунакларга таба йөгерү мизгелләре – онытылмаслык. Тагын кайда әле шулай зөбәрҗәт болын уртасында ял итүче атлар янәшәсендә чирәмдә аунарга яисә кызыл-җирән карагачлар буенда йөрергә мөмкин?

КЕНТАВР – УЙДЫРМА ТҮГЕЛ

БЕРВАКЫТ Настя тылсымга ия була. Ул атлар белән «либерти» стилендә шөгыльләнә. Кеше белән ат үзара иркен, дирбияләрсез, үз ихтыяры белән аралаша. Читтән мондый аралашу чыннан да тылсым кебек күренә.

Әмма чынлыкта исә бу хайванга хөрмәт, сабырлык, дрессура нигезләрен, психологияне, атның табигатен, аның дөньяны һәм тән телен ничек кабул итүен аңлауны таләп итә торган төгәл юнәлешле тренинг булып тора.

– Балачакта әбием мине ат спорты мәктәбенә бирде, тик мин традицион спортның ошамавын аңладым, – дип искә ала Настя. – Иярләнмәгән ат белән аралашасы килә иде. Соңрак, беренче айгырым Викинг пәйда булгач, мин аның йөрәгенә, ирексезләми хезмәттәшлек итүгә, чыбыркыламый үзара аңлашуга юл эзли башладым, атларны һәм аларның ничек уйлауларын өйрәнергә керештем. Бу эзләнү мине тагын да зуррак масштабтагы хыялга китерде. Тормышта иң гаҗәеп маҗара – хыялдан аны тормышка ашыруга кадәр юл, – дип сөйли Настя, торган саен ныграк рухланып.

Атлар табигате буенча кешеләр белән аралашырга теләми икән. Шуңа күрә кеше хезмәттәшлеккә мотивация, үзара ышанычлы мөнәсәбәт тудырырга тиеш, һәм шул вакытта аттан да тугрырак партнер таба алмассың. Моңа ничек ирешергә? Бу хәтта фән генә дә түгел, ә тулы бер сәнгать. Моның өчен атларны аңларга өйрәнү мөһим. Шулай булгач, күпмедер дәрәҗәдә кентаврлар – уйдырма да, миф та түгел. Асылда, бербөтен булып эшләргә өйрәнгән кешеләр һәм атлар алар.

РӘХӘТ БАЛАЧАК

БЕРВАКЫТ Настяның тагын бер хыялы тормышка аша – ранчода беренче колын туа. Беренче тапкыр!

Алар көтүлектә дөньяга килә һәм шунда үсә, шул ук вакытта даими рәвештә кешеләр белән очраша, шуңа күрә беркемнән дә курыкмый һәм кызыксынып аралаша. Алар белән бергә кыргый тере рух туа. Мондый рәхәт балачак күргән колын куркусыз һәм бәхетле була. Бия колын өчен яшәү тирәлеге тудыра, алар дөньясының төрле буяу һәм авазларга бай булуы бик мөһим, ди Настя. Аның инануынча, ябык абзарларда сәламәт һәм бәхетле атлар үстереп булмый.

– Колыннар аяк асларындагы җирне тоймыйча чаба, әйтерсең лә алар болытларда очып йөрүче һәм аларны мамыктай күпертүче бер кайгысыз сихри пегаслар, – дип сөйли ул. – Әниләре, ягъни бияләр, һәр түмгәк турында тынычсызланып кешнәп кисәтеп, аларны куып җитәргә генә өлгерә. Әмма колыннар ишетми, очу шатлыгыннан һәм озын тоякларының җитезлегеннән ләззәт ала... Шуңа күрә сабый чактан ук очарга телгән бу мустанг балаларының иректән башка кайдадыр тилмереп үсеп-яшәп ятулары башка сыймый.

Настя шулай ук кешеләр белән уртак тел таба алмаган атларга ярдәм итә, аны башка районнар һәм бистәләргә дә чакыралар. Мәсәлән, ат тибенә, контактка бармый, тешли, хәтта һөҗүм итә. Настя әйтүенчә, бу проблемаларның барысы да хәл ителерлек, иң мөһиме, кешеләр киңәшләрне тыңласын, атлар асрауның дөрес булмаган шартларын үзгәртергә һәм үзләре дә үзгәрергә әзер булсын.

ТОРМЫШ ОРКЕСТРЫ ФЛЕЙТАЧЫЛАРЫ

– БЕРВАКЫТ атлар хәтта җирдә яткан ташларны да хәйран калдыра алырдай тормыш оркестрымның төп флейтачыларына әйләнде, – дип ышандыра Настя. – Шуннан бирле – калган бар нәрсә дә үзгәрә торган декорацияләр генә.

Аның проектының инде дуслары бик күп, бу төр яшәү рәвеше өлкәннәргә дә, балаларга да ошый. Алар монда бик рәхәтләнеп каникулда ял итә һәм атлар янәшәсендә үткәргән вакытны гомерләрендәге иң яхшы җәй дип атый. Мондый бәяләмәләрне ишетүне чын бәхеткә тиңли Настя.

– Табигатьтән көч алучы, аның белән илһамланучы һәм аңа тартылучы барлык кадерле һәм якын кешеләрне үзебезгә җыясы килә. Моның өчен бик күп хезмәт куярга кирәк, әмма иң мөһимен, әлбәттә, атлар эшли. Алар – борын-борын заманнардан бирле кешене үзенә җәлеп иткән табигатьнең бик кадерле һәм бик акыллы җан ияләре. Алардан борынгы рух бөрки, һәм ул рух безне чакыра.

ЯСАЛМА ИНТЕЛЛЕКТ – ТРАДИЦИЯЛӘРГӘ ХЕЗМӘТТӘ, ЯКИ ХӘЗЕРГЕ МӘКТӘПНЕҢ УҢЫШ СЕРЛӘРЕ

Елена Добровольская

Россия Кораллы көчләре Генштабын, РФ оборона министрының беренче урынбасары Валерий Герасимовны, кинорежиссёр Сергей Говорухинны, бард Леонид Сергеевны, журналист һәм атаклы телевидение алып баручысы Константин Курановны, Татарстан ҮСК рәисе Андрей Кондратьевны нәрсә берләштерә? Бу кешеләр барысы да үз вакытында Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан 94 нче мәктәпне тәмамлый. 2001 елдан ул инде гимназия статусын йөртә.

94 нче гимназия үзенең тарихын 1933 елдан исәпли. Дөрес, башта ул 49 нчы мәктәп булып йөри. 94 нче мәктәп дип Бөек Ватан сугышы елларында атала башлый. Бу вакытта аның иске бинасын хәрби госпитальгә бирәләр дә берничә уку йортын берләштерәләр.

Мәктәпнең яңа сан йөртеп эшли башлаган беренче елында кечкенә генә бер катлы бинада парта артына 275 укучы утыра. Хәзерге вакытта гимназиядә дүрт мәртәбә күбрәк бала укый. Ул, яшерен-батырын түгел, Казандагы иң яхшы белем бирү учреждениеләреннән исәпләнә. Сере нәрсәдәме? 94 нче гимназия директоры Лариса Кузьменко белән без нәкъ шул хакта сөйләштек.

ДИНАСТИЯ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

Берничә ел элек минем Мәскәү районында яшәүче коллегам улын беренче сыйныфка 94 нче гимназиягә бирергә теләде. Барып чыгармы дип борчылганын хәтерлим. Бүген ул бала бирегә укырга йөри.

– Бу – безнең өчен гадәти күренеш, гадәттә, шулай була да, – дип елмая Лариса Львовна. – Бездә гомумән династия традицияләре бик көчле. Безнең мәктәпне бетергән бик күпләр балаларын, оныкларын монда алып килә... Кайчак ата-аналар, балаларын китергәннән соң, үзләре дә килә. Мәсәлән, үзем шулай булдым – 2000 елда беренче сыйныфка кызымны китердем, ә аннан башлангыч сыйныфларга укытучы булып урнаштым. Күпчелек педагоглар – йә безнең чыгарылыш, йә укучыларыбызның әтиәниләре.

– Үзләрен нәкъ менә шушы уку йортына багышлауның сере нәрсәдә дип уйлыйсыз?

– Бездә һәрчак педагоглар коллективы көчле булды. Моннан тыш, минемчә, гимназиянең аерым аурасы да бар – тынычлык, зыялылык бөркелеп тора аңардан. Бу ауралы элеккеге җитәкчеләр булдырган. Мәсәлән, сугыштан соңгы елларда мәктәпне Иосиф Маркович Найшулер җитәкли. Ул – Россиянең атказанган укытучысы, фронтны узган кеше, сугышчан бүләкләре бар. Монда хөкем сөргән күп кенә традицияләргә нәкъ менә ул нигез салган. Ул җитәкчелек иткән вакытта мәктәп Шамил Усманов урамындагы яңа бинага күчә, без хәзер дә шушында кала бирәбез.

Аңардан соң, утыз елдан артык мәктәп директоры булып искиткеч педагог һәм психолог Леонид Николаевич Мурысин эшләде. Аның вакытында без немец телен тирәнтен өйрәнә торган уку йорты статусын алдык, гимназиягә әверелдек, сәнгать мәктәбе ачтык. Ни кызганыч, Леонид Николаевич узган елны якты дөньядан китеп барды. Гимназиябез аның исемен йөртә.

– Бүген бик күп мәктәпләрнең проблемасы – яшь мөгаллимнәр җитмәү. Алар эшләргә килсә дә, мәктәптә озак тоткарланмый...

Фотолар 94 нче гимназия архивыннан. РЕКЛАМА

– Яшь укытучылар, нигездә, үзебездә үк укып чыкканнар. Килсәләр, берәгәйле итеп, озакка калырлык итеп киләләр.

– Ничек аларны мәктәптә калдыра аласыз?

– Монда үзләренә һәрчак ярдәм итәчәкләрен, күтәрәчәкләрен белгәнгә калалар. Күпчелек яшьләр администрация тарафыннан берөзлексез акыл өйрәтү, күрсәтмәләр бирү булыр дип шикләнә бит. Ягъни «Син дөрес эшләмисең», «Алай эшләмиләр аны» дип тукып торуларыннан куркалар. Әмма без үзебез дә кайчандыр өлкәннәрдән өйрәндек. Миңа да бирүдә өлкән коллегаларым иңен куйды, тәҗрибәсе белән бүлеште. Хәтта дәрес конспектларына кадәр языштылар. Педагог буларак шундый җылы, ярдәмчел атмосферада тәрбияләгәнгә, үзебез дә яшьләргә карата хәерхаһлы. Гомумән, укытучыларның бер-берсенә ярдәм итүе, яшьләргә терәк булуы – гимназия өчен табигый хәл.

Яшьләргә матди як та бик мөһим. Шуңа без аларга ярдәм кулы сузарга тырышабыз: төрле бәйгеләрдә, грантларда даими катнаштырабыз. Командабыз шәп, коллегалар бер-берсен теләсә нинди сынауга әзер тота. Шуңа күрә ел саен төрле җиңүләр яулыйбыз: «Ел укытучысы» бәйгесе этапларында призлы урыннар алабыз, шул исәптән – «Педагогик дебют» номинациясендә дә.

ТАБИГЫЙ ФӘННӘР ТЕЛЕ

– Немец теле турында да сөйләшеп алыйк. Аны тирәнтен укыта торган мәктәпләр бездә әллә ни күп түгел...

– Әйе, Казанда алар нибары өчәү.

– Әмма сездә инглиз телен дә өйрәтәләр дип беләм?

– Хәзер инде юк. Без аны атнага берәр сәгать кертергә тырыштык. Әмма телләргә өйрәтә торган мәктәп буларак, бу мәсьәләгә бик җитди якын киләбез. Телне атнага бер мәртәбә өйрәнү, чынлыкта, бик аз һәм тиешле дәрәҗәгә ирешеп булмый. Шуңа да тирәнтен немец телен өйрәтүне сайладык.

– Балаларын сездә укытырга омтылган ата-аналар санын исәпкә алганда, инглиз теленең булмавы аларны куркытмый...

– Химия белән биология кебек фәннәрне күздә тотсак, мәсәлән, алар хәзерге көндә Германиядә актив үсә. Димәк, алга таба язмышын бу фәннәр белән бәйләргә теләүче бала өчен немец теле бик кирәк булачак. Моннан тыш, безнең педагоглар хак әйтә: немец теленнән инглиз теленә күчүе җиңелрәк, ә менә инглизчәдән немец теленә, киресенчә, кыен.

КУЛЬТУРА ҺӘМ ПАТРИОТЛЫК

– Бүгенге мәктәп, белем бирүдән тыш, баланы тәрбияләргә, үстерергә дә тиеш, дип саныйлар...

– Без моның белән һәрчак шөгыльләнә идек, бу яңалык түгел. Әле 1970 нче еллардан мәктәп Төньяк флотының элеккеге юнгалары Ветераннар советы белән хезмәттәшлек итте. Укучылар, мөгаллимнәр белән берлектә, Соловецк юнгаларын эзләшә, алар белән очрашулар оештыра иде. Мәктәп музеенда юнгалар батырлыгына багышлап экспозиция дә ачылды. Гимназия территориясендә Соловецк юнгалары батырлыгына багышлап һәйкәл куелды. Шуны да онытмыйк: Казандагы Соловецк юнгалары урамына да исем безнең Леонид Николевич Мурысин тырышлыгы белән бирелде бит.

Хәзер дә патриотик тәрбия – игътибар үзәгендә. Гимназиядә юнармия отряды эшли, аның әгъзалары Юнармиянең хәрби-спорт уеннарында катнаша, берничә мәртәбә Җиңү көнендә Меңьеллык мәйданында узган парадта да катнаштылар.

Балаларны иҗади яктан үстерүгә дә зур игътибар бирәбез. Әйткәнемчә, гимназиядә 1992 елдан сәнгать мәктәбе эшли, анда музыка, хореография, сәнгать бүлекләре бар, малайлар хоры, үзебезнең театрыбыз. Җиденче сыйныфны тәмамлаганда, барлык укучылар да дипломнар алып чыга. Ә иң мөһиме – этиәниләр балалары монда шөгыльләнгән өчен өстәмә бер тиен дә түләми.

ДАИМИ ӘҢГӘМӘ

– Сүз уңаеннан, ата-аналар белән мөнәсәбәтләр – замана мәктәбе өчен авырткан урын. Сездә бу яктан ничек?

– Безнең ата-аналар укытучыларның аралашу өчен һәрчак ачык икәнен белә, моңа ияләшкән. Бездә теләсә кайсы укытучы янына килеп, борчыган темага сөйләшергә була. Ата-аналар җыелышларына да барлык укытучылар килә. Кайчак мондый җыелышлар өчәр сәгатькә сузыла, чөнки бу – һәр ике як тарафыннан да зур кызыксынуга, кайгыртучанлыкка корылган әңгәмә.

Без эти-әниләр белән даими аралашуны әле Үсеш мәктәбендә чакта ук башлыйбыз. Анда программа нигезендә алты яшьлекләр шөгыльләнә. Ул дәресләрдә эти-әниләр һичшиксез булырга тиеш, алар да программаның асылына төшенә.

– Бу аларга нигә кирәк һәм нәрсә бирә?

– Беренчедән, бала алар янәшәсендә үзен психологик яктан уңайлырак һәм ышанычлырак хис итә. Икенчедән, ата-ана баласының ничек шөгыльләнгәнен, үсешен күреп тора. Кайчак шулай була: эти-әниләр баласын мәктәпкә иртәрәк бирергә тели, әмма бала әле психологик яктан әзер түгел, уйнап туймаган, өлгереп җитмәгән. Ата-аналар моны күрә, психолог белән аралашып, аның киңәшләренә колак салып, кайсы проблемаларны ничек хәл итәргә икәнен белә.

ТРАДИЦИЯЛӘР ҺӘМ НОВАЦИЯЛӘР

– Без традицияләр турында күп сөйләштек, әмма бүген бит новацияләр дә бик мөһим.

– Билгеле шулай, без вакыт белән бер адымда барырга тырышабыз. Быел менә КИТТУ-КАИ каршында эшли торган Казан инженерлык лицее белән хезмәттәшлек турында килешү төзелде. Эти-әниләр инде бу юнәлеш белән бик кызыксына. Киләсе елга планнарыбызның берсе – башлангыч сыйныфларның чыгарылыш базасында тулы канлы инженер сыйныфы ачу. Димәк, балалар бишенче сыйныфтан ук программалаштыру, ясалма интеллект проблемалары кебек заманча, бик әһәмиятле юнәлешләр белән шөгыльләнә ала дигән сүз. Киләчәк шуларга корылган. Безнең балалар – мотивацияле, кызыксынучан, алдынгы фикерле, без аларны берничек тә классик белем бирү белән генә чикли алмыйбыз, тиеш тә түгелбез. Ә инде программалаштыру белән шөгыльләнүчеләргә инглиз теленең кирәклеге – көн кебек ачык, димәк, инженер сыйныфларда аны да өйрәтәчәкләр.

– Сезнең мөгаллимнәр сәламәт консервативлык белән прогресс арасында балансны ничек саклый?

– Укытучы мәктәптә беркайчан да картаймый, чөнки ул – һәрчак балалар белән. Ә балалар – өзлексез хәрәкәт, яңалыкка омтылыш. Син алар белән бер дулкында булсаң гына эшли аласың.

Төрле яшьтәге мөгаллимнәрдән торган коллектив бездә, бу да, үз чиратында, зур мотивация бирә. Мисал өчен, хәзерге вакытта безнең бер укытучыбыз чираттагы педагогик бәйгегә әзерләнә, ачык дәрес өчен ул ясалма интеллект ярдәмендә үзенең балачак фотографиясен «җанландырды». Шулай итеп, бишенче сыйныфларга теманы аларның яшьтәше сөйли, һәм бу бик кызыклы алым. Өлкән коллегаларны да бу бик кызыктырды, аларның кайберләре хәзер шулай ук бәйгеләрдә катнашырга омтыла.

Безнең гимназиядә катып калган, «консервациягә» куелган берни дә, беркем дә юк, диясем килә. Әйе, без традицияләрне саклыйбыз, тик алар, елдан-ел төрле мәгънәләр өстәлеп, яңарып тора. Т

100 000 СУМ

һәм башка бүләкләр

Бүләкләрне уйнату 2025 елның 6 февралендә узачак.

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru сайтында белә аласыз.

Акция 2024 елның 15 октябреннән 2025 елның 20 мартына кадәр уздырыла. Гаризалар 26.01.2025 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин

ТАТ МЕДИА

РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Ульяновскидагы авиация музеенда **нинди** очкычлар саклана

Кар барсы Татарстан белән Сәмәркандны **ничек** берләштерә

«Татарстан» туктап калган вакытны **ничек** «уята»

Дмитрий Сивков Донбасста **ничек** волонтёр булды

Римма Ибриһимованың остазлары **кем** булган

«ТАТАРСТАН» МАҖАРАЛАРЫ



Нинди генә сәяхәтләрдә булмады бу бер ел эчендә «Татарстан»!

Нинди генә маҗараларга юлыкмады!

Нинди генә сый-нигъмәтләрне авыз итмәде!

Яңа М-12 трассасын тиешле дәрәҗәдә сузылганмы-юкмы дип тикшереп карады. Юлда йөргәндә, Арзамаска кереп, яу казларын да санап чыкты, Сергачтагы өйрәтелгән аюлар белән дә танышты, Муромга сугылып, әкиятләрдә генә сурәтләнгән баһадирларның чынлап та булганын күрде, туган Чүпрәле болыннарында үскән җиләк белән дә хушланды...

Сочидан журналистика буенча җыңу яулап кайтты.

Абхазиядә яңа туристлык маршруты ачты.

Дагыстанда әдәби фестивальдә катнашты һәм үзебезнең Менделеевскида Пастернак укуларын тыңлады.

Үзбәкстандагы Олы Мәҗлестә законнар чыгару палатасы депутатларын сайлауны күзәтте, Байкал күлендә диңгез мәчеләренең пляждагы уеннарына шаһит булды.

Великий Устюгта Кыш Бабайның туган көнен билгеләде, ә Яңа Кырлайдагы Кыш Бабай резиденциясендә Яңа ел бүләкләре әзерләште.

Болар хакында сез ел дәвамында журналдан укып бардыгыз.

Бүгенге «сәяхәтләр сандыгында»нда «ТАТАРСТАН» МАҖАРАЛАРЫНЫҢ тагын менә нindиләре белән танышырсыз:

- АВИАЦИЯЛЕ – Ульяновскидагы гражданлык авиациясе музеенда без ничек Ту-124 самолётының пилоты булдык;
- АК ҺӘМ ЙОМШАК – кар барсы ничек итеп Татарстан белән Сәмәркандны берләштерде;
- КОМИ-ПЕРМЯКЛЫ – туктап калган Вакытны «уятыр» өчен нишләргә кирәк;
- ВОЛОНТЁРЛЫ – ни өчен Донецкида «гипотенуза буенча йөрергә» ярамый.

САРВАР
ЗАФАР

Фото: Айдар Мешәрапов

СОВЕТ ИЛЕ КАНАТЛАРЫ. ҮТКӘННӘРГӘ ӨМЕТ БЕЛӘН

Әскәр Сабиров

Хыяллар тормышка аша. «Туполев» реактив самолёты, пилот кабинасы, каршымда ике дистәләп төймә, штурвал. Мин – командир кәнәфиендә. Гәрчә малай чактан хыялланган – «Очышны рөхсәт итәм!» дигән сүзләрне ишетмәсәм дә, дулкынлануым чиктән аша. Двигательләр – очыш режимында, штурвалны үземә тартам, менә җирдән аерылабыз...

Барысы да, әлбәттә, күңелдән генә. Яшел газонга соңгы тапкыр төшеп утырган өч дистә самолётның берсе булган әлеге Ту-124 – Ульяновск гражданлык авиациясе музеенда. Күз алдына китерәсезме, утызлап авиация раритеты – узган гасырның 20 нче елларындагы «Добролёт»тан алып илебезнең беренче Ту-104 реактив очкычына, континентара Ил-62М һәм дөньяда беренче тавышныкыннан югарырак тизлеккә ия Ту-144 самолётларына кадәр – барысы да бер урында тупланган. Искиткеч!

ШТУРВАЛ АРТЫНА? ӘЛБӘТТӘ!

Музейга керә торган урынга эленгән язуга игътибар итәм: биш самолётның эченә кереп карарга мөмкин икән! Түләү дә бик арзан. Канәгатьлектән кулларымны угалап, шул биш самолётны сайлыйм. Иң-иңнәр арасына, әлбәттә, Ту-144не кертәм, пилот кабинасын карыйсы иде. Аннан соң Ил-62М очкычын – аны бездә, Казанда җыйганнар.

– Эченә кереп караргамы? Юк, бары тик Ту-124 кә генә рөхсәт ителә, – дип, кинәт чынбарлыкка кайтара кассир кыз. – Башкаларына ярамый...

–?

– Нигәме? Самолётка күтәрелгәч, үзегез барысын да аңларсыз.

Эченә кереп карар өчен мин Ту-124 самолётын сайлыйм, исәп – штурвалы артына утырып карарга. Сәфәремне күңелле ноктада тәмамлыйм әле.

ХРУЩЁВ ЧОРЫ ӘЗМӘВЕРЕ

Аэрофлот өслүбендә бизәлгән нәфис Ту-114 самолёты 1960 нчы еллар үрнәге икән. Менә ул, безнең беренче континентара пассажир лайнеры – аның канатлары астына Ан-2 кебек кечерәк бер-ике самолёт сыена ала. Илләр һәм континентлар буйлап оча башлагач, Ту-114 барысын да куәтле һәм уңайлы булуы белән шаккатыра. Ике палуба (багаж һәм пассажирлар бүлекләре), үз кухнясы, буфеты, беренче класста очучы пассажирлар өчен йокы урыннары каралган аерым купелар...

Бу лайнер 60 нчы елларда дөньяда иң зур пассажир самолёты исәпләнә. Хабаровскига һәм Токиога, Гаванага һәм Нью-Йоркка оча. Мәскәү – Токио линиясенә Аэрофлот белән Japan Airlines хезмәт күрсәтә – «Боинглар»га ихтыяҗ булмаган чак...

Ту-114 – безнең беренче континентара пассажир лайнеры – аның канатлары астына Ан-2 кебек кечерәк бер-ике самолёт сыена ала..

Ту-114 очкычының биеклек яратучы «кош» булуы аеруча гигант шасси терәкләре астында басып торганда сизелә. Очкычның борын өлешеннән фюзеляжына кадәр биш метр чамасы ара – ләкин анда янгын сүндерү баскычыннан башка менеп булмый. Безнең флагман дөньяда иң биеге дә санала, бу кайчак проблемалар тудыра.

1959 елда совет иле җитәкчесе Никита Хрущев АКШка Ту-114 самолётында килә. Ләкин төшәр өчен мондый биеклектәге трап табылмый, аптыраган хуҗалар, нишләргә белмәгәннән янгын сүндерү машинасын китерәләр, дип сөйлиләр. Безнең ил лидерына янгын сүндерү машинасы баскычы буйлап төшкәндә, барлык кагыйдәләрне бозып, каршы алучыларга йөз белән түгел, гәүдәнең дипломатик булмаган бөтенләй башка ягы белән төшәргә туры килә.

Шулай дип сөйлиләр, әмма чынлыкта алай булмаска да мөмкин: ни дисәң дә, сәфәр алдан ук планлаштырыла бит. Аның каравы, Никита Сергеевичның Америкага әле барлык сынауларны да узып бетермәгән самолётка утырып барырга батырчылык итүе – хак. Ту-114 даими очышларны әле ике еллап вакыт узгач кына башлый. Шунысы да төгәл дөрес: 1977 елда очу карьерасы тәмамланганчы, лайнер дөньяда турбовинтлы иң тиз пассажир самолёты булып кала бирә. Һәм, кызганычка каршы, иң тавышлысы да. Шуңа күрә очкычны «Змей Горыныч» дип тә йөртәләр.

Беренче совет реактив пассажир самолёты Ту-104.

Ил-86 – безнең беренче аэробус.

Ил-14.

«Пчёлка» Ан-14 очкычы.

ЧЕЛЮСКИНЧЫЛАРНЫ КОТКАРА, ИДЕЛ БУЕНЧА ЙӨЗЕП КИЛӘ

Ялкын-сары фюзеляж, зәңгәр канатлар... Тыйнак макияжлы башка самолетлар фонында ул нәфис аккошлар көтүендәге тавис кошы түгелме? Ләкин тышкы кыяфәт күп вакыт алдаучан: беренче карашка килбәтсезрәк тоелган бу очкыч күп кенә матур лайнерларга бабай туры киләдер. Безнең илдә җитештерелгән ТБ-1 (АНТ-4) очкычы беренче тапкыр һавага 99 ел элек күтәрелә. Һәм, сүз уңаеннан, дөньяда серияләп чыгарыла башлаган ике моторлы, тоташ металлдан ясалган беренче бомбардировщик була ул.

Ветеранның казанышлары бихисап. 1929 елда «Страна Советов» дип аталган АНТ-4 бөтен дөньяга бу илнең күп нәрсәгә сәләтле булуын ачык күрсәтә: самолёт Мәскәү – Петропавловск-Камчатск – Сан-Франциско – Нью-Йорк маршруты буенча гаять зур араны очып үтә. Сигез ел узгач, ул тагын бер очышы белән барысын да таң калдыра. Бу юлы АНТ-4 самолёты Мәскәү – Казан – Свердловск – Иркутск – Анадырь – Уэлен борыны – Архангельск – Мәскәү маршрутын буйсындыра.

Әмма самолёт тагын бер тиңсез очышы белән мәңгегә тарихка кереп кала. 1934 елның мартында АНТ-4 пилоты Анатолий Ляпидевский Арктикада бозлар арасына кысылган «Челюскин» бозваткычы экипажын һәм пассажирларын беренче булып таба, бозга төшеп утыра һәм ун хатын-кызны, ике баланы Зур җиргә алып чыга. Ляпидевский беренче булып Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Әлеге батырлыкка багышлап чыгарылган почта маркасына «Встреча на льдине самолёта АНТ-4» дип язып куелган була.

Ульяновскидагы АНТ-4, сүз уңаеннан, шулай ук атказанган полярник. Төньякта очкан, шуңа күрә аның каурый-канатлары җете төстә – гадәттән тыш хәлләр була калса, самолётны кар арасыннан табу җиңелрәк булсын. Бу самолёт Диксон утравында һәлакәткә очрый, бөтен кеше тарафыннан онытылып, кырык еллап шунда ята. Аны 80 нче елларда табалар, өлешләп Выборгка алып кайталар, төзәтәләр. Су юлы буйлап Ульяновскига китерәләр. Борт номеры СССР-Н227 булган бу АНТ-4 очкычы – дөньяда бердәнбер сакланып калган экземпляр. Сүз уңаеннан, аны Татарстан башкаласына эвакуацияләнеп, Казан авиация заводына үз исемен биргән Мәскәүнең 22 нче заводында җыйган булалар.

Тышкы кыяфәт күп вакыт алдаучан: беренче карашка килбәтсезрәк тоелган бу очкыч күп кенә матур лайнерларга бабай туры киләдер. Безнең илдә җитештерелгән ТБ-1 (АНТ-4) очкычы беренче тапкыр һавага 99 ел элек күтәрелә.

Континентара Ил-62М самолёты. Мондый машинада КПСС Үзәк комитетының барлык генераль секретарьлары очкан.

ҖИТӘКЧЕЛӘР ӨЧЕН 1 НЧЕ НОМЕРЛЫ БОРТ

Ә менә бу бестселлер чыннан да Татарстанда җыелган. Континентара Ил-62М самолёты. Мондый машинада КПСС Үзәк комитетының барлык генераль секретарьлары, команданте Фидель Кастро һәм тагын дистәләп илнең лидерлары очкан. Без, казанлылар, теләсә кайсы экскурсоводка караганда да күбрәк белгән самолёт. Кем, мәсәлән, монда, Ульяновскида, төп пассажирны йөртү өчен заказ бирелгән машинаның соңгысы Казанда төзелгән, ләкин аның өчен түләнмәгән, дип сөйли алыр – Борис Николаевичның, күрәсең, «иномарка»га күчкән вакыты булгандыр...

Ә бервакыт Леонид Ильич Брежневның, үзенең «президент» Ил-62нең йокы бүлмәсендә төн уртасында уянып китеп, караваг башында бортпроводникны чакыру өчен урнаштырылган төймәне таба алмавы турында кем сөйләр? Чакыру төймәсе, әлбәттә, беркая да китмәгән, генераль секретарь, яше шактый өлкән булуы сәбәпле, аны икенче яктан эзләгән. Әмма төп пассажирның яше – аклану өчен сәбәп түгел. «Гадәттән тыш хәл»дән соң ук башкалага ашыгыч рәвештә белгечләр чакырыла – «конструктив җитешсезлекләрне» бетерү максатында. Нәтиҗәдә генераль секретарь караваты янында берьюлы өч чакыру төймәсе пәйда була: икесе – баш очында, берсе – аяк очында. Табасың килмәсә дә, табарсың... Сүз уңаеннан, өч Брежнев төймәсе булган бу самолёт мирас буенча аның варисына күчә, аннары икенче генераль секретарьга...

Гражданлык авиациясе музее чирәмендә торган Ил-62М, әлбәттә, гадирәк. Салонында кызыл агачтан ясалган панельләре, күн тарттырылган йомшак кәнәфиләре һәм кыйммәтле агачлардан эшләнгән зур СССР гербы юк. Әмма башка барлык яхшы сыйфатлары, әлбәттә, беркая да китмәгән. Ил-62 – безнең беренче континентара реактив самолёт. Күккә күтәрелергә өлгерми, ул инде үз классы лайнерлары арасында тизлек һәм ераклыкка очу буенча берничә дөнья рекорды куя. Ышанычлылык, уңайлылык, экономиялелек буенча үзенең очу биографиясе башында көнбатыш көндәшләреннән калышмый.

Сүз уңаеннан, кайбер Казан Ил-62ләре әлегә кадәр төрле илләрдә оча. Аларны Казанда 60 нчы еллар уртасында ук төзи башлаган булсалар да.

КҮҢЕЛСЕЗ ТАРИХКА ИЯ ОЧКЫЧ

Трап буенча ТУ-124 салонына күтәреләм... Эченә кереп карарга рөхсәт ителә торган бердәнбер самолёт. Пычрак кәнәфиләр, салон стеналары кыршылып беткән... Таушалган, вакыт аямаган салон эче кәефне күтәрми. Кассир кызның: «Самолётка күтәрелгәч, үзегез барысын да аңларсыз», – дигән сүзләре яхшы аңлашыла хәзер.

Шулай да командир кәнәфиенә утырмыйча булдыра алмыйм. Штурвалы төзек, приборларының да барысы да диярлек бар. Бераз хыялга бирелеп алганда, үзеңне пилот итеп тоярга мөмкиндер. Двигательләр – очыш режимында, штурвалны үземә тартам, менә җирдән аерылабыз...

Ту-124 очкычы салонында.

Бу реактив самолётлар Россия шәһәрләре арасында 60–70 нче елларда оча. Аларны Харьковта җыялар. 1979 елда Казаннан очып килә торган самолёт Тамбов өлкәсендә һәлакәткә очрый. Бу хәлдән соң бер ай узгач, аны бөтенләйгә кулланыштан чыгаралар. Шулай килеп чыга ки, ул вакытта Ту-124 очкычын иярләгән соңгы авиаотряд та Казанныкы була. Күпкә камилрәк Ту-134 машиналары иске аэропорт полосасына утыра алмый. Яңа полосаларны фаҗигадән соң бер ай үткәч куллануга тапшыралар. Ашыгыч рәвештә исәптән чыгарылган «Туполевлар» исә Оренбург тракты янындагы урман авызында тагын ун еллап хуҗасыз ята. Менә шундый күңелсез хәл.

ЗАМАННЫ УЗГАН ЛАЙНЕР

Ту-144. Тагын бер тапкыр «дөньяда беренче» дип әйтеп булган очкычыбыз. Үз заманын шактыйга узып киткән бу совет лайнеры 1978 елда пассажирларны Мәскәүдән Алма-Атага ике сәгать эчендә илтеп җиткерә. Тизлеге хәтта хәзерге вакыт өчен дә фантастик – сәгатенә 2000 километрдан артык! (Бүгенге самолётлар бу араны дүрт сәгать ярым эчендә үтә – **ред. иск.**)

Әкият җиде айлап дәвам итә – пассажирларны тавышныкыннан югарырак тизлектә йөртү бик кыйммәткә төшә... Шуңа да карамастан, самолёт дөньяда тавышныкыннан югарырак тизлеккә ия беренче лайнер булып мәңгегә тарихка кереп кала – Ту-144 өчен беренче сынау очышы 1968 елның 31 декабрендә була. Инглиз-француз «Конкород»ы һавага ике ай соңрак күтәрелә...

Истәлеккә тагын бер фото ясыйм – Ту-144 янында. Шулай да бу самолёт – көнбатышныкыннан бер дә ким булмаган совет авиатөзелешенең горурлыгы. Горурлыкка сагыш кушыла. «Йөз кырык дүртенче»нең туктап калган тәгәрмәчләре, төсе уңган макияжы һәм ашыгыч рәвештә фанералар белән пәрдәләнгән кабина тәрәзәләре... Ә янәшәдә фюзеляжларын мүк баскан «Ил», «Як» һәм «Ту»лар...

Безнең бөек мирасыбызга шулай карарга хакыбыз бармы? Мөгаен, үзебезнең гражданлык авиациясен торгызуга алынырга әлегә соң түгелдер, безгә кадәр башкарылган эшләр турында да кайгыртырга нәкъ менә вакыттыр. Әлбәттә, әгәр киләчәктә горурланырлык нәрсәләр калуын телибез икән.

Ту-144 дөньяда тавышныкыннан югарырак тизлеккә ия беренче лайнер буларак мәңгегә тарихка кереп калды.

Казан.
Казан Кремленең
Туп утары ишегалды.
«Ирбис. Күзгә күренмәс мәче» күргәзмәсендәге кар барсы.

ТАТАРСТАН – СӘМӘРКАНД: БАРСЛАР НЫГЫТКАН ДУСЛЫК

Сәмәрканд. Конгресс-холл.
Кар барсы – БМОның глобаль конференциясе символы. Чара кыргый хайваннарның күченеп йөри торган төрләрен саклауга багышланган.

Фотолар авторныкы, tatat-inform.ru



«Татарстан»лылар моңарчы күргән аэропортлар арасыннан иң матуры – Сәмәркандныкы, ул ачып куелган китап рәвешендә төзелгән.

Татьяна Вафина

Сәмәркандта кунакларны иң беренче булып ак барс каршы ала. Аның сурәте бөтен җирдә очрый: шәһәрнең рәсми гербында да, Регистанның борынгы Шер-Дор мәдрәсәсендә дә, һөнәрчеләр ясаган эшләнмәләр белән сыннарда да, миниатюралар, архитектурада да... Әйтерсең, Татарстаннан бөтенләй китмәгәнбез. Шундый ук ап-ак йомшак җәнлек безне үз аэропортыбызда да озатып калган иде. Аның туганы, хәтта ки игезәге дияргә дә ярыйдыр, Сәмәрканд аэропортында көтеп тора булып чыкты. Барлык экскурсияләрдә озатып йөрде. Бик әйбәт, дип уйлаштык без: әйдәгез, Татарстан һәм Үзбәкстан барслары аша дуслыкны тагын да ныгытыйк!

БАРС № 1. БОРЫНГЫ ШӘҺӘРНЕҢ ТӨП ЛЕГЕНДАСЫ

Барс Сәмәркандның төп символы булып тора. Шәһәргә нигез салыну легендасы да әлеге җитез җәнлек белән бәйле. Аны безгә Сәмәрканд халыкара аэропортының дежур менеджеры Шухрат Зокиров сөйләде:

– Риваять буенча, шәһәр төзелеп беткәч, Зарафшан тауларыннан барс төшкән. Ул шәһәр капкалары янына килгән дә барлык торакларның ничек төзелгәнен карап, тикшереп чыккан. Күргәннәреннән разый калып, кире тауга менеп киткән. Сәмәрканд халкы, җәнлекләр патшасы безнең эшебезне хуплады дип, бик сөенгән. Әнә шуннан башлап барс безнең шәһәрнең сакчысы буларак кабул ителгән. Ул – Сәмәркандның символы.

Сәмәркандта ак барс сурәте бик күп очрый.

Борынгы шәһәрнең төп легендасын безгә Шухрат Зокиров сөйләде.

Шәкертләр яшәгән хөҗрәләрдә бүген чыршы уенчыклары саталар. Тиздән Яңа ел бит!

Сәмәркәнд аэропортында яшәгән барсны сыйпап карау – байлыкка, диләр.

Шер-Дор мәдрәсәсенең төп айваны да юлбарыс (барс) сурәтләре белән бизәлгән.



Сәмәркәнд аэропортының шулай ук үз символы бар – аның исеме Барсик. Ул да Зарафшан тауларыннан... ой, гафу итегез, аэропортның өченче катыннан төшеп, кунакларны каршы алырга ярата. Без, «татарстан»лылар, моңарчы күргән аэропортлар арасыннан иң матуры – Сәмәркәндныкы, ул ачып куелган китап рәвешендә төзелгән. Кунаклар белән әвәрә килмәгән арада барс ял итеп ята, аның янына Сәмәркәндкә аяк басучылар баш иярга үзләре бара. Сәмәркәнд аэропортында яшәгән барсны сыйпап карау – байлыкка, диләр.

Шулай итеп, байлыкка тиенеп, без шәһәр карарга юл тотабыз.

БАРС № 2.
РЕГИСТАН ҺӘМ АНЫҢ ГҮЗӘЛЛӘРЕ

Сәмәркәнд буйлап башны бер дә төшермичә сәгатьләр буе йөрергә була. Күкнең зәңгәрлеге – бер хәл, ә туристларга күрсәтелә торган төп биналарның гөмбәзләренә карасаң, күгең дә бер якта торсын! Сарайлар белән мәчетләрнең гөмбәз-диварларын каплаган зәңгәр ялтыравыгы смартфоннарыбызның бөтен хәтерен тутыра! Күз явын алырлык! Бигрәк тә Сәмәркәндның үзәк мәйданы – Регистан. Әлеге мәйданда XV–XVII гасырларга караган өч мәдрәсәдән гыйбарәт атаклы архитектура ансамбле урнашкан.

Сулдан уңга – Тамерланның оныгы Олыгбәк мәдрәсәсе. Нәкъ менә аның хакимлеге вакытында Регистан мәйданы төзекләндерелә башлый. Беренче зур корылма 1419 елда калкып чыга. Бу Урта Азиядәге иң зур ислам университеты – Олыгбәк мәдрәсәсе була. Мәдрәсә Көнчыгышның иң абруйлы уку йорты санала.

Үзәктә – Тилля-Кари мәдрәсәсе, «алтын йөгертелгән» дигәнне аңлата. Ул 1660 елда элеккеге матурлыгын җуйган, искерә башлаган кәрвансарай урынында торгызыла. Эченә керсәң, үзеңне чынлап та мәдрәсә шәкерте итеп хис итә башлыйсың. Кечкенә генә бүлмәләр – хөҗрәләр ишегалдына карый, ә анда тут агачлары үсеп утыра. Биредә бернәрсә дә укуга комачауламый, хәер, хөҗрәнең бизәлешен исәпкә алмагандадыр, чөнки аларның «дизайны» да шәһәрнең төп истәлекле урыннары техникасында эшләнгән. Зәңгәр ялтыравык йөгертелгән орнамент-бизәкләрне сәгатьләр буе күзәтеп утырырга буладыр шикелле...

Хәзерге вакытта беренче катта урнашкан һәм Урта гасыр шәкертләре яшәгән

Регистан – Сәмәркәндның үзәк мәйданы. Әлеге мәйданда XV–XVII гасырларга караган өч мәдрәсәдән гыйбарәт атаклы архитектура ансамбле урнашкан.

Регистан мәйданы – фотосессияләр өчен менә дигән локация, Сәмәрканд фотографлары моны бик оста итеп куллана да белә.

хөҗрәләрдә... чыршы уенчыклары саталар. Тиздән Яңа ел бит!

Уңда – Шер-Дор мәдрәсәсе. Аның төп айваны юлбарыс сурәтләре белән бизәлгән (икенче версия буенча – барслар белән). Ерткыч җәнлекләр нәфис боланны эзәрлекли. Әлеге бина «Арысланнар йорты» дип атала. (Күрәсең, ул заманнарда мәчесыманнар семьялыгының барлык төрләрен бер җәнлек итеп караганнар.)

Шер-Дор 17 ел буе төзелгән, 1619 елдан 1636 елга кадәр. Ул – Олыгбәк мәдрәсәсенең көзгедәге сыман чагылышы.

Сәмәркандның Регистан мәйданы, башка борынгы тарихи архитектура һәйкәлләре белән беррәттән, ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирасы исемлегенә кертелә.

Регистан мәйданы – фотосессияләр өчен менә дигән локация, Сәмәрканд фотографлары моны бик оста итеп куллана да белә. Алар дөньяның барлык почмакларыннан килгән гүзәлләргә үзбәк принты белән киемнәр тәкъдим итә, һәм шул киемнәрне киеп алган ханым һәм туташларны фотоаппаратка «аулап та ала».

Костюмлы маҗараларга да, мәйдандагы туй фотосессияләренә дә, кыскасы, барлык гүзәлләргә үзенең дикъкатьле карашын төбәп ак барс утыра, ул – Регистанның төп сакчысы.



Биредә 1405 елда Әмир Тимер үзе җирләнә, ә ул, белгәнебезчә, иксез-чиксез мәмләкәткә нигез салган зат, аталы җиһангир, гаскәр башлыгы. Аягы аксаганга, аны халыкта Аксак Тимер дип тә йөртәләр.

БАРС № 3.
ГУР-ӘМИР ҺӘМ ТАМЕРЛАН КАҺӘРЕ

Гур-Әмир мавзолее – Сәмәркандның үзендә генә түгел, ә гомумән бөтен Үзбәкстандагы иң атаклы төрбәләрнең берседер, мөгаен. Биредә 1405 елда Әмир Тимер үзе җирләнә, ә ул, белгәнебезчә, иксез-чиксез мәмләкәткә нигез салган зат, атаклы җиһангир, гаскәр башлыгы. Аягы аксаганга, аны халыкта Аксак Тимер дип тә йөртәләр. Бөек әмирдән кала, төрбәдә аның нәсел-ыруыннан булган тагын берничә зат «йоклый», шулай ук Тимернең рухи остазы – шәех Мир Саид Барака да.

Төрбәдә сезгә Мисыр фараоннары каберлекләре ачылгач, нинди коточкыч хәлләр булуы рухындагы «риваятьләр»не дә, һичшиксез, сөйләячәкләр. Ә эш менә ничек килеп чыга. 1941 елның 19 июнендә, янәсе су басып алганнан соң саклап калыр өчен, археологлар Тамерлан каберлеген ача. Монда чыннан да бөек һәм җиңелмәс Әмир Тимер ятуына да инанырга телиләр.

Иң башта Олыгбәкнең уллары яткан төрбәне ачалар, аннары инде – Мироншах белән Шахрухныкын. Шулай ук Олыгбәкнең калдыкларын да ачып чыгаралар. Ә инде археологлар Тимернең үз каберлегенә орынгач... Бөек Ватан сугышы башлана (ул кайчандыр тынычлыгын җуймаска боерып калдырган була!).

Ырымнарга артык ышанучан кешеләр, герметик табут эченнән аңкып чыккан һәм бөтен төрбәне тутырган иснең, аз да түгел, күп тә түгел, Тамерлан рухы булуына шикләнми. Бу – аның, ә димәк ки, яу-сугышның рухы, дип уйлый.

Имештер, аксакаллар, казу эшләренә тотынганчы, төрбәгә орынырга теләүчеләрне ача күрмәгез, дип, өндәп кисәткән. Тимернең оныгы Олыгбәк бабасының васыятен төрбәгә язарга да вәгъдә биргән була кайчандыр: «Минем тынычлыгыма орынган һәркемне кайгы-хәсрәт белән үлем көтә...»

Сугыш – сугыш урынында, ә менә археолог Герасимов, калдыкларны җентекләп өйрәнеп, аларның чыннан да Бөек Аксак Тимернеке – Тамерланныкы булуын раслый. Әлеге калдыклар буенча Аксак Тимернең төс-кыяфәте дә торгызыла. Аңа һәйкәлне Үзбәкстандагы мәхәлләләрнең берсендә күрергә мөмкин.

Тимур белән тимуридларның калдыкларын каберлекләренә һәм төрбәләренә кайтару совет гаскәрләренең Сталинград сугышындагы җиңүе алдыннан була. Ә бит нәкъ менә Сталинград сугышы Бөек Ватан сугышының хәлиткеч бәрелеше санала. Ничек риваятькә ышанмыйсың монда?

Сүз уңаеннан, мавзолейның алтын йөгертелгән гөмбәзләре астында бер данәсе 50 мең сум (үзбәк акчасы белән) торган ак барслар карап тора. Риваятьләрне тыңлаганнан һәм хозурланганнан соң, тимуридлар торгызган каланың сагында торган барсны да алырга онытмагыз!

БАРС № 4.
БЕР ҮБЕШҮ ТАРИХЫ

Сәмаркандтагы иң матур мәчетне Аксак Тимернең иң олы һәм яраткан хатыны Биби ханым төзетә. Биби ханымның гүзәллеге турында да легендалар йөри. Шундыйларның берсен мәчет тарихы белән бергә үзегез үк ишетә аласыз.

Аксак Тимер яуга чыгып киткәч, яраткан хатыны аның кайтышына сюрприз ясарга тели – иң зур һәм матур мәчет торгызып каршыларга. Төзү эшләрен ул яшь мигъмарга тапшыра. Тегесе исә, матурлыгына хәйран калып, Биби ханымга баштанаяк гашыйк була. Мәчетне дә һич кенә төзеп бетерә алмый тилмерә, имеш...

Биби ханым борчуга кала: ире менә-менә кайтам дип тора, ә сюрприз әзер түгел! Ул мигъмарны ашыктыра башлый, ә мигъмар, кинәт кенә батыраеп китеп, аңа шарт куя. Алга таба бу легенданы теләсә кайсы сәмаркандлы яттан сөйләп күрсәтә ала. Имештер, яшь мигъмар болай ди: «Әгәр үзеңне үбәргә рөхсәт итсәң, мәчет нәкъ вакытына төзелеп бетәчәк!» «Мин сиңа җарияләремнән кайсын телисең, шунысын бүләк итә алам, – ди, ачуы кабарган Биби ханым. – Нәрсәгә сиңа нәкъ менә минем үбүем? Менә бу буялган йомыркаларга кара әле: аларның төсләре барысыныкы да төрле, зурлыгы да, әмма ватып карасаң, эчендә – шул ук бер сары. Без, хатыннар да, нәкъ шулай – бертөрле!»

«Менә ике шәраб савыты. Берсендә – үтә күренмәле сыекча, ягъни су, икенчесендә – ак шәраб. Алар бер-берсенә охшаган, әмма мин иреннәремне якын китерсәм һәм тидерсәм, шәраб иреннәремне яндырып алачак, ә суны мин тоймаячакмын да», – ди мигъмар, теле-телгә йокмыйча.

Биби ханым сюприз нәкъ вакытына әзер булсын өчен, куйган шартка риза була. Мигъмар аны үбәргә иелә, әмма Биби ханым соңгы мизгелдә битен капларга өлгерә. Тик үбү шулкадәр кайнар була ки, мигъмарның эссе тыны, кул аша үтеп кереп, аның битендә эз калдыра.

Бөек Тимур шәһәргә кайта. Аның күз алдында гаҗәеп манзара ачыла – манаралары һәм гөмбәзләре белән балкып... өр-яңа мәчет калкып тора. Әмма Биби ханым йөзендә үбү эзе күреп, ул бик каты ярсый. Хатынына дөреслекне ачарга туры килә.

Әмирнең боерыгына буйсынып, сакчылар шунда ук мигъмарны эзләргә томырыла. Эзәрлекләүчеләрдән качып, мигъмар шәкерте белән бергә мәчет манарасына менә. Ә инде сакчылар йөгереп менеп җитсә, анда аның шәкертен генә табып алалар.

«Остазың кайда?» – дип сорыйлар.

«Остазым үзенә канатлар ясады да очып китте», – ди шәкерт.

Менә шулай тәмамлана әлеге мәхәббәт тарихы. Аны ишетер һәм Көнчыгышның күз явын алырдай мәчетен күрер өчен без, аз да түгел, күп тә түгел, 40 000 сум түләдек. Сүз уңаеннан, һәр биш меңлек купюрага әлеге дә баягы барс сурәте төшерелгән. Безнең акчага күчерсәк, Биби ханым шулкадәр тырышып төзеткән мәчеткә керү хакы нибары 336 сумга гына төшә.

Сәмаркандтагы иң матур мәчетне Аксак Тимернең иң олы һәм яраткан хатыны Биби ханым төзетә.

БАРС № 5.
САКЛАУГА МОХТАҖ... БАРС

Инде сәяхәтебез тәмамланып килгәндә, әлеге елның февралендә Сәмаркандта тагын бер ак барс пәйда булуын беләбез. Аны Inkuzart дигән рәссам БМОның глобаль конференциясе өчен махсус ясаган. Әлеге чара кыргый хайваннарның күченеп йөри торган төрләрен саклауга багышланган. Сак кына атлап килүче ап-ак барс Конгресс-холлда яши хәзер, нәкъ менә шунда Конвенция яклары 14 нче конференциягә җыелган (CMS COP14). Ул вакытта Сәмаркандка күченеп йөри торган төрләрне саклау һәм аларның яшәү урыннарын кайгырту мәсьәләләре буенча стратегияләр булдыру өчен, хакимият башлыклары, галимнәр һәм башка кызыксынган затлар килгән.

Шулай итеп, бу затлы җәнлек шәһәр сагына гына басып калмаган, бүген үзе дә саклауга мохтаҗ булып чыккан.



«ХОХЛОВКА»: ӨЧ ГАСЫР АРЪЯГЫНА СӘЯХӘТ

Михаил Рябинин

Идән такталары колакны ярып шыгырдый, югыйсә бик сак басарга да тырышам кебек. Вакытны борчый күрмим, дим. Хәер, монда ул беркая да ашыкмый, әйтерсең, бөтенләй туктап калган. Шыгырдап торган такталар белән бу ызбага – йөз җитмеш еллап бар, эчендәге җиһазлар да яхшы сакланган. Әнә, балчык ягып чыгарган мич, сәндерә, тәре торган «кызыл почмак», савыт-саба, хуҗаларның кием-салымы. Һәм корым ягылган диварлар – чөнки карага ягалар... Эһ, хуҗаның үзе белән дә сөйләшеп алсаң иде! Ә хуҗабикәнең яңа гына мичтән чыккан щи шулпасын да татып карасаң... Соңгарак калдым шул. Йөз елга...

Суксун районы Сыра авылында XVIII гасырда ук төзелгән әлеге чаң манарасы калку урынга күптән түгел генә күчерелгән.

Хуҗаларның исемнәре дә сакланмаган. Ә менә фамилияләре билгеле – Кудымовлар. Әлеге йорт бирегә – Пермьнең «Хохловка» архитектура-этнография музеена Чулман буеның төньяк-көнбатышындагы Яшкино авылыннан күченеп утыра. Бар да гади һәм кырыс, бернинди артык бизәкләр күзгә ташланмый. XIX гасырда яшәгән коми-пермякларның купшыланып утырырга вакыты да, мөмкинлеге дә булмаган. Ә менә төзүен төзеп тә караганнар – гасырларга калырлык.

– Бу ул замандагы коми-пермякларның типик торагы, – дип сөйли безгә экскурсовод. – Нарат бура, нык, чыдам – гасырлар буена тора алырлык. Төтен чыгармый торган мич, күрәсезме, диварда махсус тишек ясалган, төтен аның аша тышка чыга. Фронтоннарда бернинди такта юк, түбәнең ике ягы тоташканчыга кадәр – тоташ бүрәнәләр генә. Ни өчен шулаймы? Чөнки ул заманда корылмалар бер кадаксыз җыела торган булган, кадак бит – тимердән, ә тимергә – кытлык...

Экскурсоводның сүзләренә ышанмыйча, карап чыгам... Бурага кагып, шакып, сугып карыйм, болдырны, идән такталарын тикшерәм. Чын мәгәр, ник бер кадак булсын. Ышкы, пычкы һәм өтергә белән авыл халкы гаҗәеп оста эш итә белгән шул.

БАЯНДИНДА КУНАКТА

Ярлырак тормышлы Кудымовлар йортында кунак булганнан соң, инде хәлле тормышлысына сугылырга булдык – крестьян Баяндинга. «Хохловка»га килеп урнашканчы, йорт гасыр ярым буена Чердынь өязенең Дмитриевка авылында торган. Кудымов йорты белән чагыштырганда, аерма җир белән күк арасы: Баяндинныкы патша сараена тиң! Ике катлы йортның болдыры да биек баскычлы, каплаулы, хәзерге күзлектән караганда да, соципотека гына түгел...

Түбә астындагы баскычтан күтәрелеп, икенче каттагы бүлмәләргә әләгәм. Монда да ул заманда авыл җирлегенә хас булмаган искиткеч купшылык: ике мич – «голландка» белән русныкы, төтен юллыгы, димәк, диварларга бернинди дә корым кунмый. Затлы, матур комод...

Әйбәт яшәгән Баяндин – авыл кешеләре көнләшеп узгандыр, шәт. Билгеле инде, тоз заводларында да, басу-кырда да көн-төн бил бөкмәгән ул. Николай Михайловичның

Фото: Айдар Мөшәрәпов

йортының беренче катында – сәүдә лавкасы. Җитеш тормышны да сәүдә эшеннән кергән керем тәэмин итә: ашлык, он келәтләре, дисеңме, ат абзары, печәнлек, мал-туар утарлары. Шунда ук – арба белән чаналар, алардан башка буламыни?!

Тик Баяндинга авыл халкы «ак күңләшү» белән караган булса кирәк, алай булмаса, йорт-кураларын революция вакытында яндырып ташлаган булырлар иде. Баяндин үзе дә мал табу өчен җиде кат тирен түккән. Бакчасындагы бер ызбада – буяу остаханәсе. Монда ул киндер буяу белән шөгыльләнгән, бу кәсеп тә өстәмә керем китергән, әлбәттә.

ТӨНЬЯК ЧУЛМАН ХРАМНАРЫН «КИЖИ» БЕЛӘН НИ БЕРЛӘШТЕРӘ?

Бер авылда яшәсәләр, хәлле Баяндин белән фәкыйрь Кудымов аралашкан булыр идеме икән? Чиркәүдә булса гына инде. Авыл җирлегендә элегрәк нәкъ менә чиркәү бөтен яңалык җиткерелә торган урын булган. Анда ишеткәннәргә бергәләп сөенгәннәр дә, көенгәннәр дә. Спас-Преображение чиркәвенә күз салыгыз – аны Чердынь районының Янидор авылыннан «Хохловка»га китергәндә, бик сак эш йөрткәннәр. Ни генә дисәң дә, өч гасырга караган халыкны үзара берләштерү өчен рухи нигез лә ул.

Вакыт һич кенә дә аямаган, каралып киткән ниргәләр, усактан ясалган дулкынсыман чирәпләр – мондыйны бары тик Кижи һәм аның тирә-ягындагы борынгы гыйбадәтханәләрдә генә күрергә була. Бернинди өстәмә метрика-фәлән кирәкми, чиркәү үзенең яшен кычкырып әйтеп тора. Шунысы билгеле: храм өчен агачларны 1702 елда Урал осталары кисеп хәстәрли. Әйтергә кирәк, бу буралар да бер кадаксыз җыелган. Чирәпкә дигән усакларны да балта белән әзерләгәннәр. Чиркәүдә келәүләр 1939 елга кадәр барган, ә аннары инде алты дистә елга Ходай йортын ашлык саклау амбарына әйләндергәннәр.

– Архитекторлар әйтүе буенча, бу чиркәүнең гыйбадәтханә өлешен төгәллəү генә дә уникаль үзенчәлеккә ия: биек чөйсыман өй түбәсенә хачсыман башы чыгып торган «мичкә» урнаштырып куелган, – дип аңлата безгә экскурсовод. – Мондый бизәлеш борынгы рус архитектурасы үрнәкләренә хас, үзенә күрә кабатланмас очрак санала.

Ни кызганыч, чиркәүнең эчке җиһазланышы безнең көннәргә кадәр сакланмаган. Бизәкләп ясаган агач эскәмияләр генә исән-имин калган – вакыт аларга артык орынып өлгермәгән. Интерьерны торгызу өчен дә инде мөмкинлек юк: эче нинди булганын дәлилли торган документлар сакланмаган.

Ә иң гаҗәбе – Спас-Преображение чиркәве әллә кайчангы булса да, ул «Хохловка»да иң борынгысы түгел. Агачтан эшләнгән «Неопалимая купина» Богородица чиркәве сигез елга өлкәнрәк. Аны 1694 елда Сылва елгасы янындагы Тохтарево авылында төзергә керешкәннәр. Пётр I әле үзенең Азов походларына да юл алмаган чакта... Риваять буенча, гыйбадәтханәне Сылва елгасы сулары китергән Богородица тәресе табылган урында төзи башлаганнар. Бәлки, нәкъ менә шуңа да «көймә» рәвешендә корганнардыр: керү урыны белән ризыклану бүлмәсе, храм белән алтарь өлеше – бер күчәрдә.

«Хохловка»да иң матур чаң манарасы да урнашкан, ул әле бөтенләй «яшь», 1781 елда гына «туган». 30 метрлы корылманың очын бик хәтәр очланып торган гөмбәз бизи. 1980 елда «Вокруг света» журналындагы мәкаләдә: «Чаң манарасының чатыры аның диварларына кадәр килеп терәлгән чыршыларның дәвамы кебек шәйләнә, – дип язганнар хәтта. – Суксун районы Сыра авылында XVIII гасырда ук төзелгән әлеге чаң манарасын калку урынга күптән түгел генә күчереп утыртканнар. Әюп Асыловның балта осталарыннан тупланган бригадасы ниргәләп торгызган. Һәм менә хәзер күләгәләр, бизәкләнеп, җылы

Баяндин йорты.

Кара мунча.

Спас-Преображение чиркәве.

Каравыл манарасы – рус агач сак корылмалары үрнәге.

соры диварларга ятты да, манара, әйтерсең, өр-яңадан җанланып китте...»

ТОЗНЫ НИЧЕК ЧЫГАРГАННАР...

Чулман ярындагы күрексез корылмалар. Диварлары, әйтерсең, ниндидер аксыл элпә белән капланган. Бу «аксыл элпә» дигәннәре, баксаң, агачка мәңгегә сеңгән тоз икән. Безнең алдыбызда – узган гасырдан истәлек булып калган «тоз заводы» үрнәге.

Юк, копия түгел, ә чып-чын оригинал. «Хохловка»да мондыйны бары тик ике җирдә генә күрергә була, диләр. Биредә һәм Соликамскидагы элеккеге Усть-Боровск тоз заводы территориясендә урнашкан Тоз тарихы музеенда...

– Пермь өлкәсендә тозны каян чыгарганнар? – дип сорап куя бездән кинәт экскурсовод. – Әлбәттә, тоз эремәсе белән тулы җир асты күлләреннән, – дип, үз сөаленә үзе үк җавап бирергә ашыга ул. – Скважина казып төшкәннәр, аннары насос ярдәмендә эремәне агач торбалар буйлап өскә кудырганнар, ә насосларны ат көче белән эшләткәннәр. Шул рәвешле сыеклыкны эремә тутыру манарасына суыртканнар.

Менә ул манара – ничектер каравыл башнясын да хәтерләтә. XX гасыр башына кадәр егерме ел элек юан, калын бүрәнәләрдән корып куелган. Эш стажына килсәк, анысы да йөз елга тула. Усть-Боровскидагы тоз заводына хезмәт иткән. «Пенсиягә» бары тик 1972 елда гына киткән, ә бу инде безнең кинәнеп галәмгә очкан еллар...

Янәшәдә генә – тоз бурасы, аңа эремә тутырганнар, тозның утырып, урнашып бетүен көткәннәр. Бураны агач борыслар белән бик һәйбәтләп уратып, беркетеп куйганнар, югыйсә тоз «җимереп» чыгарга мөмкин булган. Җайланманы үз вакытында Чулман елгасы буйлап агызып китергәннәр: тоз белән укмашып каткан, ысланган бураны реставраторлар таратып карарга шикләнгән, яңадан җыеп ала алмабыз, дип уйлаганнар. Шулай итеп, өч йөз километрны бура баржада йөзгән...

Тагын бер бик кадерле экспонат. Тоз кайнату йорты. Нәкъ менә шунда эремә без күрергә күнеккән тозга әйләнгән дә инде. Кайнату йорты эчендә – мич, өстендә – алагаем зур металл таба (чрен), аның мәйданы йөз квадрат метрдан да артыграк. Эремә табада кристаллга калганчы кайнап торган...

Хәзер инде бу шаккаткыч процессны күз алдына китереп карап кына була: әйтерсең, капкайнар тәмугның үзе. Дөрес, фотографияләр дә тоярга ярдәм итә, алар биредә экспозицияне тулыландырып тора.

Монда сезгә шулай ук «пермяк – тозлы колак» дигән гыйбарәнең каян килеп чыгышын да аңлатачаклар:

– Чулман буендагы корылманы күрәсезме? Ул – тоз амбары, – ди музей сакчысы. – Анда тоз ташучылар, әзер продуктны капчыкларга тутырып, тиешле җиргә илткән. 80 килограммлы капчыкларны аркага салып ташыганнар, тоз колакларын һәм баш артын, җилкәләрен «ашаган». Тоз ташучы булып ирләр генә түгел, ә хатын-кызлар да эшләгән...

Боларны тыңлаганнан соң, шунда ук өеңдәге уңайлы-җайлы тормышны искә төшереп, куырылып куясың.

КРЕСТЬЯН ЫЗБАСЫНДАГЫ ВЕРНИСАЖ

Уңайлы тормыш, дигәннән, аны эзләп, кунакка рус крестьяны Васильевка керәм. XIX гасырның 80 нче елларында торгызылган ызба элегрәк Чердынь өязенең Зур Гадья авылында балкып утырган. Тыштан караганда, барысы да коми-пермякларныкы кебек үк: ызба – өйалды – ызба – барысы да бер түбә астында, тик һәр торак өлешендә үз миче булган. Бүрәнәләрдән җыелган ызба – алагаем зур, диаметрга сиксән сантиметр!

Күрәсең, гаилә дә зур булган, алай гына да түгел, шактый хәлле, җитеш тормышлы да. Моны агач киштәләргә кадәр чәчәк белән бизәлгән җиһазлар дәлилләп тора. Бу өй бизәге шул чаклардагы Төньяк Чулман буе ызбаларының «фишкасы» икән. Андыйны бары тик шушында гына очратырга була, диләр.

Әлбәттә, барлык йортларда да очрамый ул: бизәкләргә заказ бирү нибары хәлле хуҗаларның гына көченнән килгән. Гадәттә, интерьерның иң күзгә ташланып торган урыннары бизәлгән. Васильевларның төп бизәге –

шау чәчәктә утырган тормыш агачы, ә агачны сайрар кошлар уратып алган. Мондый бизәкне бик яратып куллана торган булганнар. Ул йорт-ыруны саклый торган көчкә дә ия, дип тә ышанганнар.

Бүген Васильевлар йортында – тулы вернисаж. Пермь өлкәсендәге йорт бизәкләренең барлык төрләрен дә китереп урнаштырганнар аларга. Кабалар, көянтәләр, борынгының гаҗәеп кул осталары бизәгән савыт-сабалар, кыскасы, чын сәнгать әсәрләре.

КИЛӘЧӘК БУЫННАР ХАКЫНА...

Элекке заманнарда Чулман буенда ничек яшәгәннәрен хәтердә тоткан һәм сакланып калган байлыкларга күз-колак булган, «Хохловка»ның үз сагында да торган каравыл манарасы – шулай ук борынгы агач төзелеш сәнгате һәйкәле. Аны бирегә Сылва елгасы ярындагы Торговище авылыннан китереп куйганнар. Манара, нәкъ аңа тиешле булганча, биек үр башында калкып утыра – чит-ят берәр хәрәкәт булса, дошман күренсә, каравылда торучылар шунда ук шәйләп алырга һәм чаң сугарга тиеш...

Кайчандыр манара «Торговижский острожок» сак корылмаларының бер өлеше булган. Аны 1664 елда Кунгур шәһәрен көньяктан һөҗүм иткән дошманнардан саклар өчен төзегәннәр. Бу сигезләп манарасы булган агач ныгытма, ул нык һәм берәгәйле казык койма белән уратып алынган, ике мәртәбә дошманның каты һөҗүмен кайтарган. 1671 һәм 1708 елларда, баскыннар кимегәч, ул кирәксезгә әйләнгән, аны сүткәннәр. Ә менә каравыл манарасын калдырганнар – хәтәр кабиләләрне, булган орышларны хәтердә тотсыннар, онытмасыннар өчен. Дөрес, янгын чыгып, каравыл манарасы харап булган, әмма җирле халык, аны югалтуга разый булмыйча, 1905 елда үз көче белән манараны яңадан торгызган.

«Хохловка»да болай сөйлиләр: Торговище халкы өчен манара – бик кадерле ядкарь. Аның каршында авыл кешеләре Беренче бөтендөнья сугышына киткәндә изге әләмнәр – хоругвьлар белән сурәткә төшкән. Аның янында бүрәнәләрдә муртайган сөякләрен җылытып авыл картлары утырырга ярата торган булган...

Шулай да ядкарьне музейга алырга җыенуларын белеп алгач, берәү дә каршы килми. Үз теләкләре белән тапшыралар, чөнки музейчылар, экспонат буларак, аны кадерләп саклаячак һәм киләчәк буыннарга илтеп җиткерәчәк.

«Хохловка»дан киткәндә, мин Олы Мәңгәрдәге (Татарстан) татар төзелеш сәнгате җәүһәре – Вәлиулла Бакиров йортын искә төшердем. Ул әле нык булса да, тәрәзә-ишекләре каплаулы килеш, әйтерсең, язмышының аяныч хәл ителәчәген көтеп утыра... Ә күпме әле бездә узган гасырлардан калган андый йортлар, гыйбадәтханәләр, хуҗалык корылмалары?! Тып-тын гына картаялар, янтаялар һәм җимерелеп юкка чыгалар. Язмышлары турында кайгыртучыларны да, реставраторларны да көтеп җиткермичә, билгеле.

Үзебезнең үткәнгә үзебез үк битараф булмас өчен, әйдәгез әле, аларны бер урында – «Татарстан» журналында – җыеп карыйк? Барысын да – татарныкын, русныкын, марины кын... Һәм тарихыбызга карата да саграк булырга өйрәник. Вакыт торган саен азрак калып бара...



Тоз эремәсен суырту манарасы ничектер каравыл башнясын да хәтерләтә. Ул XX гасыр башына кадәр егерме ел элек юан, калын бүрәнәләрдән корып куелган.

Варница – тоз кайнату йорты.

ТАМЧЫДАН КҮЛ ҖЫЕЛА
(ВОЛОНТЁР КӨНДӘЛЕГЕ)

Автор фотолары

Дмитрий Сивков

...Икенче көнне Лысенький нихәл икән, дип, бүлеккә керсәм, ни күрим: үзе – юк, урын-җирен алыштырып җәйгәннәр. Беренче уем: «Моргта микәнни?..» Ул уй мине, кинәт кенә килеп бәрелгән үтәли җилне тойгандай, куырылып куярга мәҗбүр итте.

Күпьеллык фронт тормышы белән яшәгән шәһәрдә – үзгә бер атмосфера. Хәзер инде алгы сызык Донецкидан шактый читкә чигерелгән, әмма һөҗүмнәр булгалап тора икән. Дөрес, элеккегегә караганда азрак корбаннар һәм җимерелүләр белән, тик шулай да... Шартлау авазлары, шул исәптән ПВО гөрелтесе дә ишетелеп тора.

Фронтның янәшәдә генә икәнлеге иң нык сизелгән урын – Республика клиник хастаханәсе. Нейрохирургия хезмәтенең кабул итү бүлеге санитары сыйфатында төнге дежурга калгач, моны бигрәк тә тирән тоясың. Чөнки санприёмникка фронттан китерелгән яралылар да, гади кешеләр дә тоташ бер агым булып агыла: караватыннан очып төшеп башы ярылган бала, дисеңме, ядрә чәрдәкләгән сугышчымы, инсульт бәргән кешеме...

Беренче төнне үк муены җәрәхәтләнгән дошман солдатын китерделәр. «Безнекеләргә әле күтәргә туры килә, ә менә «укроплар»ны гел чиратсыз кертәләр», – дип сукранып ала медикларның берсе. «Харківська обласна клінічна лікарня»да эшләүче медиклар да шулай итәме икән, алар да «русня»лардан шулай сукраналармы икән, дип уйлап куям мин.

Калинин исемендәге хастаханәнең неврология хезмәте бүлеге.

ИРТӘНГЕ РИФМА

Курахово, Курахово, Курахово... Телеграм-каналлардан бу атама санприёмниктагы сөйләшүләргә күчә. Беренче сменадан соң, тулай торакка таба атлаганда, аяк астындагы яфрак шыгырдавы да кур-ах-о-во... булып ишетелә. Шулай кабатлана-кабатлана, әллә ни куандырмый торган гади генә рифма пәйда була: «ахово».

Шулай да бу төн начар узды дияргә тел әйләнми: беркемне каталкада китермәделәр, катетер куелган, канлы бинтка уралганнар да булмады. Барысы да – үз аягында, җиңелчә яралар һәм җәрәхәтләр белән генә. Реанимациягә дә беркемне кертмәдек, 9 корпуска (моргка) да. Кайсыларын бүлекләргә урнаштырдылар, кайсыларын эвакуациягә озаттылар. Шөкер!

Ә рифмага килгәндә... Әйбәтләп йоклап, көч җыеп алгач, яңалары килер әле, дип өметләнәсең. Әмма аңарчы барыбер иялөшә төшү кирәк. Күршедәгеләргә – бигрәк тә. Тулай

Кальмиус елгасы яры.

торактан йөз метр арада гына – Фәрештәләр аллеясе чөнки. Чүкеп ясалган роза чәчәкләре гильзалар, күгәрченнәр белән чиратлаштырып беркетелгән зур металл арка... Ул Донбасста сугыш барышында һәлак булган балалар истәлегенә ясалган.

Килеп урнашкач, иң беренче эш итеп, без шунда бардык. Гранит плитә каршында бер сүз дә дәшмичә басып тордык. Ташка үлгән балаларның исемнәре белән яшьләре алфавит тәртибендә чокылган. Һәр юлда аерым бер гаиләнең коточкыч йөрәк ярасы гына түгел, ә тулы бер халыкның, илнең фаҗигасе дә яшеренгән булуын барыбыз да яхшы аңлый. Бу яраны инде берни төзәтә алмаячагын да. Бу ун көндә кулыбыздан килгәннең барысын да эшләргә әчтән генә ант бирәбез, гәрчә моның диңгездәге тамчы гына икәнен аңласак та.

ЫГЫ-ЗЫГЫ

Яңа килгән санитар-волонтёрны госпиталь персоналы арасыннан бик тиз танып була. Беренчедән, аның сагайган карашы шунда ук игътибарны җәлеп итә. Икенчедән, башына мәгънәсез алсу башлык киелгән булыр, битендә – маска, кулында – латекс перчаткалар, аягында – бахила. Гуманитар миссия координаторы өйрәткәнчә киенгән булыр ул.

Беренче сменада чакта ук кафель җәелгән идәндә чаж-чож килә башлагач, мөрәҗәгатьләрне теркәп утыручы шәфкать туташы, ачуы килеп:

– Салыгыз сана шул бахилаларны! Алар сезгә бик кирәкме? – дип куйды.

Берничә сменадан соң инде барысын да аңлый башлыйсың. Баштагы теге әкәмәт нәмәрсә урынына инде – чып-чын хирургия башлыгы, битлек – бик кирәк булганда гына, бахила (тукта, нәрсә соң әле ул?). Дөрес, син әле аборигеннардан аермалы буларак, перчатка кими булдыра алмыйсың. Әйтик, китерелгән яралыларны ялан кул белән әйләндерергә базмыйсың.

Акрынлап иялəшәсең. Икенче көн кизү торганда санприёмникка керәм. Карыйм, таныш түгел смена. Берәү дә сиңа игътибар итми: берсе телефоннан кемгәдер түземсезләнеп нидер аңлата, икенчесе кибет болдырыннан мәтәлгән пациентның хәле ни дәрәҗәдә авыр икәнне билгеләргә тырыша... Мине күрүче дә юк. Ну ярар, юк икән – юк инде. Урындыкка чүмәшеп, кулга телефонны алам.

Ярты сәгатьләп уза. Медицина факультетының өченче курс студенты – санитарка Лена килеп керә. Без таныш – алдагы төнне дежурда бергә булган идек. Миңа карап:

– Канны анализга, ЭКГны расшифровкага илтәсезме? – ди.

– Илтәм, – дим.

Шулчак шәфкать туташы:

– Сез волонтёрмыни? Мин башка корпустан килгән табиб дип торам, – ди.

– Мин кем икәнемне әйттем дә бит, сезнең монда – ыгы-зыгы шул, – дим.

– Безнең монда – гел ыгы-зыгы...

ҺӘР ХАСТАНЫҢ – ҮЗ ӘФСЕНЕ

Беренче мәлләрдә кешеләрнең РФ Кораллы көчләре белән контракт төзегәннән соң авырулары беркая да китмәгәне онытыла кебек. Әмма алар юкка чыкмый гына түгел, яңалары өстәлә тора. Неврология хезмәтенең кабул итү бүлегенә кеше баш, муен тирәсендәге җәрәхәтләр белән генә түгел, башка сәбәпләр аркасында

Үзем бик тиз иялəштем.

да эләгергә мөмкин. Менә хәрби медиклар яшь кенә бер сугышчыны алып килә – инсульт дигән шикләре бар: кан басымы 180 гә 120 югарылыгында. Медицина взводы табибының берсе аңа магнезий кадаган (монда күптән сыналган ысулларны хөрмәт итәләр), икенчесе госпитальгә озата килгән. Башына томография ясагач, инсульт расланмады.

Кардиолог ханым егеткә диагноз куя: гипертония кризы.

– 28 яшьтә кан басымы мондый булырга тиеш түгел, – ди ул, тавышына шелтә чыгарып, янәсе, ник үзегезне карамыйсыз, яшь бит әле сез.

– Мин җ-җ-җ-җиде к-к-к-контузия а-алдым... – дип суза егет.

– Ә тотлыгу – бала чактанмы?

– Икенче к-к-к-контузиядән с-с-с-соң... Егерме ик-к-к-кедә...

Табиб киңәшләрнең Гугл аша да эзләп табарга мөмкин булган киңәйтелгән исемлегенә күчә.

– Сез миңа төгәл әйтегез: ситуация кабатлана калса, миңа нишләргә? – дип, командирларча кырыс тавыш белән бүлдерә аны хәрби табиб.

Алар чыгып китә. Алдан күп тапкырлар контузия алган, тотлыга башлаган егет атлый, аның артыннан – сул аягына күзгә күренерлек аксаган табиб. Аның медсумкасына берничә мәзәк тә, гыйбрәтле дә билге тегелгән. Шуларның берсендә: «Бөтен авырулардан әфсен (мат) укып терелтәм».

УҢЫШ САНИТАРЫ

«Сез – бәхетле санитар, чөнки чиркәүгә йөрисез», – диде миңа өченче көн кизү торганда шәфкать туташы.

Эш менә нәрсәдә икән: мин сменага чыгуга, пациентларны азрак китерә башлыйлар, ди. Сезгә кадәр дә, аннан соң да – Ленин проспектында «час пик» диярсең, ә менә сезнең белән – курорттагы кебек. Чәй йотып алырга, хәтта бераз черем итәргә дә җай табыла.

Минем диндарлыгым хакындагы нәтиҗәне, күрәсең, якшәмбе көнне чыгарганнар. Агапит Киев-Печерский госпиталь храмында узган ял көне гыйбадәтенә барган идем. Әле аннан соң, чиркәү кырыендагы сукмаклардан яфрак җыеп, капчыкларга тутырып та йөрдем. Ярар соң, дим эчемнән генә, алга таба да уйлый бирсеннәр шулай. Уңыш китерү – начар түгел бит. Коллегага безнең барыбызның да Патриарх гуманитар миссиясе волонтёрлары икәнебезне исенә төшердем, шулай булгач, бәлки, Ходай безне күбрәк үз канаты астына аладыр.

Сүз уңаеннан, миссиядәге волонтёрлыкка пациентларны күчергәндә-йөрткәндә булышу; иртәнге һәм төшке ашны китерү; пищеблокта яшелчә чистарту; анализларны илтү һәм аларның нәтиҗәләрен алу кебек даими вазыйфалардан тыш, чикләүләр дә керә. Мисал өчен: «Без персоналга кисәтү ясамыйбыз, бәхәсләшмибез, киңәш бирмибез, пациентлар һәм персонал белән шәхси темаларга сөйләшмибез, аларны җәрәхәтли торган темаларны кузгатмыйбыз (монда ничек эләктегез? монда яшәү ничегрәк? балаларыгыз кайда? – бу зур дорфалык санала һәм катгый тыела); телефон номерыбызны пациентларга бирмибез; берни сатып алырга да, кемнәндер (кемгәдер) нәрсә дә булса тапшырырга да вәгъдә итмибез».

Хәмер куллану, азартлы уеннар уйнау шулай ук катгый тыела. Мин бу шартлар белән җиңел килешәм, алар миңа авыр бирелә дип әйтә алмыйм. Ә менә журналист, ММЧ хезмәткәре буларак чираттагы таләп белән кыенгарак килә: «Журналистлар, пресса белән матбугат хезмәте яисә координатор рөхсәтеннән башка аралашырга ярамый». Нишләргә дә белмәссең. Хәер, әле бит үз-үзең белән аралашуга тыю керткәннәре юк, көндәлек алып бару – асылда, шул буладыр да инде.

ЮЛДАН – ХӘВЕФСЕЗРӘК

Бала чактан ук юлны булдыра алганча кистереп йөрергә яратам. Баштарак моны интуитив рәвештә эшли идем. Пифагор теоремасы белән танышкач, бу гадәтем фәнни нигезләнде, «гипотенуза буенча йөрү» дим мин моны.

Әмма монда, Донецкида, бу гадәттән баш тартырга туры килде. Координаторыбыз Екатерина мине беренче тапкыр кизү торырга озата чыкканда, аны яфрак түшәлгән газонны кистереп узарга әйди башлагач, нык итеп:

– Әйдәгез, юлдан гына барыйк, - диде.

– Газон аша кыскарак килеп чыга бит, – дип, аргументлар китерергә тотындым мин. Ярый әле геометрия нигезләрен аңлатудан тыелып калырга акыл җитте.

Хәрби табиблар яралыны санприёмникка алып килделәр.

Гильзалар кыршылып беткән, димәк, аларны озак вакыт таптап йөргәннәр, дип фаразларга була.

– Юлдан – куркынычсызрак, – диде кырыс тавыш белән юлдашым.

Моңа каршы минем бернинди дә дәлилем юк иде. Барышлый Екатерина әле күптән түгел генә бөтен хастаханә территориясендә «Лепесток» миналары күп булганлыгы турында сөйләде. Әнә шунан бирле барысы да бары тик билгеле сукмаклардан гына йөрергә өйрәнгән.

– Аннары сапёрлар чистартты, әлбәттә, әмма бит «сюрпирз»ның кайда яшеренеп калганын кем белә. Яфрак астында ни ятканын тиз генә абайлап бетермисең, – аның бу сүзләреннән соң бөек грек теоремаларына әйләнеп кайтырга җөрьәт итмәдем инде.

Кичен, чәйгә утыргач, тулай торакта да бу хакта сөйләдем.

Волонтёр Екатерина, минем сүзләремне әлдереп алып, болай диде:

– Ә мине әбием кечкенә чагымнан ук бары юлдан гына йөрергә өйрәтте. Шулай берчак кистереп узарга теләгән идем, ул мине итәгемнән тартып туктатты: «Гомереңне кыскартасың алай итеп!» – диде. Миңа әле тугыз яшь кенә иде, әмма программа башыма кереп урнашты. Шуңа мин сез әйткән гипотенуза буйлап йөрүне башыма да китермәс идем.

Екатеринаның әбисе белми сөйләмәгән, бу хәвефнең бер утыз елдан чынлап та тормышка ашасын алдан тойган диярсең.

Координаторның сүзләренә тагын да җитдирәк карарга гипотенузаларның берсендә юлыккан «табылдыклар» да ярдәм итте: АК-74 тән 5,45 мм калибрлы ике патрон. Гильзалар кыршылып беткән, димәк, аларны озак вакыт таптап йөргәннәр, дип фаразларга була. Әйтик, юлда төшеп калган вак тиеннәргә игътибар итми йөрибез бит, шуның кебек.

КОШ КАДӘРЛЕ ГЕНӘ ӘБЕКӘЙ

Неврология хезмәтенең кабул итү бүлеге санитары Ирина биредә бик күптәннән эшли икән. Без төнге сменада өч мәртәбә бергә кизү тордык, беренчесендә һәм соңгысында - икәү генә. Ә бу аңында булмаган, әйтик, центнерга якын авырлыктагы яралыны китергәндә, бер дә җиңел түгел. КТ белән рентгенда хәрби медиклар булыша әле, ә аннары алар китеп бара. Операция бүлмәсенә керткәндә, авыру безнең карамакка гына кала. Анда әйләндерергә дә, күчерергә дә кирәк, шулай ук – юарга, кырындырырга...

Беренче сменада мин бу кош кадәр генә гәүдәле әбекәй белән дежурлыкны ничек кенә ерып чыгарбыз икән, дип борчылдым. Ә аннары, шаккатып, шуны аңладым: аңа мин дә кирәк түгел шикелле.

Менә бераз хәл җыярга туктадык. Ирина бераз сукранып алды: арыдым, сәламәтлек тә юк, тормыш та җиңеләйми, ди. Тыңлап торсаң, аннан да мескенрәк, аннан да бәхетсезрәк кеше юк инде, һәрхәлдә Донбасста. Тик менә авыруны яки яралыны китерүләре була, аңа, әйтерсең, әллә каян көч иңә: шунда ук эшлекле кыяфәт алып, процесс белән идарә итәргә керешә ул. Зарлану-сукрануның эзе дә калмый.

Менә беркөн якташымны китерделәр, документларына караганда – Әлмәтнеке. Исеме – Ринат. Чәрдәкле яра һәм кулы сынган, маңгаенда, күзендә – бинт, Илизаров аппараты куелган. «Йоклый», әмма бик тынгысыз – кулларын-аякларын бертуктаусыз селкетеп тора, биш минут саен тәмәке тартырга чыгарга талпына. Йоклата торган препаратны кадавын-кадаганнар, әмма аның 120 килолы гәүдәсенә аз булган, күрәсең. Медвзводтагы бурят-медиклар (әйтергә кирәк, шәп егетләр) безгә хәерле смена теләделәр дә эвакуациягә китеп бардылар. Кан алырга кирәк. Ринатның кан тамырлары позициядәге снайперлардан да болайрак «яшеренгән». Җитмәсә, гәүдәсен тик тотмый, гел селкенә. Илизаров аппаратын да кузгатып кына тора, аның белән үзенә зыян китермәсен дип, күз-колак булырга кирәк.

Мин аның кулларын кысып тотам, Ирина аякларын бәйли. Әйтергә кирәк, әзмәверләрне бар дип тә белмәгән оста көрәшчеләрнең үзе кебек кылана, авыруның һәр хәрәкәтен шәрехләп тә бара. Медбрат кан тамырын табарга тырышып изалана. Бу раунд бер 10 минутка сузыла, без бер балл яулап, алга ыргылабыз – хәзер инде Ринатның чәчен аласы бар. Мине иң борчыганы өченче раунд – яраларны тегү... Әмма бәйләүләрне салдыргач, барыбыз да җиңел сулыйбыз: медиклар инде яраларны тегеп бәйләгән икән. (Уф!) Реанимациягә озатыр алдыннан аяк-кулларындагы караны, пычракны гына юып-сөртеп аласы кала. Ирина моны бик оста, артык нечкәреп тормыйча, җәһәт итеп башкарып чыга. Үзе шул арада моның кадәр пычракны каян табуын ачыкларга тырыша, сораулар яудыра.

– Ул бит сезне барыбер ишетми, – дим мин аңа, сугышчыны жәлләп һәм сорауларның мәгънәсез булуын ассызыклап.

– Ишетмәс сиңа! Барысын да ишетә! Ишетмәгәнгә салышып кына ята ул! – дип, «сорау» алуын дәвам итә Ирина.

Ахыр чиктә, башы кырылган, үзе юылган, бәйләүләре алыштырылган Ринатны реанимациягә илтәбез. Менә монысы – иң мөһиме! Ә кош кадәрле генә әбекәйнең эш стиле, чыннан да, үзенә бер. Макеевкада түбәсе тишек йортта тора икән ул, шулкадәр алҗый ки, кайчак эштән кайтканда-килгәндә йоклап китеп, тукталышында төшмичә дә кала...

Әмма Иринаның стиленә чираттагы пациентны китергәч, үзең үк таң каласың. Донецк сөйләшүе ярылып торган исерек мажор, иртәнге сәгать дүрттә кибет болдырыннан галәмгә, дөресрәге, түбәнгә очып, йөзен ярган. Мин менә монысын керткәч, Иринаның Ринатка карата әле бик йомшак булганын аңлап алам.

Санитар Ирина.

Бу минем санприёмниктагы соңгы дежур сменам, иртәгә – Мәскәүгә. Иртән, инде китәргә кузгалганда, Ирина, чиктән тыш алҗыган булуына карамастан, бүлеккә керә торган җирдәге яфракларны җыештырып алырга һәм юлны себереп куярга тәкъдим итә. Мондый дембель аккордыннан баш тартып буламы соң инде, йә?!

ЛУНА ЮГАЛМАСКА КУШТЫ

Мәскәүгә юлда да уйларың белән берөзлексез Донецкига кайтасың. Истәлекләр... алар бик күп. Менә иң кадерлеләрдән берсе.

...Сугышчы спецприёмник бригадасы каршында Бөек хөкем алдына килеп эләккәндәй – яп-ялангач. Яше кырыклардан узган, Киров өлкәсеннән, доброволец. Үз аңында. Аңа йон одеял астында бер дә җылы түгел, җитмәсә, күренеп тора, ояла, уңайсызлана. Шуңа өстәп, әйләндереп караганда, катетерга тоташтырылган, төнге бәвеле тулып өлгергән пакет комачаулый. Ярый әле үзен читтән күрми, дип уйлап куясың: күз төпләрендә гематомалар, башлыгы астыннан укмашып беткән чәчләре тырпаеп тора, сакалы каралып төртеп чыккан, кан белән кутыр аралаш...

Кулының бер чугы бинтланган, икенчесендә ул астматик ингаляторы белән ниндидер кәгазь кисәген кысып тоткан. Ул кәгазьне аңа эвакуация командасыннан бер хатын хушлашканда тоттырган, болай дип тә пышылдаган: «Югалма, яме, Лысенький...»

Лысенькийның югалып калган карашы хатын киткән якка төбәлгән. Аны авыр уйлардан араларга тырышып, өстенә тагын бер одеял ябам, колак артынарак шуып төшкән хачы белән бауга тагылган РФ Кораллы көчләре жетонын күкрәгенә табарак җайлап куям.

– Рәхмәт, – ди ул. – Иренгә су тидерергә ярыймы? Үлеп эчәсе килә... Күптән түзәм.

Хирургтан сорыйм, аның җавабы катгый: «Ярамый әле!» Сугышчыга әйтергә мәҗбүр булам – «ярамый» дип баш чайкыйм. Аның карашында – тагын өметсезлек.

Операция өстәлендә башындагы чүпрәген алып ташлагач, хатынның аны ник шулай атавы ачыклана. Башы пелзш, бөтен башы буйлап чәрдәкле ярадан калган кратерлар – алардан кыйпылчыкларны инде чүпләп алганнар, хәзер аларны тегәргә генә калган. Корсагына әйләндереп яткыралар, баш артында да хәлләр әллә ни яхшы түгел, аз гына тырпаеп калган чәчләрен дә кырып алалар.

– Менә, Лысенький идең, инде хәзер тоташ Лысый, – дип, шаяртмак булам мин. Яралы ишетә, баш кагып куя, әмма карашында барыбер өмет шәйләнми.

Хирург аның башын теккән арада без Ирина белән водород эремәсе белән аның

кул-аякларындагы пычракны юабыз. Ингалятор белән кәгазь кисәген кулыннан каерып алырга туры килә. Башта Лысенький аларны бирмәскә дип карыша, әйтерсең, без аны тормыш белән бәйләп торган соңгы җептән мәхрүм итәргә җыенабыз. Шулай да, кире кайтарып бирәбез, дип үгетли торгач, учын ача. Үземне тыеп кала алмыйча, кәгазьгә күз төшерәм. Анда эре хәрефләр белән телефон номеры теркәлгән һәм «Луна» дип язылган.

Тегеп бетергәч, юындыргач, яңа башлык кидергәч һәм, ниһаять, су да йоттыргач, сугышчыбызга бераз җан кереп китә. Ак футболка белән трусик, трикога, ягъни гуманитаркага да киендереп алгач, тагын да ныграк тернәкләнгәндәй күренә. Безнең ярдәм белән хәтта кресло-каталкага да күчеп утырырга көч таба.

Бу инде сәгать ярым элек китерелгән өметсез җан иясе түгел, бөтенләй башка кеше, дип уйлап куям, күңелем җылынып. Кызганыч, Луна күрмәде аның эченә җан кереп киткәнне, дип тә уйлыйм. Ул да, ахрысы, нәкъ шуны уйлап, кинәт кенә дәшеп куя: «Записка...» Аңа записка белән ингаляторын тоттырабыз – ул аларны инде чиста бармаклары белән эләктереп ала да каты итеп кыса.

...Икенче көнне Лысенький нихәл икән, дип, бүлеккә керсәм, ни күрәм: үзе – юк, урын-җирен алыштырып җәйгәннәр. Беренче уем: «Моргта микәнни?..» Ул уй мине, кинәт кенә килеп бәрелгән үтәли җилне тойгандай, куырылып куярга мәҗбүр итә.

– Ә Лысенький кайда? – дип сорыйм санитаркадан.

– Әй, борчылмагыз, сезнең солдатны эвакуациягә озаттылар. Сау-таза, үзенең ике аягында китте.

16 ноябрь төнендә, ай тулганда, башкача була да алмас иде, мөгаен. Аңа бит Луна югалмаска кушкан иде.

Шундый-шундый хәлләр менә. Әлегә. Алга таба күз күрер.

РИММА ИБРАҺИМОВА: «ЯШӘГӘН САЕН ЯШИСЕ КИЛӘ...»

Руфия Фазылова

Тыйнак, зәвыклы, көчле тавышлы... Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимовага бу сыйфатларның барысы да туры килә. Төрле гайбәтләрдән өстен торган Римма апа гомере буе татар халкына хезмәт итте дисәм, һич арттыру булмас. Советлар Союзын аркылыга-буйга гизгән, Польша, Финляндия, Төркия, Венгрия, Чехословакия сәхнәләрен бизәгән шәхес ул... Кая барса да, Римма апаны көчле алкышлар белән озатканнар.

Талантлы җырчы, тәҗрибәле мөгаллимә бүген ничек яши? Күпләрнең мәхәббәтен яулаган җырчыбызның өендә булып, үзебезне кызыксындырган сорауларга җавап эзләдек.

– Римма апа, сез үзегезне бәхетле йолдыз астында туган кеше дип әйтә аласызмы? Нәкъ сез Казанга килгән елны, Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә Мәскәүдә укыту өчен төркем җыйганнар. Һәм сезне шунда алганнар. Бу хәл бәхетле билет оту белән бер булдымы?

– Әлбәттә, чөнки конкурс бик зур иде! Шуннан узу минем өчен генә түгел, башкалар өчен дә чын бәхет булды. Мәктәпне тәмамлап, теге яки бу уку йортына керәбез дип хыялланып йөргән балалар идек. Һәм безгә шундый мөмкинлек туды! Клара Хәйретдинова, Рабига Сибгатуллина, Зиннур Нурмөхәммәтов һәм башкалар – ундүрт егет-кыз Мәскәүгә юл тоттык. Ул конкурста мин «Эзләдем, бәгърем, сине» җырын башкардым. Дөресен әйтим, узармын дип бер

Фотолар Римма Ибраһимованың шәхси архивыннан

дә уйламадым. Күрәсең, комиссия әгъзалары тавышымны ошаткан. Югыйсә музыкаль белемем юк, гади авыл кызы бит инде. Соңыннан эти-әниләребезне дә Казанга чакырдылар, җыелыш җыйдылар. Әлбәттә, балаларының Мәскәү хәтле Мәскәүгә барып укуларына алар каршы килмәде. Дәүләт хисабына белем алабыз бит, яшәү дә бушка.

– Мәскәүдә белем алу сезгә нәрсә бирде? Сез кемнәргә рәхмәтле?

– Башта шуны әйтим: Казаннан килгән ундүрт егет-кыз да җырчы булырга укымадык, арада биючеләр, музыкантлар, сүз осталары да бар иде. Милли республикадан килгән яшьләр буларак, Мәскәүдә күбрәк татарча укыттылар. Менә шуларны хәзер кайта-кайта уйлап утырам: нинди заманалар булган бит. Төркемебезнең кураторы Мәхмүт Нигъмәтҗан улы Нигъмәтҗановка рәхмәт. Казан филармониясе базасында Мәскәүдә укуыбызны ул юллап йөрде. Ул булмаса, бу эшне кем оештырыр иде икән?

Мәскәүдә безне ул заманның бик атаклы музыканты, җырчы Георгий Павлович Виноградов укытты. Профессиональ яктан үсәргә ярдәм итте. Безнең бәхеткә менә шундый тәҗрибәле мөгаллим туры килде. Вокалдан тыш, биюгә, сәнгатьле сөйләм теленә дә өйрәндек. Спорт та булды. Кыскасы, максатчан рәвештә бездән сәхнә кешеләре, артист ясадылар. Нәтиҗәдә, анда белем алган бөтен яшьләр дә сәнгать юлыннан китте.

– Казанга кайткач та башта музыка училищесында, аннан соң Казан дәүләт мәдәният институтында белем алгансыз. Югыйсә дипломсыз да җырлап, эшләп йөрергә мөмкинлек булгандыр?

– Әлбәттә, белем туплауны дәвам иттем. Мәскәүдә ике ел гына укыдык. Казанга кайткач, музыка училищесына керергә авыр булмады. Әйе, җырлап йөрер өчен вокал буенча белем җиткән дә булыр иде. Ә тулы музыкаль белем өчен, һичшиксез, укырга кирәк. Мин ул вакытта инде Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләп йөри идем: гастрольләр, концертлар... Уку белән эш бергә үрелеп барды. Ә Казан дәүләт мәдәният институтын читтән торып тәмамладым.

– Римма апа, бүгенге татар эстрадасына мөнәсәбәтегез нинди? Өч ноталы көйләр, бер үк тапталган сүзле җыр текстлары сезне борчымыймы?

– Борчый. Элек шагыйрьләр язган шигырьләрне тулы бер комиссия карый иде. Ул худсоветлар аша җыр чыгару сират күперен кичүгә тиң булды. Радиога җыр алып килергә Рафаэль Ильясовтан кот очып тора. Бүген исә акча түләсәң, теләсә нинди җы-

Римма Ибраһимова әнисе һәм бертуганнары янәшәсендә.



Әтисе белән.

Филармониядә эшләгән чак.

рыңны радио һәм телевидениедән әйләндерәләр. Бу хакта күптән сөйлибез. Ләкин бернәрсә дә үзгәрми.

– Татар җырчылары арасыннан кемнәр белән дус булдыгыз? Кемнәрне остазым дип саныйсыз?

– Казанга кайткач, Рәхилә Хәйдәровна Мифтаховада укыдым. Аның белән дуэтлар да җырладык. Мин аңа бик рәхмәтле. Кызганыч, арабыздан иртә китте, алтмыш яшенә дә җитмәде.

Дус дигәннән, бер дошманым да юк иде. Кешедән көнләшмәдем, үз юлымнан бардым да бардым. Мәскәүдә Клара Хәйретдинова белән бергә укып кайттык, бергә җырлап та йөрдек. Гомер эчендә бик күп илләрдә булырга туры килде. Гастрольләрдә йөргәндә дә бер төркем артистлар белән шаярып, көлеп барасың. Әйтәм бит, барысы белән дә дус булдым.

– Сез күп еллар Казан дәүләт мәдәният университетында студентларга белем бирдегез. Хәзер инде эшләмисез. Шулай да университет тормышы белән кызыксынасызмы? Эстрада яңалыкларыннан хәбәрдармы?

– Казан дәүләт мәдәният университетында егерме елдан артык студентлар укыттым. Әле тагын эшләргә була иде, узган ел үз теләгем белән киттем. Университет җитәкчелеге: «Теләсә кайчан кире кайтыгыз», – дип калды. Ләкин яшь бара, сәламәтлек тә икенче. Шуңа эшләп йөреп булмас инде. Әмма яшьләр арасында йөрү үзеңне тонуста тотарга ярдәм итә.

Ә яңалыкларга килгәндә, эстраданы күзәтеп барырга тырышам. Студентлар белән эшләгәндә дә, яшьләргә сәхнәдә нәрсә ярый, нәрсә ярамый икәнлеген төшендерергә тырыштым. Безнекеләр – Мәскәүдән, Мәскәү чит илдән үрнәк ала. Элек бездә чит ил музыкасы тыелган иде бит. Әмма аны барыбер төрле юллар белән, төнлә булса да радио аша тыңлыйлар иде. Аннан дөнья ачылып китте дә, җырчылар да, тамашачылар да нәрсәне сайларга, кулланырга, дип аптырап калды. Бүген инде халык бер нәрсәгә дә шаккатмый башлады.

– Римма апа, гаилә хәлегез турында да сөйләшсәк иде: илле яшь тә тулмаган килеш пар канатсыз калгансыз. Кызыгыз Ләйсән җиде яшьтән этисез үскән. Ирсез яшәү авыр булдымы?

– 22 яшьтә кияүгә чыктым. Равил белән бергә эшли идек бит. Фәритне берничә ел әти белән әни карады. Концертлардан аны сагынып, зарыгып кайта идек. Ул да безне бик сагына иде, балакай. Ана буларак йөрәкләрем өзелә иде. Соңыннан Равил филармониядә эшләде, ә мин үзем генә гастрольләрдә йөрдем. Шулай итеп, Фәрит этисе белән кала башлады. Равил бик ярдәмчел, терәк булды. Концертны оештыру мәсьәләләрен гел ул хәл итә иде. Беркайчан да артык усаллыгын күрсәтмәде. Арабызда көнләшү дә булмады, чөнки без гел бергә булдык: бергә уяндык, бергә ашадык, бергә эшләдек. Аның белән бергә яшәгән 25 ел миңа җитмәде.

Равилнең үлемен бик авыр кичердем. Яңадан тормышка кайтыр өчен әле ярый Ләйсәнне тапканмын, дип шатландым. Ләйсән белән дәрес хәзерләп, аны мәктәпкә илтеп, аннан алып кайтып, концертларда

җырлап, акча эшләп, көннәрнең ничек үтүен сизми дә кала идем. Уйланып утырып, моңаерга вакыт булмады. Ә Фәрит укый, эшли иде. Ул һәрвакыт мөстәкыйль булды.

– Балаларыгызны гел мактап телгә аласыз. Сез алар белән горурлансызмы?

– Әйе. Балалар кечкенәдән мөстәкыйль булдылар. Хәер, аларның башка мөмкинлеге дә булмаган инде, минем бит – өзлексез гастрольләр, эш. Алар белән чиләнмәдем, шөкер. Әтиләренең тәрбиясе дә кергәндер. Бик җайлы, безне борчымый торган балалар булдылар.

– Дәү әни буларак, оныкларга нинди тәрбия бирәсез? Гомумән, аларга вакыт каламы?

– Оныкларымны бик яратам. Фәритнең дүрт баласы, Ләйсәннең ике баласы бар. Җай булса, әлбәттә, күрешәбез. Фәритнең гаиләсенә кодалар бик булыша, рәхмәт аларга.

– Нинди уйлар белән йокыдан торасыз?

Яшәгән саен яшисе килә,
Балачакларга кайтасы килә...

(Римма апа бу юлларны җырлап бирде. – **Авт.**)

Һәр кешенең гаиләсе белән бергә, тату-лыкта гомер итәсе килә. Олыгая төшкәч, үзүзеңне тәрбияләп яшисе килә. Бу – табигый әйберләр. Балаларым исән-сау, дип сөенәм, яныма килеп йөриләр. Безгә тагын ни кирәк?

Балаларның гаилә тормышына кысылырга тырышмыйм. Әле менә күптән түгел генә Фәритләрнең өйләрендә кунак булып кайттым. Ул балалар ник бер рус сүзен кыстырып сөйләсеннәр. Әниләре Ландыш тырышлыгы бу, алар өчен бик сөенәм.

– Римма апа, сезгә киләсе елга 75 яшь тула. СөбханАллаһ, бик күркәм күренәсез. Нинди планнар белән янасыз? Яраткан тамашачыгыз алдында бирәр концерт куясы килү теләге юкмы?

– Бар. Алла боерса, киләсе елга юбилей елым. Балалар белән бергә тамашачым алдында бер концерт әзерлисе килә. Дөрес, әле ныклап бу эшкә алынган юк, ләкин, әйткәнемчә, күңелдә андый теләк, ният бар.

Вакыт бара, яшем әкренләп арта. Картаеп, авырып, балалар кулына калырга язмасын иде. Аллаһы Тәгаләдән шуны сорыйм. 70-80 яшьләрдә әллә нәрсәгә өметләнеп яшәп булмый. Оныкларны кияүгә биреп, туйларында биергә язсын дигән хыял бар, әлбәттә.

– Тамашачыларыгызга нәрсә теләр идегез?

– Бар кешегә дә бәхет телим! Дөньялар тынычлансын, җанда – тынычлык, тәндә сәламәтлек булсын!

Гаиләнең түгәрәк чагы.

«Яшәгән саен яшисе килә» – ди яраткан җырчыбыз.

ШАРДЖА – 2024:
БАРЫСЫ ДА КИТАПТАН БАШЛАНА...

Луиза Янсуар

6–17 ноябрьдә Шарджада 43 нче халыкара китап күргәзмә-ярминкәсе узды. Әлеге чарада быел 112 илдән 2 500 нәшрият, 450 дән артык автор һәм әдәбият белгече катнашты. Чараларның санына килсәк, 1 350 гә җитә иде. Максаты – әдәбиятка һәм уку культурасына, сторителлингка кызыксынуны арттыру.

АВАЗЛАР ПОЛИФОНИЯСЕ

Казандагы -5 тән соң, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендәге +35 градуска килеп төшү, әлбәттә, үзен сиздерде. Тел ягыннан да: тулаем диярлек инглиз, күпмедер дәрәҗәдә француз телендә сөйләшә торган дөньяга килеп эләгәсең. Ирексездән, үзеңдәге «яшерен кәрәзләрдә» йокымсырап яткан лингвистик хәтер катламнарын уятып, эшкә җигәргә керешәсең. Аэропортта инглиз теле белән бергә гарәп теленең төрле диалектлары кушылып яңгыраган аһәңгә, авазларның табигый күчештирбәлешенә колак салып, үзенә бертөрле, яңа музыка тыңлагандай хозурланасың.

Тагын бер иялэшергә кирәкле үзенчәлек – тирә-ягында иге-чиге юк, күккә терәлеп утырган берсеннән-берсе биек йортлар. Шарджада хәтта ташка (дөресрәге, рәсми кәгазьләргә) язылып куелган канун да бар: биредә биналар 60 каттан да тәбәнәгрәк булса, аларны төзергә рөхсәт бирелми. Чөнки гарәпләр чүл уртасында корып куйган бу оҗмахта җир бәясе бик кыйммәт – алтын дәрәҗәсендә йөри. «Әлбәттә, гарәп кешеләре үзләре монда яшәми, бу йортлар ни-

Фотолар Луиза Янсуар, Алексей Арзамазов, фестиваль архивыннан

гездә – килгән кешеләр өчен», – дип аңлата беленер-беленмәс таң сызылып килгәндә безне аэропорттан каршы алган таксист. Ә аннары дөньяны... гаҗәеп матур яңгырашлы иртәнге азан күмеп китә: әллә ничә яктан. Мин гаҗәпләнеп тирә-юнемә каранам. Асылда, сере бик гади – башыңны кайсы якка борып карама, мәчет урнашкан. «Кешеләр эшләреннән бүленеп, еракка йөрмәсен дип, шулай каралган. Намаз укыр өчен, шәһәрнең икенче почмагына йөрмәссең бит...» – ди безгә тагын таксистыбыз, бик гадәти нәрсәне аңлатып торырга кирәклегенә гаҗәпләнгәндәй.

Казаннан без тел галиме, лингвист, язучы Алексей Арзамазов белән бергә килдек. Аның Шарджага Халыкара китап ярминкәсенә икенче мәртәбә килүе, минем әле – беренче. Әмма һәр икебез өчен – хис-тойгылар җете, кабатланмас.

Быелгы Россия делегациясендә, гадәттәгечә, Мәскәү язучылары белән беррәттән, Россия халыкларының Милли әдәбиятларын саклау программасы вәкилләре, ягъни төрле республика, төбәкләрдән җыелган милли язучылар да бар. Татарстаннан мин һәм Удмуртия вәкиле Алексей Арзамасовтан тыш, Дагыстаннан табасаран шагыйрәсе Сувайнат Кюрбекова, лезгин шагыйре һәм журналисты Владик Батманов, карачай-балкар язучысы, «Карачай» газетасының баш мөхәррире Сәлимә Коркмазова, бурят язучысы, Мәскәүдәге М.Горький институтында бурят студентлар төркемен тәрҗемә буенча укытучы Амарсана Улзытуев, Башкортостаннан шагыйрә, «Ватандаш» газетасының әдәбият бүлеге мөхәррире, башкорт телендә чыккан «Әс-Сәлам» газетасы мөхәррире Зөлфия Ханнанова.

Кунакханәгә килеп урнашуга, әле номерларга кергәнче үк, тамак ялгап алырга чакыралар. Монда без гадәти, ияләшкән Европа кухнясы белән беррәттән, җирле кухняга юлыгабыз. Ризыкларның кабатланмас исләренә, тәменә күмелдебез. М-м-м-м-м... Юкка гына һәр мәдәниятнең нинди икәнен беләсең килсә, һичшиксез, аның ризыгын авыз итеп кара, дип әйтмәгәнннәр!

ЕВРОПА, АЗИЯ – БЕР НОКТАДА

Быелгы «Шарджа ЭКСПО 2024» үзенең бай, кызыклы программасы белән әле юлга кузгалганчы, кураторлар һәммәбезгә җибәреп куйган буклет аша ук ымсындырган иде. Аэропортта «Барысы да китаптан башлана» яки «Ноябрь китаптан башлана» дигән баннерларны, экрандагы реклама язуларын күреп, «карале, ничек рекламалыйлар!» дип тел шартлаттык. Аннары инде Шарджаны карап йөрергә чыккач, урамнарда да мондый баннерларга, китап белән бәйле инсталляцияләргә һәр адымда диярлек юлыктык. Тәүлек әйләнәсе берничә канал эшләп торган Шарджа белән Дубай телевидениесе дә бу вакыйганы өзлексез яктыртты. Безнең кунакханәгә ике адымда урнашкан ЭКСПОда тормыш 24 сәгать буе кайнап-гөрләп торды.

ШАРДЖА ХАЛЫКАРА КИТАП ЯРМИНКӘСЕНӘ 1982 ЕЛДА ШӘЕХ СОЛТАН БИН МӨХӘММӘД ӘЛ-КАСЫЙМИ ТАРАФЫННАН НИГЕЗ САЛЫНА. АНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ БИРЕДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘРНЕ, ТӨБӘКТӘГЕ ҮСЕП КИЛГӘН ЯШЬ БУЫННЫ КИТАП КУЛЬТУРАСЫНА ҖӘЛЕП ИТҮ, УКЫРГА ӨНДӘҮ БУЛА. ШУЛАЙ УК – ШАРДЖАНЫ ДӨНЬЯКҮЛӘМ БЕЛЕМ, МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ИҖАТ ҮЗӘГЕНӘ ӘЙЛӘНДЕРҮ.

Быелгы зур кунаклар арасында Букер премиясе лауреаты – Болгария язучысы Георгий Господинов, Болливуд актрисасы һәм автор Хума Курейши, чыгышы белән әфган-һинд булган Британия язучысы, журналисты һәм документалисты Таһир Шаһ, дөньякүләм билгеле физик һәм космолог Лоуренс М Краусс, күренекле тарихчы Питер Франкопан бар иде.

Мәртәбәле кунаклар рәтендә – Марокко корольлеге һәм аларның мәдәни, әдәби, заманча технологияләргә багышланган чаралар комплексы. Бу аңлашыла да, оештыручылар ЮНЕСКО карарын исәптә тоткан булса кирәк, чөнки 2026 елда Рабат Дөньякүләм китап башкаласы дип игълан ителде. Марокко мәдәнияте белән таныштырырга махсус программа эшләнгән. Монда кино күрсәтү дә, музыкаль концертлар да, театраль тамашалар да, балалар өчен интерактивлар да әзерләнгән. Шулай ук – кулинария буенча 20 дәрес! Әйе, әйе, нәкъ менә кулинария буенча! Вьетнам, Оман, Ирландия, Словения, Непал, Көньяк Африка Республикасы һ.б. илләрдән килгән 17 шеф-повар монда телне йотардай хикмәтле сый-нигъмәтләр «иҗат итте».

ЭЛЕККЕГЕ СССР СОСТАВЫНА КЕРГӘН ЯИСӘ БҮГЕН ДӘ РОССИЯ СУБЪЕКТЫ БУЛГАН РЕСПУБЛИКА-ТӨБӘКЛӘРДӘ УЗГАН ФЕСТИВАЛЬ-ЯРМИНКӘЛӘРДӘ ӘЛЕ БЕЗНЕҢ ТУКАЙ БЕЛӘН МУСА ҖӘЛИЛНЕ БУЛСА ДА ИШЕТЕП БЕЛӘЛӘР.

Әдәбиятка урын калганмы соң, диярсез. Әйе, әдәбиятны Марокко вәкилләреннән дистәләгән автор һәм сторителлинг остасы тәкъдим итте.

Инде әйткәнемчә, монда барысы да китап фестиваленә килергә кызыктырып, әйдәп тора.

БЫЕЛГЫ ТАГЫН БЕР ҮЗЕНЧӘЛЕК – ЯРМИНКӘ ТАРИХЫНДА БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ КРЕАТИВ ЯЗУ БУЕНЧА ОЕШТЫРЫЛГАН МАХСУС СЕМИНАРЛАР. БУ ТӘҖРИБӘ ХӘЗЕРГЕ КӨНДӘ РОССИЯДӘ ДӘ БИК ПОПУЛЯР. ПРАКТИКУМНАРДА ТӘРБИЯЛӘНЕП ЧЫККАН ТУЛЫ БЕР ДУЛКЫН АВТОРЛАР БАРЛЫККА КИЛДЕ, АЛАР КҮБРӘК АЕРЫМ БЕР ЖАНРГА БӘЙЛЕ ЮНӘЛЕШЛӘРДӘ АКТИВ ЭШЛИ: ТРИЛЛЕР, ФАНТАСТИКА, НОНФИКШН Һ.Б.

– Китап – бар нәрсәнең башында, ул кешелек туплаган кыйммәтләр һәм казанышлар сакчысы, – дип башлады сүзен Шарджа китап фестивале белән ярминкәсенең генераль директоры Әхмәд әл-Әмәри ачылыш тантанасында. – Мәгълүмат чиксез артып киткән заманда китапның шәхси белем туплау өчен дә, җәмгыятьнең тулаем прогрессы өчен дә төп чыганак булуын онытмаска кирәк.

КИЛӘЧӘККӘ СӘЯХӘТ

Классик форматтагы чаралардан тыш, быел Шарджада «Поэзия төне» дә планлаштырылган иде, ул гарәпчә, инглизчә, урду, пенджаби, малаялам һәм тагал телләрендә узды. Тере музыка белән кушылып-үрелеп киткән шигъри чыгышлар мәдәниятләр арасында булган чикләрне юкка чыгарды, Үткән белән Бүгенгене тоташтырды, безне Киләчәк дөньясына ендәште.

Креатив семинарлар нигездә тиз арада язу сәләтенә импульс бирергә, иҗади-техник нигезләрнең иң мөһимнәренә өйрәтергә тиеш, шулай ук авторларны сәләтен дөньяга күрсәтергә курыкмаска өндәргә дә. Киләчәк язучыларын тәрбияләү тулы бер нәшриятларның авторларга сусау ихтыяҗын тәэмин итү өчен дә кирәкле. Әйе, даһилар көн дә туып тормый, әмма әдәби процесс белән нәшриятлар эшчәнлеге – ул барыбер үзенә күрә конвейер. Һәм бу конвейерда һәркем үзенә кызыклы булган продуктны табып алырга тиеш.

«Шарджа ЭКСПО 2024» программасында каралган семинарлар нигездә инглиз, гарәп телләрендә алып барылды. Оештыручылар теркәлергә теләүчеләрне мавыктыргыч триллер язарга һәм терапия булырдай текстлар тудырырга өйрәнәчәксез, дип җәлеп итте. Семинар-практикумнарны уздырырга Мисыр язучысы Әхмәд Морад, Канада шагыйрәсе Рупи Каур, Америка детектив остасы Изабелла Мальдонадо чакырылган иде.

112 илдән килгән 2 500 нәшриятның барысын да карап-күреп бетерү гомумән мөмкин түгел, әмма без булдыра алган кадәр йөрдек, китаплар актардык, җыйдык, шәхси китапханәләребезне тагын да баеттык, бүләккә дә басмалар тупладык. Мин күп еллар буена яраткан шагыйрем Адонис китапларын эзләп мәш килдем, ахыр чиктә, Ливан нәшриятларының берсендә аның кош теле кадәр генә бер китабын табып алдым.

ШАРДЖА-ДУБАЙНЫ ЯҢГЫРАТЫП, ҮЗ ТЕЛЕБЕЗДӘ...

Көндезләрен бик эссе булганга, Шарджада халык маринага кичке 7–8 ләрдә агыла башлый: зур, затлы машиналарда килеп туктап, багажниктан ачып-ябыла торган җыелма өстәлләр, урындыклар чыгаралар, пледлар җәяләр дә яр буенда рәхәтләнеп сәйран кылып, чәйләп (бар тик чәйләп кенә, биредә беркем хәмер кулланмый!) утыралар, нарды уйныйлар, аралашалар, гәпләшәләр. Ап-аек әтиләр балалары белән шунда ук тезелешеп урнашкан спорт мәйданчыкларында, кортларда футбол, волейбол, теннис уйный, әниләр ап-ак җылы комда китап укып утыра.

Кичке тыгыз баллы-тозлы һаваны сулыйсулый, 24 сәгать буе бервөзлексез яшәгән шәһәрне аркылыга-буйга урый-урый, без таң калып йөрибез. Ә аннары төнката эшләп

торган һәм аутентик гарәп, һинд, кытай, азия халыклары ашлары тәкъдим иткән кафеларда тамак ялгап чыгабыз. Тагын йөрибез, сөйләшә-сөйләшә сүзебез бетми. Татар, башкорт, карачай, удмурт телләрен катнаштыра-укмаштыра шәрран ярып шигырь дә укыйбыз, истәлекләр дә бүлешәбез. Узган-барган безгә елмаеп-елмаеп карап китә, кафеларда «Сез каян?» дип сорап куялар. Без дәррәү Татарстанны, Дагыстанны, Удмуртияне, Карачай-Черкессияне атыйбыз. «Ә-ә-ә, сез ярминкәгә килгәнсез...» – дип суза кайберәүләр, елмаеп.

– Шарджа иң дини һәм кырыс, күбрәк гаиләле, эшлекеле кешеләргә яшәү өчен уңайлы әмирлек, – дип сөйли Дубайга юлда барганда озатып йөрүчебез Абдулла. – Дубай инде ул – ял, «тусовкалар», купшылык, зур акчалар әйләнгән һәм хөкем сөргән урын.

Һәр әмирлекнең үз кануннары, таләпләре бар, дип сөйли ул. Шарджада эчеп, дуамалланып, башбаштаклык кылып йөрү беркемнең дә башына килмәячәк. Әгәр андый халәттә тотылса, полиция кулына эләксә, 100 мәртәбә камчы белән суктырыла, әле өстәмә штрафлар да каралган икән.

– Бу закон Шарджада җирле халыкларга гына түгел, ә читтән килгән туристларга да кагыла, – дип өсти.

Тагын әле тикторганнан гына әмирнең резиденциясенә килеп, аңа аудиенциягә язылырга һәм... кабул ителергә була, дип шаккатырдылар.

– Ничек инде, аның өчен айлар буе көтәргә кирәкмимени?! – дип, ышанмыйбыз.

– Безнең әмирләр үзләренең абруена тап төшерергә кирәк дип тапмый, ул абруйны халкы каршында кадерләп саклый, – ди Абдулла, бик табигый нәрсә хакында сүз баргандай. – Җитмәсә, һәр кешене гозере, борчуы белән аның янына Аллаһы Тәгалә үзе җибәрә бит, ничек инде ул янына өмет баглап килгән Аллаһ бәндәсен кабул итмичә, кире борсын, ди?!..

ДӨНЬЯДА ЭЗЕБЕЗ... КАЙДА?

«Шарджа ЭКСПО 2024» атна буе балалар тавышыннан һәм агымыннан да өзелмәде. Монда бу мәсьәлә гаять җитди һәм хәтта катгый куелган: балаларны балалар бакчаларыннан да, мәктәпләрдән дә китерделәр. Төрле сыйныф укучыларын төркемләп-төркемләп алып килделәр һәм чаралар буйлап тараттылар.

Алар чыгышлар да тыңлады, интерактивлар белән дискуссияләрдә дә катнашты, уеннар да уйнады, интеллектуаль бәйгеләрдә дә көч сынашты. Гаҗәеп ыспай-пөхтә киенгән гарәп укытучылары, нигездә ир-атлар, сыйныфларны шулкадәр тәртипле итеп, бер йодрыкка җыеп йөртә ки, син эчеңнән генә уйлап куясың: «Мондый дисциплинага ирешер өчен нишләргә кирәк икән?!»

ҮЗ ТЕЛЕҢНЕҢ ТӘМЕ-КҮРКЕ, БӨТЕН АҺӘҢНӘРЕ ЧИТТӘ ТАГЫН ДА НЫГРАК АЧЫЛА, КАДЕРЕ АРТА ТӨШӘ. БИГРӘК ТӘ ТУГАНДАШ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР БЕЛӘН ЙӨРЕП, ҮЗАРА ФИКЕР СӨРЕШЛӘРЕ КИСЕШКӘНДӘ.

Без дә үзебезнең милли әдәбиятлар буенча чыгышлар, презентацияләр хәстәрләп килгән идек. Дөньякүләм аренага чыкканда, син үз өстеңә икеләтә, бишләтә, юк, хәтта унлата җаваплылык аласың: туган илеңнең, ватаныңның бөтен сиңа кадәр булган әдәби мирасын тәкъдим итәсең бит! Бирегә дә «дөнья белергә тиешле татар язучылары» дигән топ-исемлек төзегән идем – Кол Галидән алып бүгенге әдипләргә кадәр...

Әйтик, Дагыстанда без хәтта 60 нчы елларда Әдәбият көннәрендә, Бөтенсоюз форум-семинарларында катнашкан, күпсанлы очрашуларга йөргән кайбер язучы-шагыйрьләрне дә искә алып сөйләштек. Ә менә дөнья мәйданына чыкканда, «бу – безнең татар язучысы!» дип, авыз тутырып сөйләгәндә, «әйе, без аны беләбез бит» дисеннәр өчен, әле җиң сызганып тырышасы да, тырышасы... Югыйсә, дөнья күләмендә яңгырап торырдай классик әдипләребез дә, шагыйрьләребез дә бар лабаса. Яңа буын тәрҗемәчеләрен дә үстерү бик зарур!

Замана язучыларыннан да танытырлыклары, милли йөзебезне һәм әдәби табышларыбызны күрсәтердәйләре бар: алар төрле телләргә тәрҗемә итүне, пропагандалауны сорый. Бу җәһәттән Милли әдәбиятларны саклау программасына һәм аның кысаларында басылып чыккан антологияләргә рәхмәт әйтми мөмкин түгел, алар аша әдәбиятның кечкенә генә бөртекләре булса да дөньякүләм күренә, яңгырый, ишетелә...

...ә тагын күпме әле аның ишетелми калганнары.

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –

«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

WWW.PROTATARSTAN.RU

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Шаһинә таҗына **ничек** ия булырга

Мөхәммәтхан Фазлуллин **нинди** мирас калдырган

Халыкара китап ярминкәсе **кайда** узды

Яңа Бүләк авылы **ничек** яши

Фотолар Альбина Каменецкая архивыннан

АЛЬБИНА КАМЕНЕЦКАЯНЫҢ ДҮРТ ТАҖЫ

Дмитрий Сивков

Казан гүзәленең матурлык бәйгесендәге дебюты көтелгәннән дә уңышлырак килеп чыкты – бер ел эчендә өч титул. Әмма гүзәл якташыбызның төп призы – шаһинә таҗлары гына түгел ул, ә Россия хатын-кызлары өчен каралган үзенең кабатланмас декоратив косметика линиясе дә.

Матурлык алиһәсе белән очрашуны, әлбәттә инде, 60 нчы еллар шлягеры ритмнарында күзаллыйсың: «По переулкам бродит лето / Солнце льётся прямо с крыш / В потоке солнечного света / У киоска ты стоишь / А я иду к тебе навстречу / И я несу тебе цветы / Как единственной на свете / Королеве красоты!»

Альбина Каменецкая очрагында 60 нчы еллар схемасы бер дә барып чыкмый әле: җәй дә түгел, кояш та юк, чәчәкләр дә хәтта... Әмма матурлык алиһәсе декабрьнең беренче карына басып барыбер каршыма атлап килә – кышның үзеннән дә күркәмрәк ул... Өстендә – ак тун, ак башлык... ә менә таҗы юк...

Аннары, аралаша башлагач, шунысы аңлашыла: Альбина белән нindидер кысаларга сыешу гомумән мөмкин түгел икән. Әле узган елның азагында гына ул берниндидә Матурлык шаһинәсе таҗлары турында башына да кертеп карамаган, ә хәзер инде алар – төп-төгәл дүртәү. Менә шундый ул – чынга ашкан әкият!

«СИН НИК... СӘХНӘДӘ ТҮГЕЛ?!»

Барысы да 23 гыйнварда башлана. Ул көнне «Мисс Татарстан» матурлык бәйгесе финалы уза.

– Очраклы гына чакыру билеты эләкте. Мине бу бәйге тәмам рухландырды, илһамландырды – тантаналы шоу белән дә, катнашучы гүзәлләр белән дә... – дип искә ала Альбина. – Залда йөргәндә, элеккеге коллегамны очраттым. Ул мине күрәкүрешкә: «Сәлам! Син ник сәхнәдә түгел? Сиңа һичшиксез мондый бәйгеләрдә катнашырга кирәк!» – дип, куәтләп җибәрде.

Альбина аның сүзләрен уенга борырга, шаяртып кына узарга тырышкан. Әмма танышы бер дә шаяртмый булып чыккан, ул аңа «Миссис Татарстан» бәйгесе турында бәйнә-бәйнә сөйләп тә биргән. Мәгълүмат Альбинага кызыклы тоелган, ә инде бер айдан соң аны иртәнге бизнес-аш вакытында язмыш Best Lady матурлык бәйгесе оештыручысы белән очраштырган. Һәм ул оештыручы Альбинага бәйге программасында катнашып карарга тәкъдим ясаган. Күрәсең, алдан карап эш йөрткән, ялгышмаган – Альбина Каменецкая беренче катнашуында ук Гран-при иясе булып куя.

Май аендагы җиңүдән соң, июльдә инде Альбина бишенче тапкыр уздырылган «Миссис Татарстан – 2024» матурлык һәм уңыш бәйгесенең республика этабына чыга. Йомгаклау этабында Казан, Чистай, Түбән Кама, Саба районнарыннан 10 конкурсантка катнаша. Монда да безнең героиняга уңыш елмая: ул «Миссис Фото Татарстан – 2024» төп титулларының берсенә ия була, шулай ук «Миссис Россия International» бәйгесе финалына чакыру да ала.

Альбина ачыктан-ачык әйтә: сертификатка озак карап тордым, барыргамы-бармаскамы, дип баш ваттым, ди. Әмма туганнары белән якыннарының хуплавы, үсендерүе үзенекен итә. Вакыйга Ростов-на-Дону шәһәрендә октябрьдә уза, монда да Казан кызының башына «Гранд Миссис Россия International – 2024» таҗын кидерәләр. Шуңа өстәп, ул әле тагын ике титулга лаек дип табыла – «Интернет-танылу» һәм «Тамашачы тануы». Бу – профессиональ жюри белән сайтта, тамаша залында тавыш биргән гади тамашачыларның фикерләре тәңгәл килгән, кисешкән сирәк очракларның берсе.

ГӨБӘДИЯНЕҢ 99,9 ПРОЦЕНТЛЫ УҢЫШЫ

– Сезнең «Миссис Россия International – 2024» бәйгесендә катнашуыгыз чын мәгънәсендә триумфаль булды. Шундый нәтиҗәгә ирешергә нәрсә булышты, дип уйлыйсыз?

– Мөгаен, ихласлыгым, кайсыдыр өлкәдә кабатланмас булуым... Һәм, әлбәттә инде, кулинар бәйге белән костюм бәйгесендә уңышлы чыгыш ясавым. Ахыр чиктә, алар барысы бергә миңа таҗ алырга ярдәм итте.

Без, хатын-кызлар, күпкырлы, төрле яклы һәм ни белән булса да кабатланмас булырга тиеш. Билгеле, бу җиңел генә бирелми, чөнки бриллиантның да һәр кыры үзенә бертөрле балкый. Димәк, аның кырлары балкып китсен өчен, бик нык тырышырга кирәк, ул бит үзеннән-үзе генә балкымаячак.

– Жюри һушсыз калсын өчен, нинди ризык әзерләдегез?

– Бу бер дә җиңелләрдән булмады, чөнки без әзерләгән ризыкларны профессиональ шеф-повар бәяләде. Мин әбием Римма рецепты буенча гөбәдия пешердем. Ул бит - бик тәмле дә, бәйрәмчә дә сый. Тәме белән генә сокландырып калмыйча, татар бәйрәменең атмосферасын да җиткерәсе килде. Шеф-повар пирогны авыз итеп карагач: «Гөбәдиянең уңышы 99,9%», – диде. Шулчакта мин: «Рәхмәт сиңа, әбием!» – дип сөендем. Бәйгедә гөбәдиянең беренче урынга чыгуы зур куаныч та, уңышымның нигезе дә булды.

ЯУГИР ХАТЫН-КЫЗ – КАРАКҮЗ

– Ә костюм нәрсә белән уникаль иде?

– Милли булуы белән, монысы инде аңлашыла. Гадәттә, Татарстан гүзәлләре Сөембикә образын сайлый, әмма мин бу кысалардан да чыгарга кирәк таптым. Яугир хатын-кыз – Каракүз костюмына тукталдым. Борынгы Болгарны басып

алучылардан саклап, ул ир-егетләр белән бергә көрәшкән. Янган уттан да исән-имин чыккан, шуның белән дошманнарны таң калдырган. Каракүз образы – туган якка мәхәббәт символы ул, үзеңне аңа багышлау үрнәге. Татарстан туташлары белән ханымнарына бу сыйфат хас, дип уйлыйм.

МИНЕМ ШӘХСИ МАТУРЛЫК ДӨНЬЯМ

– Моңа кадәр матурлык бәйгеләрендә катнашмасагыз да, сезне бит бу өлкәдә бөтенләй яңа кеше дип тә әйтеп булмый.

– Әйе, матурлык дөньясын мин һәрчак ярата идем. Хатын-кызларны кабатланмас итү, аларның гүзәллегенә басым ясау – бу минем миссиям, дип уйлыйм.

Туган шәһәремдә тегү фабрикасында узган мода кичәләрендә чыгыш ясаганым булды. Икътисад, идарә итү һәм хокук институтында укыганда, «Глория» театрына нигез салдым. Ул чакта без беренче мәртәбә «Студентлар язы» конкурсында катнаштык. Анда тәүге коллекциямне күрсәттем, идея авторы буларак чыгыш ясадым.

Ул театр хәзер дә бар, әмма инде башка исем белән атала. Һөнәрем буенча мин – финанс аналитигы, ике матурлык салоны белән идарә иттем. Әйткәнемчә, хатын-кызларга матурлык бүләк итүне миссиям дип исәплим. Хәзер менә – шәхси үрнәгем аша да.

УЛЛАРЫМ – ОЛЫ ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

– Үрнәк, дигәннән. Күп кенә замана хатын-кызлары беренче урынга карьераны куя. Менә, шушыларга-шушыларга ирешәм дә, аннары гаилә турында да уйларга мөмкин, дип фикер йөртә. Ә менә сезнең гаилә үрнәге – ир хатыны да, ике улның әнисе дә булуыгыз – эшлекле хатын-кызларга бернинди киртәләр дә юклыгын раслый шикелле?

– Яшь кызларга шуны гына әйтә алам: гаилә корырга курыкмасыннар. Син бер генә нәрсәгә ставка ясаганда, кайсын да булса югалтырга мөмкинсең. Иң төп кагыйдә – вакытың белән идарә итә белергә өйрәнү. Ә гаилә төзергә кирәк! Гаилә ул – тормыштагы иң зур терәк! Улларым – олы илһам чыганагы. Алар талантлы, иҗади балалар. Өлкәне – Артур – музыка мәктәбендә шөгыльләнә, ул күпсанлы республика һәм бөтенроссия бәйгеләре лауреаты. Өстәмә рәвештә электрогитарада уйный: Scopionsны да, Стингны да. Инде үзе дә матур гына көйләр иҗат итә. Музыкада кызыксынулары гаять киң колачлы – роктан алып джазга кадәр. Хәзер менә моделинг белән дә мавыга башлады, мин моңа шулай ук куанам һәм улым белән горурланам. Аның төс-кыяфәте, коммерция күзлегеннән караганда, чын мәгънәсендә уңышлы, ул үзен күрсәтә, тәкъдим итә дә белә.

Бәләкәй улым – Арон – бик ачык бала. Аның исеме юкка гына «яктылык тавы» дигән мәгънә белдерми. Аналитик фикер йөртә, кечкенә вакытында без аның белән йоклар алдыннан еш кына әкиятләр укымый, ә... саный идек. Мин аңа ниндидер мәсьәләләр бирәм, ә ул баштан гына исәпләп, санап чыгара. Дүрт яшендә бергә кибеттә йөргәндә, ул әле сатып алган әйберләрнең касса бәяләрен дә санап бирә иде. Миңа бу бик гаҗәп, әлбәттә! Арон телләр белән мавыга, инглизчә өйрәнә, бу елдан татарчаны да үзләштерә башлады. Аңардан яхшы бизнес-аналитик, идарәче чыгар, дип уйлыйм.

Мин балалардагы талантны күреп алырга, аларның кабатланмас якларын ачарга, ә аннан инде үстерергә кирәк, дип саныйм. Шуңа аларга бу юнәлештә ярдәм итәргә омтылам.

ЯШҮСМЕРЛӘРГӘ КҮПЕР

– Әмма бит сез әле башка балаларга да ярдәм итәсез.

– Сез авыр хәлдә калган яшүсмерләр турында әйтәсезме? Беләсезме, алар белән эшләргә бик яратам. Бигрәк тә – әти-әниләре булмаган балалар белән, бу 13–14 яшьләрдәге кызлар. Нәкъ шушы яшьтә кызларның гормоннар фоны үзгәрә, аларның дөньяны кабул итүе, үзаңы формалаша. Мин аларга бу чорда үзләрен яратырга, кызлар булып өлгерү этабына җай гына, матур итеп күчәргә булышам. Гадәттә, теманы, кирәкле материалларны сайлыйм: рәсемнәр ясыйбыз, төрле нәрсәләр турында сөйләшәбез, косметичканы барлыйбыз, алар табигый матурлыгын сакласын өчен, ничек дөрес итеп юынырга, үзеңне тәрбияләргә кирәклеген өйрәнәбез.

Бу да – үзенә күрә бер миссиядер, мөгаен. Мин нәрсә генә эшләсәм дә, йөрәгемне тыңлыйм. Бу кызлар янында да бик илһамланып, рухланып кайтам, чөнки алар өчен әһәмиятле эш эшләвемне, чынлап та булыша алуымны тоям. Шуны да әйтим инде: матурлык дөньясына юлым визаж белән мавыгудан башланып китте. Әле балачакта ук...

ТОРМЫШЫМНЫ ҮЗГӘРТКӘН МӘКАЛӘ

– Моңа ни дә булса этәргеч булдымы?

– Әйе. Безнең гаилә кечкенә генә бер шәһәрдә яши иде, этием телемастер

булып эшли. Шулай беркөнне мин укудан соң аның янына кердем, кулыма бер журнал килеп эләкте, анда «Зур күзләр эффекты» дип аталган бер мәкаләне күрдем.

Мин аны шунда ук йотлыгып укып чыктым. Алай гына да түгел, тулаем дәфтәремә күчереп яздым, шулкадәр гаҗәпләндерде ул мине. Әлегә кадәр авторның күз кабагына перламутрны ничек ягарга кирәк булуын, күләгәләрне орбиталь катламга салырга кирәклеген аңлатуы хәтеремдә тора. Мин боларны күз алдыма китерә-китерә укыган идем. Ул мәкалә минем авторлык макияжын тудыруыма илһамчы һәм этәргеч булды.

Сүз уңаеннан, күптән түгел генә мин «Мисс Татарстан» бәйгесе дирекциясеннән моделинг белән шөгыльләнүче кызларга визаж курслары өйрәтергә чакыру алдым.

– Сезнең бөтен эшкә дә җитди якын килүегезне күреп, әле тагын кайсы да булса өлкәдә үзегезне табарсыз, дип ышанырга буламы?

– Сез хаклы, мин процесска кереп китеп эшләргә яратам. Балачактан ук косметика өлкәсендә ни дә булса иҗат итеп, эшләп карарга омтылдым: төсле карандашларның грифелен юкартып, башкача кулланып карыйм, текстураны ваклыйм, аннары нинди дә булса катнашмалар йә су белән кушам, куертам, сыеклыйм... Хәзер инде бу Россия хатын-кызларына туры килә торган уникаль косметика линиясе булдыру юнәлешенә эверелде. Россия хатын-кызларына бу бик әһәмиятле, чөнки безнең урта полоса бик үзенчәлекле, бездә кояш – аз, ә салкын – күп.

Төсләр тибы буенча да безнең хатын-кызларның үз үзенчәлекләре бар, мондагы туташ һәм ханымнар Европаныкына караганда «сорырак». Шулай ук безнең тән тиресе дә аерым дымландыру һәм тукландыруны таләп итә.

БӘХЕТЛЕ ҖИДЕ САНЫ АСТЫНДА

– Бу проектыгыз нинди стадиядә хәзер?

– Инде төгәлләнеп килә. Барлык серләрне дә ачып бетермим, әмма шуны әйтәм: тиздән җитди бер Европа бренды белән килешү төзергә торабыз.

– Уңыш теләргә генә кала, димәк! Мин әле сезгә бәхетле саннар да ярдәм итә, дип ишетеп беләм...

– Җиде санын әйтәсездер... Бар андый хикмәт. Үзегез уйлап карагыз: «Миссис Россия International – 2024» 7 октябрьдә башланды, Ростов-на-Дону шәһәренә мин җиденче вагонда бардым, кунакханәдә җиденче катта яшәдем, җиденче номер белән чыгыш ясадым. Җиде санын бит гел тылсым һәм яхшы үзгәрешләр белән бәйлиләр, әйтик, «бәхетнең җиденче катында» дию генә ни тора...

Әле шушы көннәрдә генә үземне бер премиягә тәкъдим иткәннәрен белдем. «Матурлык – чикләрсез» дип атала ул, анда һәртөрле матурлык бәйгеләре җиңүчеләре һәм лауреатлары тәкъдим ителә. Менә әйтегез әле, җиңүчеләрне кайсы числода игълан итәләр, дип уйлыйсыз?

– Җидесемени?!

– Әйе! Һәм бу инде, бирсен Ходай, минем дүртенче таҗым булачак.

– Моңа инде бернинди шикшөбһә дә юк! Ә мин, сөйләшеүбезне төгәлләр алдыннан, бер үтенеч белән мөрәҗәгать итәм: безнең журналны укый торган гүзәл туташ вә ханымнарга да матурлык серләрен ачыгыз әле.

– Иң беренче чиратта, үзең булып калырга кирәк, дип уйлыйм. Үз принципларыңа хыянәт итмәскә, уйларың белән максатларыңда ихлас булырга. Матурлык ул һәрчак тышкы яктан гына күренмәскә дә мөмкин, кайчак ул – эчтә, тирәндә. Бары тик тышкы матурлык белән эчке матурлыкның тигез, дөрес тәңгәллеге генә тиешле эффект бирә ала.

Серләргә килгәндә... Әйе, әлбәттә бар кечкенә генә серләр. Мәсәлән, мин битемә һәм тәнемә һәрчак массаж ясатам, битемә контраст душ ясарга тырышам, үземә ярашлы косметика кулланам (ул минем битемне һәм тәнемне бозмый), тагын әле йокы да организмга кирәкле дәрәҗәдә булырга тиеш...

Еллар оештырырга кирәк, аратирә вакытны үзеңә генә багышларга, кибетләрдә йөрергә... Бу кәефне күтәрә, тиешле гармониягә китерә. Хатын-кыз үзен яратырга тиеш, чөнки ул янәшәсендәге ир-ат өчен дә, җәмгыять өчен дә – илһам чыганагы.

МӨХӘММӘТХАН ФАЗЛУЛЛИН: ТЕЛ ЯЗМЫШЫ САГЫНДА



Айдар Шәйхин

Татар фәне һәм мәгарифе тарихында тирән эз калдырган Мөхәммәтхан Фазлуллинның фәнни мирасы хакында һичшиксез кыза-кыза бәхәсләшергә була. Мөгаен, гомерлек хезмәтенең әһәмиятен дискуссияләр ассызыклый гына төшәдер.

МӘХДҮМНЕҢ АЛЕКСАНДР II СТИПЕНДИЯСЕН АЛУЫ

Мөхәммәтхан Әшрәфҗан улы хәзерге Яшел Үзән районының Әрә авылында 1883 елның 2 декабрендә туа. Әрә авылы – бу төбәктәге борынгы татар авылларының берсе. Аның халкы – дәүләт крестьяннары катлавына кергән татарлар. Авылда ике мәхәллә була, XX гасыр башында ирләр һәм кызлар өчен мәдрәсәләр дә эшли.

Икенче мәхәллә мәчетенең имам-хатыйбы Әшрәфҗан хәзрәт Фазлулла гаиләсендә булачак татар филологы һәм педагогы туа да инде. Башта ул, әлбәттә, туган авылындагы мәдрәсәдә укый, әмма 12 яше тулар-тулмас ук әтисе аны Казанның Апанай мәчете янындагы Күл буе мәдрәсәсенә укырга илтә. Бу урында шунысын да искәртик: Мөхәммәтхан шәкерт булган дәвердә «Касыймия» (Күл буе мәдрәсәсенең икенче атамасы) иң абруйлы мәдрәсә булудан туктамый. Әйе, җәдит ысулы белән укыткан «Мөхәммәдия»нең йолдызы гыйлем күгендә якты яна, әмма Күл буеның популярлыгы бу елларда әле бер дә төшми: мәдрәсәдә төрле елларда Мөхетдин Корбангалиев, Нургали Надиев, Гаяз Исхакый, Муса Бигиев, Галиәсгар Камал, Камил Мотыйгый кебек могътәбәр шәхесләр укый.

Атаклы мәдрәсәнең шактый нигезле программасын үзләштерүдән тыш, Мөхәммәтхан рус сыйныфына да йөри. 1903 елда – мәдрәсәне, 1904 елда рус сыйныфын тәмамлый. Нәтиҗәдә, мәдрәсә һәм рус классында алган белеменә таянып, ул Казан татар укытучылар мәктәбенә керә. Бирерә 1908 елның 26 маена кадәр укый һәм шактый уңышларга ирешә. Мәсәлән, аның Александр II хөрмәтенә оештырылган стипендиягә лаек дип табылуы хакында мәгълүмат бар. Мондый төр бүләкләү чаралары, әлбәттә, укуда аеруча сәләтле булган студентларга гына каралган. Фазлуллинның укытучылар мәктәбен иң югары билгеләргә генә тәмамлавын әйтсәсе дә юктыр: аттестатында барлык фәннәр янында да «отлично» тора.

«Касыймия»не тәмамлагач, Мөхәммәтханның укытучылык стажы башлана: 1903 елда үзен тәрбияләп чыгарган мәдрәсәдә эшләп ала. Алга таба аның педагогик карьерасы укытучылар мәктәбендә белем алу белән бергә барган, күрәсең: ул Мамадыш өязенең Тарлау авылында (хәзерге Кукмара районы) рус-татар мәктәбендә укытучылык итә, ә 1911 елдан Мамадышның үзендә рус-татар мәктәбендә эшли.

Инкыйлабны да ул Мамадыш ягында каршы ала. 1917 елда ул Мамадыш өязенең мөселман мәктәпләре инспекторы итеп билгеләнә. 1918 елда исә Мамадышта татар укытучылар семинариясен оештыра һәм аның беренче мөдире булып эшли. Ә инде 1919 елда Казан губернасының халык мәгарифе идарәсе аны үзенә чакырта.

Фотолар автордан, ачык чыганаклардан алынды.

ЯҢА ТОРМЫШНЫҢ ЯҢА ПЕДАГОГИКАСЫ

1919 елда Казанда өч елга исәпләнгән педагогик курслар ачыла. 1921 елдан бу курслар нигезендә Казан педагогика техникумы оеша.

Илдә Гражданнар сугышы тәмамланып килгән дәвердә Фазлуллин яңа җәмгыятьнең яңа максатларга бай мәгариф системасын коруда катнаша. Ул чын-чынлап укытучылар укытучысына һәм халыкны агартучыга әверелә. 1923 елның көзеннән Казан дәүләт университетының эшче факультетында хезмәт куя, 1929 елның февраленнән Татар коммунистик университетында эшли. Бу уку йортларында ул татар теле һәм әдәбияты укыта. Шул ук 1929 елны Көнчыгыш педагогика институтына (соңрак Казан педагогика институты итеп үзгәртелә) татар телен укытырга чакырыла.

Пединститутта Фазлуллин аеруча зур уңышларга ирешә. Тиз арада аны институтның профессоры итеп сайлыйлар. Ә бер елдан соң ул татар теле кафедрасын оештыра һәм аның беренче мөдире була. Кафедраның коллективын туплау, татар тел белеме буенча курсларның күләмен һәм эчтәлеген билгеләү, программалар төзү – боларның барысын да ул елларда Мөхәммәтхан ага башкарып чыга.

20 ел дәвамында ул Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасын җитәкли. 40лап аспирант, бихисап дәреслекләр һәм фәнни эзләнүләр, мәкаләләр, методик эшкәртмәләр – аның фәнни-гыйльми мирасының саллы өлеше шуннан гыйбарәт.

ТАТАР МӘГАРИФЕНЕҢ БЕР ТЕОРЕТИГЫ

Латинлаштыру эше башланган елларда Фазлуллин татар теленең имлясын алыштыру идеясен халыкка таратырга тиешле «Яңалиф» җәмгыятенең әгъзасы һәм фәнни-методик советы сәркатибе булып хезмәт итә. Яңалифчеләрнең беренче конференциясен оештыруда катнаша.

Бу елларда тел белгече һәм мәгариф теоретигы татар телен гамәлгә ашыру комиссиясендә әгъзалык итә, төрледән-төрле советлар, комиссияләр, берлекләр, комитетларда да эшли. 1940 нчы елларда сүзлекләр комиссиясен җитәкли башлый, шулай итеп, тәрҗемә һәм терминнар сүзлекләрен төзүне яңадан җайга салуны оештыра.

20 нче еллардан башлап Мөхәммәтхан ага мәктәпләр һәм вузлар өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен, программаларын һәм методик кулланмаларын эзерләүне оештырып йөри. Бу чорда дөнья күргән дәреслекләрнең шактые аның авторлыгында яки аның методик җитәкчелегендә башкарылган.

Фазлуллинның укытучылар өчен язылган дәреслек һәм кулланмаларында мөһим бер принцип ассызыклана: укыту методикасы психология һәм педагогика мәсләкләре белән тыгыз бәйләнештә булырга тиеш. Элементар фикерме? Бүген бик гади яңгырый, ә үз вакытында дәреслекләрдә һәм укыту системасында психология нигезләрен белмичә белем бирергә тырышу очраклары бик еш күзәтелгән. Мөхәммәтхан ага ата-аналарны да балалары белән ачыктан-ачык сөйләшергә, укучыларны исә үз фикерләрен җиткерергә өйрәтергә чакыра.

Инкыйлабка кадәр, 1908 елда ук, аның «Дидактика кагыйдәләре» исемле әсбабы языла башлый. Гаять файдалы бу хезмәтнең бер өлеше «Йолдыз» газетасында дөнья күрә, әмма тулысы белән китап 1922 елда гына басыла. Биредә ул укытучыларга кирәкле киңәшләрне туплый, укыту һәм тәрбия бирүнең ничек оештырылырга тиешлеген аңлата. Укытуның эчке һәм тышкы яклары, укытучыларга, укытыласы фәннәрнең эчтәлегенә карата таләпләр һәм укучыларның үзләреннән соралган сыйфатлар – болар барысы да бу кечкенә генә җыентыкка сыйган.

1954 елда Фазлуллинның «Татар теле методикасы» дигән дәреслеге басыла. Китап вузларның татар бүлекләрендә укучы студентлар өчен төп дәреслекләрнең берсенә әверелә. Соңрак үзенең гыйльми варислары тулыландырган версиядә бу дәреслек берничә буын татар укытучыларын тәрбияләүдә «катнаша».



1 Мөхәммәтхан Фазлуллин – мәдрәсә шәкерте.

2

Грамота мәктәпләре өчен эшләнгән «Әлифба» тышлыгы.

3

Мөхәммәтхан Фазлуллин Укытучылар мәктәбендә укыган чорда.

ОРФОГРАФИЯ. ФАЗЛУЛЛИН БЕЛӘН КИЛЕШӘБЕЗМЕ?

1938 елның 23 августында «Кызыл Татарстан» газетасында Фазлуллинның «Яңа алфавит турында» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Бу мәкаләдән татар язуын кириллицага күчерү процессы башлана, дип әйтергә була. Фазлуллин татарлар өчен кирилл алфавитының беренче проектын тәкъдим итә. Ул татар теленә хас авазлар өчен бернинди дә өстәмә хәрефләр алмаска чакыра. Сәбәпләрен исә болай дип аңлата: «Яңадан хәреф өстәү ул хәзерге русча хәрефләргә нигезләнгән язу машиналары системасын боза, татарча язу өчен яңа система машина хәзерләргә куша; икенчедән, типографиядә дә яңа хәрефләр коярга, набор кассаларына ящиклар өстәргә мәҗбүр итә; өченчедән, татарча язу белән русча язу арасында аерма калдыра, бер үк сүзләрне ике төрле язып йөрергә юл калдыра».

Бу чорда Мөхәммәтхан ага фикеренчә, татар теле әкренләп гадиләшә барырга, аның кайбер авазлары бөтенләй төшеп калырга тиеш була: къ, гъ авазлары белән сөйләү киләчәктә бөтенләй бетә, җ белән һ дә перспективасыз дип табыла, чөнки җ авазын й кысрыклый, ә һ, гомумән, татарның чын авазы түгел. Бу урында шунысына игътибар итегез: ни кызганыч, ләкин Фазлуллинның бу фаразы әкренләп чынга аша бара, чөнки һ авазы да, къ белән гъ авазлары да телебездә специфик яңгырашларын югалта тора. Һава дип түгел, «хава» дип язучы да, әйтүче кешеләр дә күпме бүген!

Кызганыч, татар телен кириллицага күчерү эшендә актив катнашкан Мөхәммәтхан Фазлуллин язу алыштыру фаҗигасен прогресс билгесе дип санаган. Аның тәкъдимнәре нигезендә 1938 елның ахырында «Татар адьяби теленень алфавиты хъям орфографиясе» исемле брошюра да басылып чыга. Татар җәмәгатьчелеге тәнкыйтьләгән бу алфавит проекты XIX гасыр ахырында керәшеннәргә Николай Ильминский төзегән язуны хәтерләткән.

Мәгълүм ки, 1939 елның 5 маенда Мөхәммәт Корбангалиев һәм Шиһап Рамазанов тәкъдим иткән орфография проектлары нигезендә татар әдәби теленең яңа язу кагыйдәләре раслана. Бу язу тәртипләре 85 ел буена әкренләп камилләшә барды. Без бүген буйсынган кагыйдәләрнең хәзерге формага килүенә Фазлуллинның да өлеше кергән. Мәсәлән, е, ю, я хәрефләре булган иҗекләр нечкә әйтелешле булган очракларда азактан нечкәлек билгесе куюны ул тәкъдим итә. Шуңа күрә без юнь-юньле, ямь-ямьле дип язабыз. Башка төрле мисаллар да җитәрлек.

1950 нче елларда, Шәйхи Маннурның матбугатта күтәргән сорауларыннан соң, орфографияне камилләштерү мәсьәләсе тагын кискенләшә. Ул елларда барган дискуссияләрдә Мөхәммәтхан ага һаман үз принципларында тора. Күпләр къ һәм гъ өчен аерым хәрефләр таләп иткәндә, ул барыбер «бу авазлар – искелек калдыгы. Без аларны шуңа күрә алфавиттан алып ташладык. Гырлап торулар бездә бетә бара, аны бетерергә кирәк», – ди. Алай гына да түгел, Фазлуллин татар исем-фамилияләрен язганда да татар фонемаларын куллануны чикләргә чакыра. Мәсәлән, «Җәүһәрова» дип язасы урында «Жаухарова» дип кенә язарга куша ул. Әйе, паспорт бирүчеләр өчен бу принцип бик уңайлы булыр иде, мөгаен. Әмма телнең үзен саклый алуы өчен нинди куркыныч!

МӨХӘММӘТХАН ФАЗЛУЛЛИН ТАТАР ТЕЛЕН БЕЛЕП ҺӘМ СӨЕП КЕНӘ КАЛМАГАН. УЛ ТЕЛНЕҢ БҮГЕНГЕ ҺӘМ КИЛӘЧӘКТӘГЕ ХАЛӘТЕ, ТЕЛНЕҢ ЛОГИКАСЫ, АНЫҢ СТРУКТУР ЯКТАН ТӨЗЕКЛЕГЕ ТУРЫНДА ДА БОРЧЫЛГАН.

ХӘТЕР

1934 ел. Казанның Зур Кызыл урамы сквер белән кисешкән урында торак-төзелеш кооперативы тарафыннан кызыл кирпечтән күтәрелгән беренче йорт әзер була. Үзенә аерым фатир сатып алырдай кешеләр бу дәвердә бик аз булганга, яхшы йорттагы фатирларны башлыча мәдәният һәм фән әһелләренә, артистлар һәм профессорларга бирәләр. Болар арасында Мөхәммәтхан ага да була. Бу йортта ул соңгы көннәренә кадәр яши. Хәзер бу бина, конструктивизм архитектурасы һәйкәле буларак кадерле булса да, беренче чиратта, нәкъ менә Мөхәммәтхан Фазлуллин яшәгән йорт буларак мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелгән.

Бүген Фазлуллин мирасы яшәвен дәвам итә. Татар телен университетларда фән буларак өйрәнүчеләр булганда, бу зур галимнәрнең фәнни хезмәтләре әһәмиятен югалтмаячак әле. Телгә, мәгариф һәм фәнгә тиешле хөрмәт белән караучыларны – элекке заманда яшәгәннәрен дә, бүген үзләрен бу өлкәгә багышлаучыларны да – тиешенчә хөрмәтлик.

«КАЙБЕР КИТАПЛАР ГАШЫЙКЛЫК КЕБЕК…»

Луиза Янсуар

Чебиләрне көзен санныйлар, диләрме әле. Халык әйтсә, бик хак әйтә ул. Һәм менә, гадәттә, иң күп укылган китапларга да бәяне көзен бирәләр. Балалар һәм яшүсмерләр өчен әдәбият өлкәсендә 2024 елгы лауреатларны игълан иттеләр. Алар арасында якташыбыз – татар язучысы һәм тәрҗемәчесе, бик күп әдипләрне рус телендә яңгыраткан, тулы бер рәт антологияләрнең төзүчесе һәм редакторы булган Алёна Кәримова да бар.

Фото: godliterary.ru, Алия Кәримова

Иң башта ук бераз гына лирик булмаган чигенештән башлыйм әле. Соңгы елларда без Алёнаны Мәскәү белән Казан арасында «бүлешәбез». Чөнки аның эше дә, күпчелек проектлары да Мәскәү белән бәйле. Хәзерге көндә инде мөгаллимлек миссиясе дә – ул менә дүртенче ел М.Горький исемендәге Әдәбият институтында татар теленнән рус теленә тәрҗемәчеләр курсы әзерли. Ә бу, әйтергә кирәк, гаять четерекле эш.

Совет чорында системага салынган тәрҗемә эше үзгәртеп кору елларында таркалып үткәндә калды. Хәзерге вакытта моның белән тулы бер институцияләр шөгыльләнми. Дәүләт заказлары, махсус проектларны исәпкә алмаганда, әлбәттә. Әмма андыйлар – бармак белән

ЯЗУЧЫНЫ УКУЧЫ БИЛГЕЛИ. ҺӘМ БУ, АСЫЛДА, ИҢ ГАДЕЛ, КАДЕРЛЕ БӘЯ. ИНДЕ АЛЁНАНЫҢ ТӘРҖЕМӘЧЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ, Ә ИҢ БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА, ӘЛЕ ЯЗУЧЫ ИКӘНЕН ДӘ ИСТӘ ТОТЫП, ИҖАДИ КАЗАНЫШЛАРЫНА ТУКТАЛЫЙК. БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШҮСМЕРЛӘР ӘДӘБИЯТЫ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ 2024 ЕЛГЫ МИЛЛИ ПРЕМИЯНЕ УЛ «ВОЗВРАЩЕНИЕ ПЕЛИКЕНА» ДИГӘН КИТАБЫ ӨЧЕН «БАЛАЛАР ӨЧЕН ИҢ ЯХШЫ ПРОЗА ӘСӘРЕ» НОМИНАЦИЯСЕНДӘ АЛДЫ.

генә санарлык. Чын профессиональ тәрҗемәчеләр – үзләре дә. Ә сүз югары кимәлдәге, сәнгати яктан камил әдәби тәрҗемә турында бара. Ягъни бер әдәбиятны икенче телдә бар нечкәлекләре, менталь үзенчәлекләре белән яңгырату, укучыга әлеге тәрҗемә ителгән әдәбият белән бергә тулы бер халык, аның мәдәнияте турында да мәгълүмат җиткерү.

Шуңа да карамастан, тәрҗемә үз эшенең осталары белән энтузиастларына бәйле рәвештә яшәвен дәвам итә. Бүгенге көндә безнең Татарстан Язучылар берлеге каршында оешкан Тәрҗемә үзәгендә дә, Милли әдәбиятларны саклау программасы кысаларында да, Татарстан китап нәшрияты махсус проектлары, үзара мәдәни багланышлар нигезендә дә тәрҗемә китаплары басылып тора. Әлбәттә, арада төрлеләре бар – сайлау ягыннан да, сыйфаты буенча да.

2024 елда Мәскәүдә узган тәрҗемәчеләр форумында тәрҗемә проблемаларына багышланган түгәрәк өстәл узды. Форумны йомгаклаганда Программаның кураторы Максим Амелин болай диде:

– Югары интеллектлы, тәрҗемә итүнең бөтен нечкәлекләрен белгән бер берәмлек тәрҗемәчене әзерләп чыгару – ул зәркәнлек эшенә тиң, ә бит аннары аларга нинди ихтыяҗ буласын да уйларга кирәк.

– Киләчәктә балаларының ничек урнашып, тамак туйдырачагын да уйлый ата-аналар, курс җыю бик авыр, хәтта ул «целевой» булса да, – дип җөпләде аның сүзләрен Алёна.

Ни өчен бу хакта болай тәфсилләп сөйләвем? Чөнки югарыда әйткәнчә, берәү-икәү-өчәү булган Казаныбыздагы гына тәрҗемәчеләрне дә без 300 дән артык язучыга йолыккалыйбыз, анда да еш кына – стихияле рәвештә. Ә бит әле дөнья күләменә милли классиканы да чыгарырга, социаль проектларга да сулыш калдырырга кирәк.

«ПЕЛИКЕН»НЫҢ ҺӘМ ЯЗУЧЫНЫҢ КАЙТУЫ

Алёна Кәримова. «Возвращение Пеликена». «Рутения» нәшрияты, 2023 ел

«Пеликен»ның кайтуын мин метафора итеп кабул иттем, асылда, бу Алёнаның үзенең «кайтуы» дип. Бик күп еллар дәвамында башкаларның текстларына һәм, әйткәнемчә, антологияләргә кумелгән Алёнаның шагыйрь буларак кына түгел, ә прозаик, драматург буларак та «кайтуы» аеруча сөендерә. Чөнки аның дөньяга карашы нәкъ менә күпсанлы милли әдәбиятлар, классик һәм заманча рус әдәбияты, дөнья мәдәнияте казанышлары синтезында формалашып, укучыга бик кызыклы, кабатланмас әдәби модельләр бүләк итәргә сәләтле.

«Пеликен» – бик үзенчәлекле, кызыклы әсәр. Көннәрдән бер көнне тау мәгарәсендә, лава катламы эчендә бәләкәч кенә, әмма эче тулы кодрәт йөрткән... Пеликен исемле борынгы Чукотка алласы уянып китә. Уянуын уяна, ләкин – менә бәла! – ул берни дә хәтерләми. Төньяк халыкларының дөньяларын яраткан козгын Кутх моңа әйтеп сала: «Мин сине алла вакытында белә идем. Хәзер син кемдер – әйтә алмыйм». Шулай ди дә Пеликенга кешеләр арасына барырга боера. Һәм менә Пеликенның кырыс тундра, кисеп җилләп торган диңгез яры һәм утлы төкереген чәчеп утырган таулар илендә маҗаралары башлана. Әйтергә кирәк, вакыйгалар Камчатка җирлегендә, Петропавловск-Камчатск шәһәрендә бара. Үзенең үткәнен дә, борынгы көчен һәм кем икәнен дә оныткан Пеликенга барысын да искә төшерергә бишенче сыйныф укучылары Андрей белән Настя булыша. Аңа ярдәм иткән арада алар үзләре дә кешенең Җир йөзенә нәрсәгә яралуы турында уйлана башлый.

Хәзерге заманда мәгълүматны каян һәм ничек табасын бик яхшы белгән балалар бервакыт Пеликенга аның... бөтенләй булмавын «гуглить» итеп бирә. Имештер, Пеликенны нindидер бер Америка рәссамы уйлап тапкан, шуннан инде ул бик популяр сувенирга әверелгән. Аның турында табылган тагын бер мәгълүмат – ул Төньяк халыклары, чукча, эскимос, коряк, ительменнәрнең борынгы йорт алласы һәм саклаучы амулеты.

Балалар язучысының сабыйларга да, өлкәннәргә дә, гомумән укучысына иң зур бүләге – ул инде шактый борынгы һәм таушала төшкән бу дөньяны өр-яңадан ачудыр, мөгаен. Балалар, билгеле инде, беренче ачуына – шаккатып, ә менә өлкәннәр оныта төшкән бу ләззәткә рәхмәтле булып, үз-үзләренә гаҗәпләнеп укый ала. «Пеликен» шул ләззәтне бүләк итеп кенә калмый, соңыннан озакка сузылган тәме белән дә җылыта, юата.

Шуны да әйтеп узасы килә: китап Олег Добровольскийның искиткеч рәсемнәре белән бизәлгән. Автор борынгы мифларга үзеннән яңа сулыш өрсә, рәссам да аларны гаҗәеп рәвештә сак һәм ярату белән «заманчалаштырган», күркәм универсальлеккә ирешкән.

Балачакка юл сабу, аның суларында яңадан коенып чыгу аша автор үзенәрәк тә кайтадыр, дип ышанам. Һәрхәлдә, миңа прозаик Алёна Кәримованың алга таба нинди әсәрләр белән сөендерүен көтү – бик кызыклы һәм дулкынландыргыч.

Алия Каюм кызы Кәримова (әдәби тәхәллүсе – Алёна Кәримова) 1976 елның 14 июнендә Кыргыз ССРның Ош өлкәсе Кызыл-Кыя шәһәрендә туа. Өч яшендә әти-әниләре белән Түбән Новгород өлкәсенә Чулково авылына күченә, 2 нче сыйныфны тәмамлаганнан соң – Казанга. 1999 елда Казан дәүләт университетының физика факультетын тәмамлый, физика магистры (оптика һәм нанофотоника кафедрасы).

Шигырьләре беренче мәртәбә «Идел» журналында дөнья күрә. М.Горький музее каршындагы ЛИТОга йөргәндә, Марк Зарецкийның яраткан укучысы була, аның вафатыннан соң, ЛИТОны җитәкли.

Татарстандагы һәм Россиядәге әйдәп баручы газета-журналларда иҗаты һәм тәрҗемәләре даими басылып килә: «Идел», «Казан утлары», «Казань», «Казанские ведомости», «Республика Татарстан», «Дружба народов», «Знамя», «Наш современник», «Новый мир», «Октябрь», «Юность» һ.б.

«Другое платье» исемле беренче шигырь җыентыгы 2006 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыга, аңа кереш сүзне Равил Бохараев яза. «Холодно-горячо» (2015), «Вересковая пустошь» (2016), «Между» (2024) шигырь җыентыклары авторы.

М.Горький исемендәге әдәби премия лауреаты. 2006 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Татар ПЕН-үзәге әгъзасы.

«АЛАР БУЛМАСА, МИН ДӘ МИН БУЛМАС ИДЕМ»

Мин бик кечкенәдән укыйм, шуңа балачагым китаплар белән узды. «Сказки Пушкина», Эно Раудның «Муфта, Полботинка и Моховая борода», Льюис Кэроллның «Алиса в стране чудес», Астрид Линдгренның «Пеппи Длинный Чулок» – иң беренче китапларым. Һәм, әлбәттә, шигырьләр: Сергей Михалков, Агния Барто, Габдулла Тукай, Самуил Маршак, Муса Җәлил, Борис Заходер...

Мөгаен, сәер бала булганмындыр – мәктәп программасын бик теләп һәм тәмләп укый идем. Шуларга өстәп, тагын Толкиен, Замятин, Стругацкийлар, Ефремов, Беляев, Корчагин, Бальзак, Дюма, Саганны... Француз әдәбияты бик ошый. 90 нчы еллар азагында безнең өйдә Пруст пәйда булды, һәм миңа ул бик зур йогынты ясады.

Хәзер параллель рәвештә берничә авторны укыйм. Рус телендә – Алексей Варламовның «Одсун» әсәрен һәм тәрҗемәдә Орхан Памукның «Другие цвета» романын. Әкрен укыйм, беренчедән, вакыт җитми, икенчедән, бу авторлар ашыкмый укуны сорый шикелле. Бигрәк тә – Памук. Шулай ук инглиз телендә Америка язучысы Жанель Браунның All we ever wanted was everything әсәренә тотындым. Әле башладым гына, әмма инде интрига бик көчле...

Соңгы арада искиткеч тетрәндергән әсәр Кобо Абэның «Женщина в песках» романы булды. Мин аны бер ел элек кенә укыдым.

Лев Толстой беркайчан да искерми. «Анна Каренина»ны берничә ел элек кабат укыдым, чагыштырып карар өчен: кабул итүем үзгәрдеме икән? Әйе, үзгәргән, әмма бер нәрсә үзгәрмәгән – Толстой минем өчен һаман да иң әһәмиятле язучы булып кала бирә. Чехов пьесаларын вакыт үзгәртми һәм искертми.

Татар классикасын студентларым белән эшләгәндә кайта-кайта укыйм, яңа мәгънәләр ачам.

Укырга тәкъдим итәм! Соңгы арада укыган китаплардан бик ошаган авторларны, болар – Арундати Рой «Бог мелочей» һәм Наталья Илишкина «Улан Далай».

Даими әйләнеп кайта торган китаплар. Мөгаен, шигырьләрдер. Евгений Боратынский, Марина Цветаева, Арсений Тарковский, Владимир Соколов, Алексей Цветков поэзиясен бик яратам. Иосиф Бродскийны кабат-кабат укыйм.

Мине үзгәрткән китап. Югарыда санаган китапларның барысы да. Алар булмаса, мин дә мин булмас идем.

Боратынский җыентыгын укып чыккач, шигырь яза башладым. Бер сулышта укылды ул. Миңа 12-13 яшьләр иде.

Кәгазь китапны уку дөресрәк һәм рәхәтрәк, билгеле. Әмма мин хәзер нигездә электрон форматта укыйм...

Китап минем өчен нәрсә ул? Гомумән, төшенчә буларак кына аерып карау кирәкмидер. Кайбер китаплар берниндиде тойгы уятмый, ә кайсыберләре, гашыйклык кебек, тулаем үзенә йолып һәм йотып ала.

ЯҢА БҮЛӘК: ИЛҺАМЛЫ АВЫЛ



ЯҢА БҮЛӘК

Тукай районына сәяхәткә кузгалдык. Яңгыр сибәләп тора. Югыйсә декабрьнең беренче атнасы узып бара. Узган ел бу вакыт ап-ак кар иде, дип сөйләшәбез. Әйе, ел белән ел охшаш булмый шул.

Авыллар да бер-берсеннән аерыла. Без барасы Яңа Бүләк авылы татар милләтенә легендар җырчы – Илһам Шакировны биргән төбәк. Илһам ага олыгайган көндә дә Яңа Бүләккә кайтып йөргән. Биредә бүген дә аның туганнары яши.

Руфия Фазылова

Фото: Лилиана Вәлитова

ГАРМУНЧЫГА СҮЗ ӘЙТМӘГЕЗ...

Үзәк урамга килеп кердек. Күпкатлы йортлар каршы алды. Әллә бистәме, дисәк, авыл статусында йөри икән. Ә бу күпкатлы йортларны заманында эшчеләргә дип колхоз төзеткән.

Яңа Бүләк чагыштырмача яшь авыл: 1927 елда нигез салына аңа. Колхозлар оеша башлагач, бу урында авыл ясарга уйлыйлар. Нәтиҗәдә, якындагы өч саладан кешеләр килеп, бирегә төпләнә. 1984 елга кадәр Яңа Бүләк Сарман районына карый. Шуның өчен өлкәнрәк кешеләр үзләрен һаман да сарманлылар рәтенә кертә, шул чакларны сагынып искә ала.

Телефоннан сөйләшкәндә үк авыл җирлеге башлыгы туры мәдәният йортына килүебезне сорады. Хәер, Илһамлы авылда шулай булырга тиештер дә...

Мәдәният йорты капиталь төзекләндерүдән соң: эчтән дә, тыштан да ялт итеп тора. Бирегә аяк баскач та, тамашачыны Илһам ага «каршы ала»: холлда легендар җырчының портретлары, шәҗәрәсе. Һәм монда көн саен гармун, курай тавышы яңгырый икән. Без дә әле шул көйләрне хозурланып тыңладык.

1
Бу күпкатлы йортларны заманында эшчеләргә дип колхоз төзеткән.

2
Мәдәният йортында тамашачыны Илһам ага «каршы ала»: холлда легендар җырчының портретлары, шәҗәрәсе...

3
Гыймазетдиновлар тормышын мәдәнияткә багышлаган гаилә.

4
Нәзир абый уен коралларын үзе дә ясый.

Яңа Бүләк мәдәният йортында ирле-хатынлы Дилбәр һәм Нәзир Гыймазетдиновлар эшли. Берсе – директор вазыйфасында, икенчесе – сәнгать җитәкчесе. Утыз сигез ел элек Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлап, эшкә кайткан булганнар.

– Һич онытасым юк, Нәзир белән Яңа Бүләккә 1987 елның 1 февралендә килдек. Без инде ир белән хатын идек, – дип искә алды Дилбәр апа. – Ул вакытта авылга эшкә килгән кешеләргә колхоз торак бирә иде. Без өч катлы йорттан өч бүлмәле фатир алдык. Ике яклы йорттан да торак алу мөмкинлеге бар иде. Соңрак ул йортларны үзебезгә рәсмиләштердек. Бушка бирелгән торакка кызыгып, ул чагында колхозга бик күп яшь белгечләр кайтты, табигый ки, балалар да күп иде. Хәзер менә ул чакларны сагынып сөйләргә генә калды.

Чынлап та, 90 нчы елларга кадәр Яңа Бүләктә яшь гаиләләр күп булган. Шуның өчен дә авылда 1986 елда урта мәктәп ачылган. (Авылда беренче башлангыч мәктәп 1930 елда эшли башлый.) Бүген исә Яңа Бүләкнең төп белем бирү мәктәбендә 27 укучы белем ала.

– Элек эшләргә күңеллерәк иде, – дип сүзгә кушылды Нәзир Гыймазетдинов. – Чыгыш ясарга Мәскәүгә, Кырымга кадәр барып җиттек. Балалар белән берничә түгәрәк оештырдык: курайда, гармунда уйнарга өйрәнделәр. Алар белән төрле республика конкурсларына йөрдек, урыннар алдык. Әйе, ул түгәрәкләр әле дә эшли. Берничә егетебез бик тырышып шөгыльләнә. Шулай да авылда урта мәктәп булмавы үзен сиздерә...

Нәзир абый гаҗәп кеше: берничә төрле уен коралында уйный. Алай гына да түгел, аларны ул үзе ясый: курай, сорнай, баяннарга икенче тормыш бүләк итә. Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре исеме бар.

– Без эшкә кайтканда, Яңа Бүләкнең мәдәният йорты буш, кассеталы магнитофоннан башка бер әйбер дә юк иде. Колхоз рәисенә әйтеп, кайбер әйберләрне сатып алдык. Аннары, акрынлап, уен коралларын үзем ясый башладым. Курайга охшаган менә бу уен коралы сорнай дип атала. Ул дөнья халыкларында да очрый. Аның исемнәре генә төрле, бездә, татарларда,

сорнай дип йөртәләр. Аның төп өлеше курайныкы кебек, башы гына башкача, шуңа күрә тавышы үзгәрәк яңгырашка ия.

Гыймазетдиновлар тормышын мәдәнияткә багышлаган гаилә. Тәүлекнең яртысын эштә уздыралар. Алар алган диплом, рәхмәт хатларының иге-чиге юк. Нәкъ менә Илһам Шакировны биргән авылда шундый мәдәният хезмәткәрләре булу сөенеч кенә түгел, олы бер дәрәҗә дә!

«БӨТЕН МӨМКИНЛЕКНЕ ТУДЫРДЫЛАР»

Әлбәттә, Яңа Бүләккә баргач, Илһам аганың туганнары белән дә очрашасы килде. Дөрес, монда кем белән генә сөйләшсәң дә, легендар авылдашларын телгә ала. Илһам ага картайган көнендә дә бирегә кайтып, җәйләрен яшәп китә торган булган. Яңа Бүләктә Илһам Шакировка дип махсус йорт төзегәннәр. Бүген ул музей буларак хезмәт итә. (Музейда төзеклəндерү эшләре бара иде, без аны тыштан гына карап уздык.)

– Мин Илһам абыйның бертуганы Кыяметдинның олы улы булам, – дип таныштырды үзе белән Флүр абый Шакиров. – Гаиләдә өч ир, бер кыз бала үстек. Күп еллар колхозда баш агроном булып эшләдем. Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым. Илһам абый: «Иң тыныч, иң кирәкле һөнәр – ипи үстерүче. Дөрес юлны сайладың, молодец. Артист булмагыз, кирәк түгел», – дип әйтә торган иде.

– Сезнең гаиләдә барысы да җырчылар икән, – дим.

– Әйе, Аллаһы Тәгалә барыбызга да андый сәләтне биргән. Энекәш, сеңелкәшләр кайда гына эшләсәләр дә җырлап яшиләр.

Флүр абый зыялы кеше. Нәсел-шәҗәрәсен дә өйрәнгән, ата-бабалары белән бик нык горурлана.

– Илһам абыйның бертуганнары калмады инде, – дип дәвам итте ул сүзен. – Күрше авылда аның ике апасы гомер итте. Иң соңгы булып Зәйнәп апа дөнья куйды. Өч еллап бар инде. Данлыклы нәселебезнең исемен хәзер без саклыйбыз, аннан дилбегә балалар кулына күчә инде.

Флүр Шакиров гомере буе Яңа Бүләктә яшәгән. Туган авылы турында менә нәрсәләр сөйләде ул:

– Колхозлар оеша башлагач, бу урында авыл төзергә карар кылганнар. Җирләр уңдырышлы, халык тырыш булган. Шуның өчен дә яңа оешкан колхоз уңышлы гына эшләп киткән. Мәктәп, балалар бакчасы төзелгән. Әле сугыштан соң ятимнәр йорты да ачылган. Күрше районнардан да балаларны җыйганнар. Ул вакытта инде Яңа Бүләктә сигезъеллык мәктәп булган. Ә менә Илһам абыйлар үскәндә авылда башлангыч мәктәп кенә эшләгән әле, алар урта сыйныфларда күрше Чыршылыга йөреп укыганнар.

Яшь авыл булганлыктан, колхоз җитәкчелеге Яңа Бүләкне һаман зурайтырга омтыла. 1958 елда заманына күрә бер дигән 16 бура йорт кулланышка тапшырыла. Ул колхоз эшчеләренә бушка бирелә. Һәм бу сәясәт алга таба да шулай дәвам итә.

– 80 нче елларда колхоз өч катлы йортлар сала башлады, – ди Флүр абый. – Ике яклы зур йортлар да бар иде. Миңа, мәсәлән, университетны тәмамлап кайтуга, колхоз рәисе яңа йорттан кулга ачкыч тоттырды. Әле ул вакытта мин өйләнмәгән дә идем. Әйтәм бит, авылда эшчеләр калсын өчен, бөтен мөмкинлекне тудырдылар. Һәм бер дигән итеп эшләдек тә: гектарлап кишер, суган, чөгендер, нәрсә генә үстермәдек.

– Ә ни өчен сезнең як халкына гына мондый бәхет тәтегән? – дим.

– Чөнки Чаллы халкын авыл хуҗалыгы продукциясе белән тәэмин итәргә кирәк иде. Сарман, Тукай районнары авылларына әнә шундый максат куелды. Шуның өчен дә безнең як авылларны бик күтәрделәр.

Флүр абый җәмәгате Альмира апа белән кырык ике ел тату гомер итәләр. Бер ул, бер кыз үстергәннәр, алар калада яши. Инде

Шакировлар нәселенең лаеклы дәвамчылары.

5

6
– Безнең нәселдә озак яшиләр. Шакир бабабыз 96 яшен тутырган, – диде Мөзәянә апа.

7
Айдар Мингалиев Яңа Бүләк авылында зур гына ашлык амбары, тегермән ясап куйган.

оныклары буйга җитеп килә. Балалары кайтып йөри икән. Альмира апа бик уңган хуҗабикә. (Моңа үз күзләребез белән инандык). Кыскасы, ир белән хатын – атаклы нәселнең лаеклы дәвамчылары.

«КЕЧКЕНӘДӘН МАТУР ҖЫРЛЫЙ ИДЕ»

Яңа Бүләкнең акъәбисе – Мөзәянә Вәлиуллина белән дә таныштык. Әбекәй туксан дүртенче яше белән бара. Дөрес, үз яшен биреп булмый: хәтере дә яхшы, егәре дә бар. Өе тулы гөлләр, җәен бакчасы да шау чәчәктә икән. Иң чиста бәрәңге бакчасы да аныкы була, диделәр. Кышын исә әбекәй бәйли, Коръән укый.

– Илһаметдин белән без икетуган булабыз, әниләребез бертуган. Мин аннан өч класска зуррак укыдым. Әле бергә Чыршылы мәктәбенә укырга йөрдек. Кыскасы, бергә үстек.

– Илһам абый бала чакта нинди иде? – дим.

– Аны гел җырлаталар иде. Хәтерлим, мәктәптә чыршы бәйрәме булды. Ул заманда уенчык урынына камырдан балыклар пешереп эләләр иде. Аннары инде бәйрәмдә катнашкан балаларга шул пешкән ризыкларны чыршыдан алып бирәләр. И, аңа сөенәсең инде! Илһамга да шул бүләкне бирделәр. Аңа куанды инде, җаным! Тамак ач бит...

Мөзәянә апа гомер буе Яңа Бүләктә яшәгән, колхоз эшендә булган. Мәрхүм җәмәгате белән өч бала үстергән. Бүген төп таянычы – Чаллыда яшәүче улы белән кызы икән. (Бер улы фаҗигале рәвештә вафат булган.)

– Бу минем төп нигез, – диде әбекәй. – Әти белән әни карт булгач, иптәшем алар белән яшәргә каршы килмәде. Соңрак яңа йорт салдык. Тик иптәшем минем кебек озын гомерле булмады. Безнең нәселдә озак яшиләр. Шакир бабабыз 96 яшен тутырган.

Мөзәянә апа заманча бер дигән йортта яшәсә дә, яшьлеген сагына. Басуда фәлән гектар чөгендер утаган, фермада эшләгән елларын, инде мәрхүм авылдашларын юксына.

– Безнең колхоз бай яшәде, Гыймадиев Шәүкәт абый бик көчле җитәкче иде, – диде әбекәй. – Өч тапкыр КПСС Үзәк Комитеты Байрагына ия булдык. Идарәдә Кызыл Байрак торды. Күрше авыллар да безне мактап сөйлиләр иде. Безнең әти белән әни Яңа Бүләккә Зәй районының Бистә Башыннан күченеп килгән була. Узган гасыр башында бит бу җирләргә төрле өч авылдан кешеләр килеп төпләнә.

– Ә алар үзара дус-тату яшәдеме соң? Авылларга бүленеш юк идеме?

– Юк, бик тату яшәдек. Мал суйсак та, бәрәңге утыртсак да, кумәкләп эшләдек. Авыл урамнары гөрләп тора иде. Эш беткәч бергәләп күңел дә ача идек. Шулай туры килгән: Яңа Бүләктә гармунчылар, җырчылар күп. Күрәсең, халык бер-берсеннән күреп җыр-моңга тартылган.

«ҮЗЕҢӘ ЭШЛӘҮ ОТЫШЛЫ!»

Кызганыч, Яңа Бүләкнең алдынгы колхозы үзгәртеп кору җилләренә каршы тора алмаган. (Башка бик күп авылларның да фаҗигасе бу.) Авылда фермерлык эше белән шөгыльләнүчеләр бар, Мингалиевлар шуларның берсе. Гаилә башлыгы Айдар Яңа Бүләк авылында зур гына ашлык амбары, тегермән ясап куйган. Берничә складлары да бар. Ике улы белән 160 гектар җирне эшкәртеп, җир җимертеп яшәп ята.

– Безнең малайлар биш яшеннән трактор йөртте, – дип шаккатырды ул. – Олы улыбыз хәзер Чаллыда укый, икенчесе Яңа бүләк мәктәбендә белем ала. Җәй буе кырда эшлибез. Улларым – төп ярдәмчеләрем, кечкенәдән бөтен эшкә өйрәнеп үсәләр.

Айдар Мингалиев КФХ булып җиде ел эшли икән. Авылдашларының пай җирләрен арендага алган. Аңа кадәр берничә ел үзенең пай җирләрен эшкәрткән. Җәмәгате Гүзәл дә шушы эштә – документларны алып бара.

– Хәзер арпа белән бодай гына үстерәчәкбез, – диде фермер. – Быелга кадәр күпләп бәрәңге утырта идек, ләкин туктарга карар кылдык.

– Ни өчен? Бәрәңге үстерүнең файдасы юкмы? – дим.

– Эше авыр. Ә файдасына килгәндә, төрле еллар булды. Кайбер елны бәрәңгедән яхшы гына табыш аласың. Басуы белән сукалап аткан чаклар да булды, чөнки бәрәңгенең килосы биш сумга төште. Кеше яллап эшләткәнче, сукалап атуың файдалырак дип таптык...

Айдар Мингалиев 2010 елга кадәр йөк ташу белән шөгыльләнгән, шәхси машинасы булган. Һәм корылык булган елны үзе өчен яңа юнәлеш ачкан.

– Җирдән бик ерак кеше идем, – дип дәвам итте фермер. – 2010 елда бәрәңге булмады бит. Мин бер эшмәкәргә үземнең КАМАЗ белән бәрәңге алып кайтып бирдем. Ул аны бер тәүлек эчендә сатып бетерде. Шуннан уйладым да үземә шулай бәрәңге алып кайтырга булдым. Яхшы гына акча калды. Гомумән, үзеңә эшләү һәрчак отышлы.

«Бәрәңгегә сорау зур икән. Ә нишләп үзебезгә утыртмаска?» Айдар Мингалиев әнә шулай итеп фермерлык эшенә кереп китә. Агрофирмадан үзенең пай җирләрен алып, өч гектар җиргә бәрәңге утырта. Ике елдан соң бәрәңге үстерергә дип, ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан грант алалар. Шулай шактый еллар икенче икмәк үстерәләр.

– Айдар заманга яраклаша белә, – дип сүзгә кушылды Гүзәл Мингалиева. – Игенне хәзер килолап түгел, он иттереп ясап сатабыз. Алай күпкә отышлырак. Онны үзебез тартабыз, гомумән, бөтен эшне бергәләп эшлибез.

...Яңа Бүләк Чаллыдан утыз биш чакрым гына. Әллә шуңадамы, шәһәрчәрәк яши биредә халык. Йорт-җирләрен гөл итеп тотып, зыялы гына сөйләшеп, матур итеп гомер итәләр. Җыр-моңга булган сәләтләрен әйттем инде. Татар дөньясына легендар җырчы биргән авылны күреп сөенеп кайттык. «Илһам» чишмәсе, музей, мәктәп, мәдәният йорты, бөтен җирдә бөек җырчының исеме балкып тора. Хәер, башкача була алмыйдыр да. Илһамлы авыл бит бу!

9 Илһам Шакиров музеендә төзекләндерү эшләре бара.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

– Яңа Бүләк авылы борынгы түгел. Аңа нибары XX гасырда гына нигез салына. 1927 елда күрше Таулык, Бистә Башы (Зәй районы), Иске Әлмәт (Сарман районы) авылларыннан берничә гаилә күченеп утырган дип карала. Шуның өчен дә Югары очта – Бистә Башы, Урталыкта Таулыктан килгән, Түбән очта Иске Әлмәт кешеләре төпләнгән. Исеменә килгәндә, колхозның күрсәткечләре әйбәт булгач, Сабан туенда халыкка эш кораллары тапшырганнар. «Бу сезгә яңа бүләк», – дигәннәр. Менә шуннан авылның исеме дә Яңа Бүләк булып калган, дип фаразлана.

Флүр Шакиров, авыл тарихы белән кызыксынучы



ПАРИЖ, BELLE ÉPOQUE (12+)

Клод Моне, Поль Гоген, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе... – әлеге бөек рәсем осталарының әсәрләрен «Эрмитаж-Казан» үзәгендә ачылган яңа экспозициядә күреп була. Күргәзмә безне Belle Epoque, яки Гүзәл эпоха (Европа тарихының XIX гасыр азагыннан алып 1914 елга кадәрге чоры шулай атала) белән таныштыра. Әлеге дәвер рәсем сәнгатендә һәм бөтен дөнья тарихында үзгә бер урын алып тора. Европа өчен иң бәхетле һәм ваемсыз еллар бу, гөрләп үсү, тынычлык, муллык эрасы. Һәм барыннан да бигрәк Франция өчен Belle Epoque атамасы шунда туган. Гүзәл эпохада иҗат ителгән даһи әсәрләр – кешелекнең бөек мирасы.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр). Дүшәмбе – ял көне
«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ӘЛФИЯ АВЗАЛОВА. МӘҢГЕЛЕК ЮЛ (12+)

«Миннән еш кына: балачагым, яшьлегем ничек үтте, ничек җырчы булып киттем, хәзер ничек яшәвем турында сораштыралар. Җырның ничек тууы белән кызыксыналар, башка күп сораулар бирәләр», – дип язган «Үзем турында» дигән китабында Әлфия Авзалова. Күренекле татар җырчысы турында спектакльне куючылар шул сорауларның кайберләренә җавап бирергә омтыла, аның катлаулы язмышын сәхнәдә гәүдәләндермәкче була.

Әлфия Авзалова – татар җыр сәнгатенең горурлыгы, феномены. Беренче карашка бар дөньяны кочып, җырлап-биеп яшәгән, һәрчак шат күңелле булып тоелган Әлфия Авзалованың мәңгелектә исемен калдыру юлы гаҗәеп сынауларга, кискен борылышларга үтә дә бай.

Әлеге музыкаль байопик татар сәхнәсе йолдызының тормышка, сәхнәгә, кешеләргә чиксез мәхәббәтен, кабатланмас бөеклек юлына кечкенә чагыннан ук салынган сукмагын, шул сукмактагы ышаныч-өметләрен, югалту-сагышларын һәм чиксез тирән моңын чагылдыра.

15 декабрь, 18:00. Зур зал
Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры
Казан, Татарстан ур., 1

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, kamalteatr.ru, tatfil.ru

ХЫЯЛГА БЕР АДЫМ (12+)

«Хыялга бер адым» спектаклендә Кәрим Тинчуринның «Без кабызган утлар сүнмәс алар…» дигән канатлы сүзләре лейтмотив буларак кулланыла. Биредә вакыйгалар 1921 елда бара. Кәрим Тинчурин җитәкчелегендәге татар артистлары, Самарада театр курслары тәмамлаганнан соң, Оренбургка килә. Тик артистларның татар театрын үстерәбез дигән хыял һәм ниятләре чәлпәрәмә килергә мөмкин: Идел буенда ачлык башлана, тиф казасы тарала. Артистларны һәм татар театрының киләчәген коткару өчен, режиссер труппаны алып Ташкентка китәргә карар кыла. Ташкентка барганда Кәрим Тинчурин «Хыялга бер адым» исемле пьеса яза һәм аны шунда ук поездда куя. Режиссер моны артистларны канатландырып, хыялландырып җибәрү, юл газабын, ачлык һәм авыруларын онытып тору, өметсезлектән арындыру максатыннан эшли. «Кешене хыял яшәтә. Ә артист халкын сәхнә алга әйди… Мин труппаны яңа пьеса белән генә, репетицияләр белән мавыктырып кына коткарып кала алачакмын», – ди Кәрим Тинчурин хатыны Заһидә ханымга… Тормышта булган вакыйгаларга нигезләнгән.

27 декабрь, 18:30 сәг., К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13

ИМПЕРАТОР ФАТИРЫ СЕРЛӘРЕ (0+)

Казан Кремлендәге Губернатор йортын ни өчен элеккеге хан сарае урынында ук салганнар? Аның мигъмары кем? Хакимлек итүче Романовлар династиясе резиденцияләреннән берсе саналган император фатиры нинди булган? Бу һәм башка сорауларга җавапны «Император фатирлы йорт» күргәзмәсендә табарга мөмкин. Биредә Губернатор сараендагы борынгы җиһазларга хозурланырга, археология раритетларын һәм хәтта уналтынчы гасыр тәңкәләре хәзинәсен күрергә була. Экспозициянең бер өлеше Казан ханлыгы чорындагы хан сараена һәм XVI–XVII гасырлардагы патша даирәсенә багышланган. Хәзер исә Губернатор сараенда Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясе урнашкан.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне
Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музее
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

БЕР ГАСЫРГА СОҢАРГАН КҮРГӘЗМӘ (6+)

Парадокс: моннан йөз ел элек әзерләнгән күргәзмә хәзер генә дөнья күргән. Мәскәү, Петербург, Казандагы авангард һәм реалистик рәсем сәнгате осталарының өч йөзләп эше хакында сүз бара. Авторларның исемнәре генә дә ни тора! Николай Фешин, Василий Кандинский, Александр Родченко, Варвара Степанова, Ольга Розанова… Өченче күчмә сәнгать күргәзмәсе өчен сайлап алынган картиналар, графика һәм сыннарны 1921 елда Вятка (Нократ) губернасы шәһәрләрендә күрсәтергә карар кылына. Экспонатлар арбаларда күчерелә, Яранскига гына килеп җитә алалар, аннары юлсызлык һәм акча юклыгы сәбәпле туктап калалар. Картиналар турында искә төшерүче дә булмый, һәм XX гасыр азагына кадәр алар Вятка (Нократ) губернасы музейларының запасникларында саклана… Бүгенге экспозициядә башлангыч чор совет сәнгате күренекле вәкилләренең Вятка сәнгать музее, Яранск төбәкне өйрәнү музее, Слободской төбәкне өйрәнү музее, шулай ук Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда һәм хосусый тупланмаларда саклангaн ике йөздән артыграк әсәре күрсәтелә.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр (җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

КЫШ БАБАЙДА КУНАКТА (0+)

Яңа елга аяк басарга әзерләнәбез. Бәйрәм рухы өйләргә, мәдәният йортларына, театрларга үтеп керә.

Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе дә яңа елда яраткан тамашачылары белән очрашырга әзерләнә. 2025 елның 2 гыйнварында ул җыр сөюче дусларын филармония артистлары катнашындагы «Кыш Бабайда кунакта» дип аталган бәйрәм концертына чакыра.

Бәйрәмдә сез Вил Усманов, Асылъяр, Ильгиз Мөхетдинов, Зәринә Хәсәншина, Әлфис Галиуллин, Татьяна Ефремова, Айнур Муратов, Эльмира Гильфанова, Рафиль Җәләлиев, Алина Даутова, Игорь Дмитриев, Алмас Хөсаенов, Миләүшә Миңнушина, Булат Закиров, Алиса Мамина, Салават Шәфыйков, Рөстәм Хөсәенов кебек яраткан җырчыларыгызны тыңлап, рәхәтләнеп ял итә аласыз.

2025 елның 2 гыйнвары, 18:30 сәг.
Г.Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

Җылылык һәм яктылык шагыйрьләре.

ҖЫЛЫЛЫК ҺӘМ ЯКТЫЛЫК ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Караңгы һәм салкын ноябрь көннәрен «Җылылык һәм яктылык шагыйрьләре» дип аталган иҗади очрашу ямьләде.

Камал театрының Кече залында аны «Татэнерго» АҖ хезмәткәрләре оештырды. Инженерлар, машинистлар, техниклар, программистлар, контроль инспекторлары, слесарьлар, икътисадчылар, шәфкать туташлары, хисапчылар һәм, әлбәттә, ветераннар – Татарстанның атказанган энергетиклары.

«Ренессанс» камера оркестры солистлары музыкасы дулкынында Яр Чаллы җылылык-электр үзәге (ҖЭҮ), Яр Чаллы җылылык челтәрләре эшчеләре, Зәй ГРЭС гидротөзүчеләре белән гидроэнергетиклары, Түбән Кама ГЭС, Казан ҖЭҮ-1 һәм Казан ҖЭҮ-2 хезмәткәрләре үзләре иҗат иткән шигырьләрне укыды.

Энергетиклар нәрсәләр турында язамы? Мәхәббәт, балалар, гаилә һәм өй җылысы турында.

Җылылык һәм яктылык шагыйрьләре, дип күңелгә теркәп куйдык без аларны.



Үз хезмәткәрләренең шигъри иҗатын чын күңелдән хуплаучы җитәкче – **Рәүзил Мәгъсумҗан улы Хаҗиев**.

Максим Тропынин, Мәгълүмати технологияләр бүлегенең әйдәп баручы инженеры, «Татэнерго» АҖ филиалы – Казан ҖЭҮ-2.

Илья Першаков, «ТатАИСЭнерго» ҖЧҖ коммерция бүлегенең 2 нче категорияле белгече.

«Татэнерго» АҖ филиалы – Яр Чаллы җылылык челтәрләре оешмасының җылылык энергиясен исәптә тоту һәм югалтуларны анализлау бүлеге инженеры **Зөлфия Нурлыгаянова** үз шигырен татар телендә укый.

Кайтаваз

Кеше гомере шундый озын кебек
Күккә карап ятсаң бишектән!
Әнә бит ул чиксез яулар үрләр...
Күренәләр нигез читеннән!

Әткәй белән әнкәй – очар канат!
Әле яшьләр, дөнья көтәләр.
«Һәр заманда намусыңны югалтма!
Кешелекле бул балам!» – дияләр.

Һич аяусыз еллар ага бирә,
Җыерчыклар, сырлар салалар...
Кичә гади авыл балалары
Бүген түрә, кеше булалар.

Кичә дөнья ярып аваз салган сабый
Бүген чаба гасыр артыннан.
Тик хәтердә кала туган авыл,
Ачы үкенү кала ахырдан.

Бер мизгелгә туктыйк әле, дустым!
Мәшәкатьләр торсын бер читтә!
Йомшак икмәк алып, әнкәйләргә кайтыйк!
Кадерен белеп калыйк исәндә!

Фото: Никита Тохтасинов

сеть ювелирных салонов
ЭКСКЛЮЗИВ
Дарите любимым драгоценные подарки!
Скидки до 50%
Действуют дисконтные карты всех ювелирных салонов
Скупка по лучшей цене в городе
ОБМЕН ВАШИХ СТАРЫХ ИЗДЕЛИЙ НА НОВЫЕ УКРАШЕНИЯ
ПО ВЫГОДНОЙ ДЛЯ ВАС ЦЕНЕ
Сеть ювелирных салонов «Эксклюзив» в Казани:
ул. Бутлерова, д. 29, тел. (843) 238-42-50
ул. Р. Зорге, д. 67, тел.: (843) 268-25-24, 268-94-95
ул. Чистопольская, д. 16/15, тел.: (843) 223-00-08, 223-00-09
Работаем в обычном режиме с 10:00 до 20:00
Ещё больше новинок в нашей группе Телеграм exclusive.kazan
www.exclusive-jewelry.ru
РЕКЛАМА